
Рәмзия Мөхетдинова
Гомер җырда калсын ...

# КЕРЕШ СҮЗ

Тирә-ягыбызда гаҗәеп кешеләр бар: алар белән бер очрашкач, кабат очрашасы, сөйләшкән саен сөйләшәсе, тыңлаган саен тыңлыйсы килә үзләрен. Андый кешеләр һәрчак ачык йөзле, тәмле сүзле, тирән фикерле, көчле рухлы, ташып торган энергияле булалар һәм үзләренә магнит кебек тартып торалар.

Туган якның моңлы җырчысы, күпкырлы сәләт иясе, тиз арада бөтен Татарстанга танылуга ирешкән авылдашыбыз Марсель Гыймазетдинов нәкъ менә шундый асыл зат иде. Без, бәзәкәлеләр, аның белән аеруча нык горурланабыз. Аның китаплары өстәлләребездә, шигырьләре телләребездә, җырлары күңелләребездә.

Без, бәзәкәлеләр, Марсель Гыймазетдинов белән бер авылда туып үскәнбез, гомеребез буе бер чишмә суларын эчкәнбез, кечкенә чакта инешендә, ялантәпи чупырдап, бәбкәләр саклаганбыз. Үсә төшкәч, гүзәл Пинәрә күлендә колач салып йөзгәнбез. Болыннарда җиләк-җимеш, әрәмәдә бадан-гөлҗимеш җыйганбыз, басу-кырларда башаклар җырын тыңлап, үсмер чакка аяк басканбыз. Мәктәпне бетергәч, яшьлегебез язында, туган авылны калдырып, төрле якларга таралганбыз. (Шәхсән үзем Марсель абый белән бер фамилия йөрттек)

Чыннан да, аның белән бер заманда, бер авылда яшәү, бер мәктәптә уку, үзен һәрдаим күреп аралашу-гәпләшү, аның шигырьләрен уку, җырлары белән хисләнү – үзе бер бәхет түгелмени? Әле нинди генә бәхет!

Марсель Гыймазетдинов – җир кешесе, җир улы иде. Ул көнозын басу-кырларда, колхозчылары янында булды, һәр карыш җир, һәр бөртек башак язмышы өчен тир түгеп, тузанга батып, армый-талмый эшләде. Артта сөйрәлүче колхоз-совхозларны, бушап баручы авылларны аякка бастру, авыл халкына кешечә яшәү өчен мөмкинлекләр булдыру өчен  җан атты., Ак хисләр белән тулы үзенең иң беренче “Туган авылым – Бәзәкәм” ( комп.В. Мироваев көе) җырында ук ул игенчегә, җир кешеләренә мәдхия җырлады.

Басуларда – башак җыры,
Тургай моңы кырларында.
Зифа билле сылуларың
Уйный йөрәк кылларында
Кушымта: Әй, Бәзәкәм, Бәзәкәм,
Языңны күтеп алам.
Тирәк, камыш, каен моңын
Йөрәк җырыма салам.
Иген игә егет-кызың,
“Кара алтын” таба илгә.
Шатланып туя алмыймын
Туганга мин Бәзәкәмдә.

Әй, Бәзәкәм, Бәзәкәм,
Туган авылым, Бәзәкәм.
Хезмәт таңың минем өчен
Зур бер шатлык, зур бер бәйрәм.

Ә җәмәгать эшләрен ничек алып барды ул! Ничек барысына да җитеште, тормыштагы вакыйгаларның һәркайсында үзе булырга, үзе катнашырга вакыт та, теләк тә тапты икән бу тынгысыз җан. Монысына инде гаҗәпләнергә генә кала. Әйтәләр бит: “Эшлисе килгәннең – теләге, эшлисе килмәгәннең – сәбәбе була”,-дип. Бу нәкъ Марсель Гыймазетдинов мисалы. Чыннан да, аның эше дә, теләге, сүзе, иҗаты да бер-берсеннән аерылмадылар, гел бергә үрелеп бардылар. Ул барысына да өлгерде, барысын да булдырды. Чөнки беркайчан да ярты юлда кире борылуны белмәде. Бу аның тормыш кагыйдәсе, яшәү мәгънәсе иде.

Эшләү-яшәү дәверендә аңа күп киртә-каршылыкларны җиңәргә, ялагай-куштаннар белән көрәшергә, туры, гадел сүзен курыкмыйча, кистереп әйтергә дә кирәк булды. Тормышыбыздагы тискәре һәм ямьсез күренешләргә, гамәлләргә каршы, дөреслек, хаклык өчен туктаусыз көрәште. Барыбыз да беләбез, җиңеллеккә караганда авыр чаклары күп булды аның. Хәер, андый чакларда, ул әйтәсе сүзен, бар дөнья ишетелерлек итеп, шигырьләре аша әйтә алды  һәм шуның белән бәхетле иде. Чөнки ул 100% лы оптимист, күңеле бер дә картаймый, гел уен-көлкеле, кешеләр белән бик тиз уртак тел таба алучы, күңелендә башкаларга һәрчак яхшылык кына эшләү теләге булган гаҗәеп шәхес иде.

Шушындый борчулы тормыш мәшәкатьләре һәм үтә тынгысыз хезмәтенә карамастан, Марсель Гыймазетдинов иҗатны да күңел халәте итеп яшәде, язды, китапларын чыгарды, үзенең иҗатын яратучылары белән даими очрашулар үткәрде, алар белән кызыклы әңгәмәләр корды, күпсанлы сорауларына җаваплар бирде.

Әмма йөрәк тимер түгел. Җир җимертеп эшләп йөргәндә, киләчәккә планнар корып, эш-гамәлләре көтеп торганда, ярыштагы аргамактай, башын югары тотып, кискен искән җилләргә бар көченә каршы чапкан мәлдә, шагыйрь йөрәге кинәт туктап калды. Бу – 1993 елның 19 апреле иде.

Шагыйрьне соңгы юлга озатырга йөзләгән кешеләр: авылдашлар, районадашлар, мәктәп укучылары, күрше Алабуга, Әгерҗе, Чаллы, Түбән Кама, Казаннан вәкилләр килде. Халык ташкыны урамнарга сыймады. Авыр, бик авыр иде ул минутларда... Исән чагында яратып, тырышып, тир түгеп иген иккән туган туфрагы кадерле, газиз улын мәңгелеккә үз куенына алды.

Ә бит әле аңа 50 яшь тә тулмаган иде. Аның әле яшисе дә яшисе, туган җирендә ипи-ипекәй үстерәсе, өстәлләребезгә мул сый-ризыклар җитештерәсе, җанга якын шигырь-җырларын иҗат итәсе бар иде. Ләкин язмыш-тәкъдир барысын да үзенчә хәл итте.

Марсель Гыймазетдиновның безнең арадан киткәненә дә инде 25 ел узган. Ә без аны, күпме вакыт узса да, һаман да сагынабыз, әле дә юксынабыз. Ул һәрчак безнең хәтерләрдә, күңелебез түрендә.

Менә ни өчен мин, шагыйрьнең 75 еллык юбилеена багышлап, китап чыгарырга булдым. Иң әүвәл китапка "Өзелгән җыр" дигән исем бирергә уйладым. Әмма бу уемнан бик тиз кире кайттым. Юк, дөрес түгел. Аның бер генә җыры да өзелмәде, киресенчә, алар яшиләр, бик еш яңгырыйлар. Китапка исем итеп шагыйрьнең бер кичәдә үзе әйткән искиткеч матур да, мәгънәле, тәэсирле дә сүзләрен алдым: "Гомер җырда калсын..."

Бу чынлап та шулай булды. Шагыйрь вафатыннан соң да аның шигъри юлларына яңадан-яңа көйләр языла, матур җырлар туа. Алар радио һәм телевидениедә даими яңгырыйлар һәм безнең күңелләрне якты, җылы хисләр белән иркәлиләр, назлыйлар.

Кешеләргә биреп бетерәсе яратуы һәм туган җиренә карата җан җылысы бөркелеп торган шигырь-җырларын югалтмыйча, кадер-хөрмәттә саклыйсы иде. Авылыбызның бүгенге һәм киләчәк буыннары өчен.

***

**Китапта Марсель Гыймазетдинов исеме белән бәйле истәлекләр, шәрехнамәләр, шагыйрьнең үзе язган мәкаләләре, шигырьләр һәм башка материаллар якынча хронологик тәртиптә бирелде.**

***

**Марсель Гыймазетдиновның зур иҗат юлы районыбыз газеталарында мәкаләләр язудан башланды, ягъни ул штаттан тыш хәбәрче булды дисәк тә, ялгыш булмас.**

**Кайберләре белән танышып китик.**

### Сез канат бирдегез.

Илленче ел. Ул елларда илебез зур авырлыклар кичерә, сугыштан соң калган җимереклекләрне торгыза, яңасын төзи иде. Безнең авылда да үзгәрешләр сизелә: азык-төлек ягы яхшыра төште, кием-салым да магазиннарда күбрәк күренә башлады, түбәсе саламнан булса да, йөз баш терлек сыешлы абзар җиткерде ул елны колхозыбыз. Бу кечкенә, тик һәркемне куандырырлык вакыйгалар минем – ул чакта сигез яшьлек сабыйның күңелендә ничек сакланып калгандыр. Хәер, әгәр Гөлсем апабыз булмаса, ул төзелешкә, үзгәрешләргә мин дә, башка кече яшьтәге балалар да игътибар итмәгән булыр идек.

Ул болай булды. Кулына дәфтәр һәм карандаш тоткан бер апа безнең өй бусагасын атлап керде. Исәнлек-саулык сорашкач, әни белән нәрсә турындадыр сөйләште һәм, минем башымнан сыйпап, исememне, фамилиямне сорады. Кем малае булуымны да әйттерде. Мин дөрес җавап биргәч, мактап

та алды. Мин “Марсель” урынына “Малсель” дидем, “р” хәрефен әйтә белми идем, сакау идем.

Әнә шул Гөлсем апа Гайнуллина мине укытырга тиеш иде инде.

1 сентябрьдә, фанердан ясалып, яшелгә буялган “сумка” эченә “Әлифба” китабы, дәфтәр, карандаш салып, мәктәпкә йөгердем. Бик ягымлы елмаеп, безне Гөлсем апа каршылады, беренче тапкыр баскычыннан класска алып керде. Бер класста 22 бала идек.

Беренче таяклар, саннар, хәрефләр... Беренче иҗекләр...

Шушы язмам өстендә утырганда да Сезнең шатлыклы да, борчылулы да, мөлаем да булган йөзегез күз алдымда тора, шактый йөгерек яза торган кулым да, хәрефләрем матуррак чыксын дигәндәй, Сезнең исемне язганда ашыкмыйча, зур ихтирам белән язалар.

Беренче тапкыр безне һәркем өчен кадерле булган Ленин, туган ил, әни, әти, дуслык кебек сүзләрне язарга өйрәттегез. Илебезнең авыр сугыштан җиңеп чыгуы, зур-зур заводлар, фабрикалар төзелүе, йортлар салынуы, җимереклекләрнең торгызылуы, колхозыбызның алга китүе һәм башка бик күп куанычлы хәбәрләр турында сөйли идегез.

Кемнең дә булса семьясында авырлык килеп чыкканда, беренче ярдәм кулы сузучы, җылы сүз белән юата белүче дә сез булдыгыз. Хәтерегездәме, Гөлсем апа, тәнәфес вакытында, башка балалар икмәк ашаганда, Галимҗан бер читтә боек кына басып тора иде. Сез аңа үзегезнең икмәк кисәгеннән өлеш чыгардыгыз. Ул шундый куанды... Заманасы шундыйрак иде шул ул чакта.

Дүрт ел бик тиз узып китте. Тәүге тапкыр атлап кергән бусагадан елмаеп, хәерле юл теләп, безне бишенче класска озаттыгыз. Күзләрегездән, иртәнге чык бөртекләредәй, яшь тамчылары кулыгыздагы чәчәк бәйләмнәренә тамдылар. Ул күз яшьләренең нилектән икәнен без аңламый идек әле ул чакта. Алар шатлык һәм юксыну билгеләре булган икән.

Мин күп нәрсәләргә тукталмыйм, тик шуны әйтәм: сез безне ышанычлы кулларга тапшырдыгыз. Класс җитәкчебез Рәшит абый Бәшәров алты ел буена безнең белән бергә булды, безне күп нәрсәләргә өйрәтте. Әдәбиятка мәхәббәтне Сез уяткан булсагыз, аны дәвам иттеручe Мәсгүдә апа Мөхәммәтдинова булды. Ватан сугышы герое, очучы Виктор Талалихинның үлмәс батырлыгы турында сөйләп, безне рухландырган булсагыз, Гаян апа Әюпова канатларыбызга ныгырга ярдәм итте. Бергә берне ничек кушарга Сез өйрәткән булсагыз, математика фәннәренә булган мәхәббәтебезне Хәй абый Гыйльфанов тирәнәйтте. Әйе, мәктәп бусагасыннан безнең чын кешеләр булып чыгуыбызда Бәзәкә урта мәктәбе укытучыларының өлешләре гаять зур.

Укытучы өчен үзе укыткан укучы һаман бала булып кала. Гөлсем апага элекке укучылары Себердән, Камчаткадан, Казаннан, Мәскәүдән һәм башка урыннардан үзләренең җылы сәламнәрен һәм рәхмәтләрен җибәрәләр.

М.Гыймазетдинов.
“Яңа Кама” газетасы,
30 сентябрь, 1967 ел.

**Хезмәте – җан рәхәте**.
(*Янәшәдә – яхшы кешеләр*)

Бәзәкә авылында яшәүче бу кешегә тиздән 66 яшь тула. Аның биографиясе меңнәрчә башка кешеләрнекенә охшаган. Шулай да аның үз ягы, ниндидер аерым үзенчәлеге бар. Габделхак ага Хөснетдиновка гына хас үзгәлек бу.

Почтальон булып эшли башлаганда, аңа уналты да тулмаган була. Бәзәкәдә коллектив хуҗалык оештырылганнан соң, ул хисапчы, ә товарлы сөт фермасы булдырылгач, аның мөдире итеп билгеләнә.

Бәзәкәдә оештырылган беренче пионер отрядына пионер булып керүен, кулдан тегелгән кызыл галстукны горурланып, муенына тагып, кызыл әләмнәр тотып, бәйрәмнәрдә строй белән йөрүләрен, аннан соң 1932 елда комсомол билеты алуын әле бүгенгедәй хәтерли Габделхак ага. Ә бер елдан комсомоллар аны бертавыштан үзләренең җитәкчеләре итеп сайлыйлар. Хисапчы булып эшләп, 1943 елга кадәр комсомол оешмасына җитәкчелек итә, халык арасында зур аңлату эшләре алып бара. 1942 ел Габделхак Хөснетдинов өчен партия члены булуы белән истәлекле. Бер елдан инде ул шул зур оешмага җитәкчелек итә. Бу зур катлаулы эшне башкару җиңел булмый. Авыл халкы Габделхак агага эш буенча гына түгел, бәлки шәхси тормышларында килеп чыккан теге яки бу четерекле хәлләрдә ярдәм итүне үтенеп киләләр. Колхозның баш бухгалтеры һәм партия оешмасы җитәкчесе кешенең кайгы-хәсрәтен җиңеләйтергә омтыла, авырлыкларны бергәләп кичерә алар. Авыр сугыш елларында Габделхак ага авыл халкы арасында кайнаша, һәр гаиләдә булып,кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырыша. Бәзәкәлеләр аңа шуның өчен хәзер дә рәхмәт белдерәләр.

Күпләр фронттан әйләнеп кайта алмыйлар. Бәзәкә авылы территориясендәге ике колхозның экономикасы ярлылана. Бондюг химия заводы өчен кәрзиннәр, арба, тәгәрмәч, камыт-дуга, диван һәм урындыклар ясау белән шөгельләнүче промартель да эшли авылда.Шушы авыр чорда, 1945 елдан 1957 елларга кадәр, Габделхак ага әлеге оешмага җитәкчелек итә, халыкны дәүләт заданиеләрен үтәүгә тупларга тырыша.

Аннан соң колхозлар эреләндерелә. Хәзерге “Кама” колхозы составына биш авыл керә. Габделхак ага, 1958 елдан бирле, хуҗалыкның баш бухгалтеры. Хатыны Заһирә апа белән бергәләп, алты бала тәрбияләп үстерәләр. Алар да, әтиләреннән үрнәк алып, гомуми эшкә үзләреннән зур өлеш кертәләр.

Еллар үзенекен итә. Инде чәчләренә чал керсә дә, маңгайдагы буразналар тирәнәйсә дә, Габделхак Хөснетдинов яраткан эшеннән аерылырга теләми, ул һәрвакыт вакыйгалар үзәгендә, халык арасында.

М. Гыймазетдинов.
Алабуга,

“Яңа Кама” газетасы, 1980 ел.

**Булдырасыз, егетләр!**

Иртәнге кояш күтәрелеп кенә килә әле. Машиналарга утырган комбайнчылар киң басуны икегә буйдан-буйга аерып торучы посадка янында хуҗаларын көтеп торучы кыр кораблары янына килеп туктадылар. Җәһәт кенә җиргә сикереп төштеләр дә, көлешә-шаярыша, үзләренең комбайннары янына таралыштылар.

– Исәнмесез, иптәшләр!

– Яхшы гына. Әллә безнең белән эшләргә килдегезме? Бик иртәләгәнсез.

– Бик теләп эшләр идем, моннан егерме ел элек без аларны гөрләтеп йөртә идек.

- Онытылмагандыр әле, – дип, “ Прикамнефть” идарәсе электригы, “Кама” колхозына урып-җыюга эшкә җибәрелгән Галиәхмәт Сибгатуллин сүзне дәвам итте.

– Кәефләр ничек соң, егетләр? Уңышлар ничек?

– Болай ярыйсы, эшләр әйбәт бара, тик менә уңышның аз булуы гына кәефне төшерә. Кичә төшкә кадәр ярты басуны урып-сукаладым, бары бер бункер икмәк җыя алдым, ел уңайсыз килде шул, – дип сүзгә кереште шулай ук “Прикамнефть” идарәсеннән машинист-оператор, бүген кыр корабы хуҗасы Габделхәй Җиһаншин.

– Игеннәр бик кыска, быелгы елны саламын да югалтасы килми бит, бик түбәннән кистерергә тырышабыз.

– Шуңа күрә бүген бездә бер теләк: игеннәрнең бөртеген дә югалтмыйча җыеп аласы килә. Әлегә көннәр әйбәт тора, ашлыкларга чык бик аз төшә. Кичә сәгать төнге унберләргә кадәр эшләдек, бүген дә иртәрәк эшкә керешергә исәп, – дип сүзен дәвам итте Галиәхмәт Нуриевич.

Ул “Кама” колхозында бишенче ел инде иген уңышын җыеп алуда катнаша. Социалистик ярышта 1979 елда производстводан колхозга эшкә җибәрелүчеләр арасында район буенча – өченче, 1980 елда беренче урынга чыкты, кыйммәтле бүләкләргә лаек булды. Ә менә быел исә “Кама” колхозы комбайнчылары арасында беренче урында бара. Сезон нормасын ул 1 августка 158 процентка үтәде, ягъни 1490 шартлы суктыру урынына үз бункерыннан 2324 центнер ашлык бушатты. Ике тапкыр район Почет тактасына кертелде. Галиәхмәт Нуриевич – һәр яңалыкта алдан әйдәп баручы.

Ә аның иптәше, тапкыр сүзле, салмак холыклы, физик яктан көчле, тоткан җиреннән өзә торган Габделхәй Җиһаншин “Кама” колхозының уңышын җыеп алуда шулай ук бишенче елын катнаша. Елның-елында районда җиңүчеләр сафында.

Алар белән бергә, бер басуда Алабуга геофизика операторы, “Кама” колхозында бишенче сезонын урып-җыюда катнашучы Геннадий Силантьев, “Прикамнефть” идарәсенең тракторчы-бульдозерчысы Николай Тарасов, “Кама” колхозы комбайнчылары Альмир Сибгатуллин, Избай Абдрашитовлар көчләрен кызганмыйча тырышып эшлиләр.

1981 нче ел уңышын җыеп алуда Бәзәкә урта мәктәбе укучылары да актив катнаша: Дамир Закиров, Фәнис Шиабиев, Руфат Исмәгыйлов, Камил Миңнахметовлар комбайнчы ярдәмчеләре булып эшлиләр.

Комбайннардан ашлык ташуда Алабуга СТК инструкторлары Владимир Тунгусков, Владимир Шалаумов, Гарифҗан Садыйков, “Кама” колхозыннан Хәмәт Шакировлар үзләренең фидакаръ хезмәтләре белән шоферлар арасында аерылып торалар.

– Аларга зур ышаныч баглыйбыз, бик яхшы эшлиләр, иртә таңнан ярты төнгә кадәр безнең комбайннардан ашлык ташыйлар, – диләр комбайнчылар шоферлар турында.

– Без пропискага Бәзәкәгә кердек бугай инде, – дип шаярта Гарифҗан Садыйков. – Чөнки бишенче ел язгы чәчү, урып-җыю вакытында бирედә эшлибез.

Һәрбер комбайнерга хезмәт заданиясе җиткерелгән, көн саен күпме уңыш җыеп алынганы хезмәт кенәгәсенә колхозның баш агрономы Зоя Тарасова тарафыннан тутырылып барыла. Һәр көн саен колхоз буенча алдынгыларга дан җырлаучы “Яшен”нәр, “Сугышчан листок” лар чыгарыла.

– Тик нишләптер агрегатлар янында агитаторлар сирәк була. Күчмә вымпеллар җиңүчеләргә тапшырылмый, алдынгы агрегатларда кызыл флажоклар җилфердәми, – ди Габделхәй Җиһаншин үзенең ризасызлыгын белдереп. – Эштән соң кайтабыз, иртән иртүк эшкә китәбез, комбайнчыларның бүген кайсы алда барганын, кайсы агрегатның күпме ашлык җыеп алганын белмибез.

– Техник ярдәм күрсәтү ничек куелган соң?

–Техник ярдәм күрсәтүдә комбайннарның ватылган частьләрен алмаштыруда колхозның баш механигы Зәки Гыйльфанов бик зур көч куя. Ватылган частьләр урынына төзекләрен бик тиз табып китерә. Үзенең мотоциклына утырып көнгә берничә тапкыр агрегатлар янына килеп китә, зур рәхмәт аңа, – диләр комбайнчылар.

... Сәгать җиденче ярты. Күк йөзендә бернинди болыт эсәре дә юк. Бу, бер яктан, игенчеләрнең киләсе ел уңышы өчен кайгыруын арттыра. Икенче яктан, болай да саран булган быелгы уңышны югалтуларсыз җыеп алуга мөмкинлекләр тудыра. Акрын-салмак кына, иркен басу өстеннән, иртәнге таң җиле исеп үтте. Комбайнчы егетләр соңгы хәзерлекләрен төгәлләделәр дә, баскыч буйлап күтәрелеп, кыр корабы штурвалы артына бастылар. Таң кошлары җырына Галиәхмәт, Габделхәйларның кыр корабларының тигез генә эшләүче моторлар җыры килеп кушылып, киң кырлар өстенә күтәрелделәр. Бу матур җыр – уңыш җыры, тормыш симфониясе белән бүгенге кыр батырлары дирижерлык итәләр. Зур җиңүләр сезгә, ир-егетләр, кыр хуҗалары!

Марсель Гыймазетдинов.<br>Алабуга, «Яңа Кама» газетасы,<br>1981 ел,14 август.

**Татар Тәкәше басуларында.**

Озакка сузылган яңгырлардан соң, көннәр аязып, һавалар җылынып китте: әбиләр чуагы башланды. Алтын көз килде. Колхозчы өчен алтындай кадерле булган бу көннәрдә “Кама” колхозы эшчәннәре үстерелгән бәрәңге уңышын югалтуларсыз җыеп алырга ашыгалар. Аларга төрле оешмалардан килгән кешеләр, укучылар, студентлар булыша.

Без Татар Тәкәше бригадасының бәрәңге басуына иртәнге сәгатьләрдә килеп җиттек. Бәрәңге сабаклары тигез итеп чабылган, басуның аргы башында бәрәңге казыгыч таккан тракторның тигез ритм белән эшләве ишетелә, КТН-1,4 артыннан җир өстенә сап-сары бәрәңгеләр тәгәрәп кала.

Икенче комплексы бригада җитәкчесе Шәяхмәт ага Миңнәхметов белән исәнләшеп, үзебезнең ярдәмгә килүебез турында әйтәбез. Шәяхмәт аганың йөзендә елмаю балкый.

– Бик вакытында килдегез, иптәшләр. Җир өстенә казып чыгарылган бәрәңге күп, көннәр аяз торганда, җыеп алырга иде, - ди ул.

Безнең белән бәрәңге җыюда (без – Менделеевскиның 2 нче кичке урта мәктәбе укытучылары) Алабуга дәүләт педагогия институты студентлары, мәктәп директоры А.Х.Гобәйдуллин һәм укытучы Р.С.Нуриева җитәкчелегендәге ярдәмче мәктәп укучылары эшли. Барысының да күңелләре көр, басу өстендә яшьләрнең шат авазлары яңгырый. Басудан бәрәңге тутырган машина-тракторлар бер-бер артлы китеп тора.

Ярыша-ярыша эшләгәннән соң, безне төшке ашка чакырдылар. Мөнәвәрә Җамалиева, Суфия Миңнәхметова әзерләгән итле аштан, кайнар чәйдән соң, бераз дөнья хәлләре турында сөйләштек. Аннан соң бәрәңге алу, тирес чыгару, гомумән, колхоздагы эшләр турында сүз башланды.

–54 гектар бәрәңге утырткан идек, –дип дәвам итте сүзен Шәяхмәт ага. –Шуның 18 гектары алынды. Җыючылар булмау сәбәпле, эш акрын бара.

– Шәяхмәт ага, уңыш ничек соң? – сүзгә кереште УЭ 148-10ның партия оешмасы секретаре Ш.Ф. Кәшәфетдинов.

– Үзегез күрәсез, уңыш бик мактанырлык түгел – уртача 70-80 центнер.

– Контроль алу вакытында 90 центнер чыккан иде, - дип дәвам итте сүзне бәрәңге казыгычта эшләүче Миңневәҗит Нуриев. – Урыны-урыны белән әйбәт участоклар бар. Тик эш әлләни кызу бармый. Казылган җир күп, җыючылар аз. Шуңа күрә безгә шәһәрдән эшчеләрне күбрәк җибәрсеннәр иде.

– “Икенче икмәк”не ташуда тоткарлык юкмы соң?

– Оешмалар үз машиналарына төйиләр, ә без, бәрәңгене саклау урынына ташып, көнгә бишәр рейс ясыйбыз, - дип тезеп китте алдынгы тракторчы Фәхерлебанат Зәйнуллина. Фәйрүзә Исмәгыйлова да шулай ук биш-алты рейска өлгерә.

– Шәяхмәт ага, бәрәңге алу техникасы ватылып интектермиме соң?

– Ныклап ватылганы юк әле. Вак-төяк ватылулар булгалый. Андыйларны төзәтүдә колхозның алдынгы механизаторы Тәлгать Сафиуллин зур ярдәм күрсәтә. Ул бәрәңге алгычта эшләүчене дә алыштыра. (Бу сүзләрнең дөреслегенә без икенче көнне үк ышандык: Тәлгать җитди сәбәп белән эшкә чыга алмаган Миңневәҗит тракторын идарә итә иде).

– Әнә, уң яктагы асфальт юл буендагы басуны күрәсезме? Анда торф чыгарыла, киләсе ел уңышы өчен көрәш бара. Торф шунда ук таратыла. Ул җир туңга сөреләчәк.

Әлеге басуда торф төялгән тракторлар күренде. Алар йөкләрен тиз генә бушаттылар да яңадан торф төягеч янына юнәлделәр.

–Ашлама чыгаруда тракторчы Мәүлидә Шакирова, Мәүлиха Мөхәммәдинова, төягечтә Габделхак Гыйльфановлар зур тырышлык күрсәтә, һәрберсе көнгә 80-100 тонна торф чыгара, –дип сүзен төгәлләде Шәяхмәт ага.

Сәгатьнең һәр минуты кадерле. Бәрәңге басуы өстендә хезмәт җыры яңгырады. Булачак укытучылар дәртле җыр башладылар. Җыр, киң кырлар өстенә таралып, шуннан ерак түгел урманнан кайтаваз булып еракларга таралды.

М. Гыймазетдинов,
“Яңа Кама” газетасы,
2 октябрь 1982 ел.

***

**М. Гыймазетдинов беркемгә дә, бернәсәгә дә битараф түгел иде. Дусты, күршесе Габделхәй һәм авылдашы Шәрифҗан Ахуновның һаман өйләнми йөрүләренә дә, колхозның яңа ашханәсенең озак вакытлар төзелеп бетә алмавына да аның җаны үртәлде, борчылды. Шул уңайдан, кирәкле вакытта һәм кирәкле урында, тиешле кешеләрне “чеметкәләп”, сатирик шигырьләр дә язды. Менә шундыйларның берсе.**

**Бер төш күрдем**
(шаяру)
Бер төш күрдем бүген, сөйлим әле,
Чынбарлыкка гел дә охшаган.
Төш рас килә,диләр, ул төшләргә
Карт-корылар күптән ышынган.
Дус-ишләрем белән җырлап йөрдем,
Иңләп аккан инеш буенда.
Әй, биедек дустым Габделхәйның
Соң булса да булган туенда.
Шул ук туйның дәвамы булгандыр,
Шәрифҗан Ахунов өйләнде.
Нинди генә җырлар җырланмады,
Кызык-кызык сүзләр сөйләнде.
Бу туйларны күптән көткән идек,
Тәки, малай, туйлар уйналды.
Бөтен авыл тәбриклэп кул чапты,
Каршы кеше бер дә булмады.
Төш дисәң, төш диген: югары очта
Зур ашханә, имеш, салганнар.
Өчпочмаклар, пәрәмәчләр пешә,
Тирләп-пешеп, сөтләп чәен эчтек,
Гөжләп тора зур, җиз самовар.
Тирләп-пешеп, сөтләп чәен эчтек,
Пәрәмәчен тәмләп карадык.
Ашханәне салган кешеләргә
Зур рәхмәтләр әйтеп ташладык.
Менделеевск - Бәзәкә арасында
Автобуслар йөри тезелеп.
Көтәсе юк зәһәр суыкларда,
Төшми эчкә салкын өздереп.
Утырасы да, әйдә, элдерт кенә,
Менә, дуслар, оҗмах кая ул.

. . . . . . . . . . . . . . .
Уянып китсәм, бар да элеккечә,
Төштә генә булган икән шул.
Габделхәй да, Шәрифҗан да буйдак,
Гел саегып калган инеше,
Ашханә дә әле өлгермәгән,
Биш ел ничек – шулай торышы.
Автобуслар зарыгып көтә-көтә,
Эчкә төшә кышның хәтәре.
Төш рас килә, диеп, ялгышалар,
Рас килми икән шул, каһәре.

6 март, 1982 ел .

**Авылым киләчәккә карый.**

Моннан утыз еллар элек Мулланур абый мине ат җигәргә өйрәтте. Ул чакта аңа 25-26 яшь булгандыр. Үзе колхозда ат белән эшли иде. Утыз ел вакыт узып та киткән. Ул дәвердә туган авылым Бәзәкәдә, анда яшәүче кешеләр арасында бик зур үзгәрешләр булды.

Авыл үсте, яңарды. Салам, такта түбәләр – шиферга, калайга, ат-үгезләр – трактор-машиналарга алышынды. Колхоз хуҗалыгы ныгыды. Яңа фермалар калкып чыкты. Кешеләр нарат, кирпечтән салган йортларда яши башладылар. Байтагы нефть чыгаручылар, шәһәр кешеләре булып киттеләр. Шулай да Мулланур абыйның изге җиргә, ата-ана нигезенә, туган туфракка мәхәббәте еллар узган саен көчәйде генә.

…Бәзәкәдә, колхоз оештырылган елларның берсендә, 1930 елда, крестьян гаиләсендә туган. Дүрт класс белем алганнан соң, Ватан сугышының иң хәтәр 1942 елында беренче тапкыр ат җигеп, элеккеге Сталин исемендәге колхозның бәрәңге басуына эшкә чыккан. Сугыш елларының авырлыгын искә алганда, Мулланур абый болай ди:

- Бик авыр булды. Ә без түздек. Чөнки беребезгә дә җиңел түгел иде. Фашист этләрен илебездән куарга кирәк. Һәркемнең уенда бер теләк – дошманнарны тизрәк җиңү теләге генә бар.

Унбер ел буена ат җигеп, колхозның төрле йөкләрен ташыды Мулланур абый. Нинди генә йөкләр күтәрмәде, нинди генә йөкләр ташымады аты белән рәттән тәртә арасына җигелеп. Ул елларны искә алганда, Мулланур абыйның йөзе кырыслана, чигәләре тартышып куя. Чөнки хәзер дә дөньяның тыныч түгеллеген яхшы белә. Баштан кичергәннәр кабатлана күрмәсен дип, бөтен көчен яраткан эшенә бирә.

Унике ел буена төзүчеләр бригадасы бригадиры булды Мулланур Фәссахович. Авыл кешеләре арасында намус белән эшләүчеләр дә, эленке-салынкы йөрүчеләр дә, “яшел елан” белән дуслашучылары да, колхоз милкенә кул сузучылары да булмады түгел. Әмма ул намуслыларга таянды, “адашучыларга” дөрес юлга басарга, тырышып хезмәт итәргә булышты. Хәзер дә, колхозчылар турында сүз чыккач, Мулланур Фәссахович җанланып киткәндәй булды.

- Һәр җирдәге кебек, авылда да барлык чараларны кадрлар хәл итә. Иң мөһиме – кадрлар белән эшләү. Нуриәхмәт Азин, Фәйзелхак Гыйльфанов, Габдулла Гәрәев кебек механизаторлар, Хәлимә Сабитова кебек уңган сыер савучылар булганда, теләсә нинди чаралар да тормышка ашырыла. ТАССР Верховный Советы депутаты, колхозның баш агрономы Зоя Семеновна Тарасова кырчылыкта зур ярдәм итә. Аннан үрнәк алып, яшь агрономнар Илгизәр Баһаутдинова, Резидә Гыйльфановалар үз бурычларын җиренә җиткереп башкаралар. Колхоз рәисе Ибраһим Миндарович та башкаларга салынып тора торганнардан түгел. Һәр эшне башлап йөри, йөкнең авыр башын үз өстенә ала. Андый кеше белән эшләве дә күңелле, дип өстәп куйды Мулланур абый, елмаеп.

- Пенсионерларыбыз да кул кушырып өйдә утырмыйлар. Бригаданың барлык саламын Шакирҗан Садриев, Фәйзерахман Садриев, Мулла Салихов ише пенсионерлар эскертләде. Яшьләр дә колхоз правлениясенең игътибар үзәгендә тора, - дип сүзен дәвам итте ул. – Быел Бәзәкә урта мәктәбен тәмамлаган 10 кыз сыер савучы булып колхозда калды. Хуҗалык җитәкчеләре алар турында кайгырта, уңай эш һәм көнкүреш шартлары тудырырга тырыша. Колхоз правлениясе эшче кешеләрне игътибар үзәгендә тота. Колхозчыларга печән, салам кайтарып бирделәр. Һәр йортка газ кертелгән, утын белән тәэмин ителгән. Аларны ташуда транспорттан тоткарлык булмады.

Җәмәгать терлекләре дә азык белән мул тәэмин ителде. Ел ярымга җитәрлек запас тупланды.

Мулланур абый колхозчылар турында әнә ничек матур итеп сөйли. Чөнки гомере шулар арасында узган, әчесен дә, төчесен дә бергә татыган, бертуганнар кебек яшиләр.

Әйе, авылым киләчәккә ныклы адымнар белән атлавын дәвам итә.

М.Гыймазетдинов,

”Яңа Кама “газетасы,1985 ел.

**Олпат әдипнең юбилеенда.**

1991 елда Казахстанның Күкчәтау шәһәрендә язучы Ибраһим Сәлаховның 80 яшьлек юбилее уза. Бу тантанада Татарстанннан бер төркем язучылар катнаша: Казаннан – Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев, Фоат Галимуллин, Шаһинур Мостафин; Яр Чаллыдан – Рахмай Хисматуллин, Саҗидә Әхмәтгалиева (җырчы); Алабугадан – Тәбрис Миннигулов; Менделеевскидан – Марсель Гыймазетдинов. Шулай ук, Башкортстаннан Фән Вәлиәхмәтов һәм Салават Әхсәнов бәйрәмдә катнашалар.

Ибраһим ага юбилейга килгән кунакларга, шул исәптән М.Гыймазетдиновка да, Казахстан касәләрен бүләк итеп өләшкән.Соңыннан бу касәләрне мин М. Гыймазетдинов музеена бүләк иттем.

Ибраһим Сәлахов үзе Кызыл-Яр авылында яшәп, шунда 85 яшендә вафат була.

Ә юбилей уңаеннан М. Гыймазетдинов аксакал әдипкә шигырь чыгарган һәм аны юбилярга бүләк иткән булган.

**Пәйгамбәр**

(Ибрһим ага Сәлаховка)

Сарман буйларында гына, ай яшел алан,
Печәннәре җитәр икән, һай,бер заман.
Колымада – тамугларда гомерләрем уза,
Шул гомеркәйләремне бит кыскартты ялган.

Шулай җырлый идең эчтән генә,
Үз илеңдә – зиндан төбендә.
Дөреслекнең килеренә ышанулар
Алып чыкты якты көнеңә.

Кимсетүләр, кимсенүләр булды,
Тамугларда күпме янмадың.
Тире белән сөяк арасында
Кысылып кына калды җаннарың.

Сындырырга күпме тырыштылар –
Булдың ныгы корыч-тимернең.
Вөҗданыңа һич тап төшермичә
Тираннарны җиңдең, җимердең.

Ак чәчәкле язлар килде инде,
Ак көннәрдә менә яшисең.
Әүлия дә тиңләшә алмый сиңа,
Зур йөрәкле Кеше, Кеше син.

Әй, Ибраһим ага, ни әйтсәм дә
Бик аз булыр төсле күренә.
Гонаһлардан син гел азаттыр,
Изге булып кердең күңелгә.

Пәйгамбәрдәй Ибраһим дип түгел,
Ибраһимдай диеп пәйгамбәр –
Чагыштырып гел йөрисем килә,
Чын күңелдән әйтәм, кардәшләр.

Озын гомер телик чын күңелдән,
Мәңгелек бул халкым күңлендә.
Тулган Ай һәм Йолдыз булып ян син
Татарстанның зәңгәр күгендә.

Энесе Марсель истәлекләреннән.
Римма Гыймазетдинова,
Менделеев каласы,
1991ел.

**Соң булса да, уң булсын.**

Безнең район битләрендә, менә инде ярты гасырдан артык, яшь каләм тибрәтүче якташларыбыз, үзләренең йөрәк түрләреннән кайнап чыккан

тойгыларын, шигырь, нәсер, хикәягә салып, дөньяга чыгарып укучыларыбызга җиткерә килделәр. Бу матур традиция бүген дә дәвам итә.

Якташларыбыз, Бондюг җирлегендә туып-үскән дусларыбыз хәтерлиләрдер әле: үзләренең матур-матур шигырьләрен газетабыз битләрендә бик актив бастырган Егор Уткин, Дифгать Сираев, Камил Гыйльмуллин, Хәмзә Исмагыйлев, Илһам Кирамов, Илгиз Абдуллин, Әнвәр Зиннәтуллин, Зөфәр Шәйхетдинов, Фәния Шакирова, Николай Климов, Фәйзелхак Хөснетдинов, Азат Мәрданов, Наил Тимербаев һәм башка күп кенә иптәшләр бар иде һәм аларның күбесе хәзер дә бар.

Егор Уткин. Менә дигән биш китап авторы. Рәхимсез үлем аны, нәкъ ир булып һәм шагыйрь булып камилләшкәч, безнең арабыздан суырып алды.

Дифгать Сирай. Камай авылы егете. Типсә тимер өзәрдәй ир-егет безнең арабызда юк инде. Нинди талантлы шагыйрь иде.

Илһам Кирамов. Лирик җанлы, оптимист, яхшы дус, эшчән иптәшебез безнең белән мәңгелеккә саубуллашканга да дистә елдан артык вакыт узды инде.

Нинди гаделсезлек. Илле яшьләре дә тулмаган ир-егетләребез, бәлки булачак танылган шагыйрьләребездер әле, безнең арабыздан китеп, безне, шигърият сөючеләрне, ятим иттеләр.

Бу елның 27 июлендә Бөрешле егете Егор Уткинга 60 яшь тулган булыр иде. Татарстан Язучылар берлеге бу юбилейны зурлап билгеләп үтәргә җыена. Шул җәһәттән мин дә район җитәкчеләреннән, мәдәният бүлегеннән, газета редакциясеннән, туган химия заводы дирекциясеннән, туган якны өйрәнү җәмгыятеннән, музей җитәкчеләреннән шушы олы юбилейны үткәрүдә актив катнашуларын сорар идем. Зур гына комиссия төзеп, Мәдәният сараенда матур гына итеп тематик кичә әзерлисе иде.

Ә без, хәзер дә иҗат итүчеләр, үткәндәге традицияләргә тугрылыклы калып, үзебезнең районда оештырылган, матур-матур кичәләр үткәргән “Ядкарь” әдәби музыкаль берләшмәбезнең эшен яңартып җибәрик.

Каләм тибрәтүче дусларыбыз, барыгызның да 8 март, якшәмбе көнне, Менделеевск район Советының “Менделеевск хәбәрләре” редакциясе урнашкан (Фомин урамы,13) йортка сәгать 10да килүегез сорала. Берегез дә тартынып, оялып тормагыз. Килегез, без сезне көтәбез!

Шигырь, хикәя, повесть, романнар язу оят түгел ул. Андый талант туган чакта ук бирелгән була, язучы булам дип кенә язучы булып булмый. Шуңа күрә, Ходай биргән талантыгызны кешеләрдән яшереп тормагыз-сезнең язган әйберләрегез кешелеккә хезмәт итсен.

Шулай итеп, соң булса да уң булсын, дигәндәй, башлыйк, кардәшләр!

М. Гыймазетдинов,
Менделеевск хәбәрләре, 5 март, 1992 ел

**“Сагыну”**

Шул исемдәге китап. Аны кулыма алу белән бер омтылышта, тынымны да алмадым ахрысы, укып чыктым. Нинди гүзәл, нинди садә, нинди эчкерсез шигырьләр!..

Егор Уткин исемендәге премия лауреаты, шагыйрь Илгиз Абдуллинның тәүге китабы чыгу – минем өчен чиксез шатлык, чиксез бәхет, олуг бәйрәм булды. Бик сөендем. Балалардай, сабыйлардай сөендем. Бәлки Илгизгә караганда да мин көчлерәк сөенгәнмендер әле...Чөнки бу китапны бастырып чыгару, үзенең хисләрен,тойгыларын, уй-фикерләрен, шатлык-кайгыларын, йөрәк моңнарын халыкка ирештерү өчен автор, Тойгуҗа авылы егете Илгиз Абдуллин, күпме көч куйганын, гомерен күпмегә кыскартканын, күпме газаплы төннәр, газаплы көннәр кичергәнен миннән гайре әнисе генә белә торгандыр, дип уйлыйм.

Ярты гасырга якын иҗат итеп, гомер тавын төшеп җиткәндә генә, китап итеп тәртипкә китереп, үзенең җан тетрәткеч шигырьләрен, җан өрүче шигырьләрен, яшәү дәрте өсти торган шигырьләрен шигърият сөючеләргә җиткерә алды. Шигырьләр җыентыгын, нindидер бер изге әйбер тоткандай, кулыма алдым. Кулыма алдым да, тагын бер тапкыр Илгизнең иҗат юлына күз салып, истәлек сандыкларымны барлап чыктым.

Нинди генә талантлар юк безнең арабызда. Нинди генә талантлар, халыкка беленмичә, мәңгелеккә китеп баралар...

Безгә шундый матур мизгелләр бүләк иткәнең өчен рәхмәт сиңа, дустым Илгиз! Кеше гомере комга язылган сүздәй, бик тиз юкка чыга, кеше гомере кайчак галактикаларга да сыя алмастай була.

Син үзеңнең исемеңне җирдә мәңгеләштердең, Илгиз. Хәзерге буын кешеләре байлык, дөнья артыннан куып, иҗатыңны бәяләмәсәләр дә, килер буын, сине укып, сине өйрәнер. Килер буын кызлары шигырьләреңне укып, сиңа гашыйк булырлар, сиңа табынырлар.

Марсель Гыймазетдинов,<br>“Менделеевск хәбәрләре”,<br>7 ноябрь 1992 ел.

***

**Марсель Гыймазетдинов, мәкаләләр белән беррәттән, кечерәк күләмле нәсер, хикәяләр дә язды, ягъни үзен проза жанрында да сынап карады һәм моны уңышлы башкарды.**

**Шомырт чәчәкләре ак кына...**

Хәтереңдәме, икәүләшеп безнең өй каршына пар шомырт агачы утырткан идек ул язны. Җыйнак кына ике чокыр казыдык, ашламалар да сиптек. Агач үсентеләре икебезнеке дә бер чамада иде. Син йөгерә-йөгерә аларга су сиптең: "Үссеннәр иде безнең пар шомыртлар".-дидең.

Ничек булды соң әле, ул язны ничек таныштык соң әле без?

Әйе, син шәһәрдән эти-әниең туып-үскән авылга кунакка кайткан идең. Тугызынчы классны тәмамлаган идең ул елны син. Ә мин урта мәктәпне тәмамларга имтиханнарга әзерләнеп йөри идем.Мәктәптә уздырылган кичәдә мин сине вальс әйләнергә чакырдым. Мин оялчан идем ул чакларда: сүз башларга сүзләр эзләдем – таба алмадым. Шулай да барлык кыюлыгымны җыеп : "Сезне озатырга мөмкинме?" – дип сорый алдым. Син бер сүз дә әйтмәдең, бары, ике яңагыңны матур гына чокырайтып, елмайдың гына. Нәкъ шул минуттан бүгенге көнгә кадәр мин сине күңел түрендә иң нәфис, иң кадерле, иң саф хәзинә итеп саклап йөртәм. Минем өчен язның бу киче бүгенгә кадәр иң газиз кич булып калды. Бу кичтә минем, унҗиде яшьлек егетнең , сөю һәм сөелү бөреләре ачылган, нәфис, беркем дә тиярга хакы булмаган нәни канатлар үскән иң матур , иң саф язгы кич иде.

Мин имтиханнарны уңышлы гына тәмамлап, өлгергәнлек аттестаты алдым. Ә син, һәр имтиханнан соң, мине тәбрикләдең, алдагыларына тагын да яхшырак әзерләнергә киңәшләр бирдең.

Без кичләрен һәрвакыт бергә булдык. Шомырт агачларына син һәр көнне су сиптең.

Нинди генә матур сүзләр эзләмәдем синең өчен. Барыбер бик гади килеп чыга иде минем әйтәсе килгән тойгыларым. Син аларны бик тә якын итеп, яратып кабул итә торган идең. Инде менә имтиханнар да артта калды. Мин бүгеннән үз юлымны үзем сайларга: эшкә керергәме, укырга барыргамы – барысын да хәл итәргә тиеш идем.

Бергәләп болыннарда, ямь-яшел бәбкә үләне белән капланган тау буйларында йөрдек: уйнадык, шаярдык, көлдек.

Хәтереңдәме, икәүләшеп киләчәк турында, Кармантау буенда бер-беребезне бүгенгедәй һәрвакыт яратырга, нинди генә авыр, кыен хәлләргә очрасак та, бер-беребезне ташламаска, киләчәктә, тиздәнме ул, әллә еллар узгачмы, бергә булырга сүз бирештек.

Безнең аерылышу киче дә килеп җитте. Бу кичне үзебез яраткан, безнең серләрне тыңлап торган һәм мәңгелеккә үзенә яшергән тау итәгендә утырдык.

Иртәгесен син киттең. Киттең, үзең белән минем йөрәгемне алып киттең. Үземне кая куярга белмичә, беркем белән дә очрашырга,сөйләшергә теләмичә, соңгы таңны каршылаган тау итәгендә утырган көннәрем күп булды.

Син минем иң беренче мәхәббәтем идең. Бу тойгылар, мондый җан әрнеткеч аерылышулар җир йөзендә яшәүче һәр кеше белән дә була

торгандыр. Чөнки унҗиде яшьтә һәркем ярата, яратыла, һәркем аерылыша, һәркем мәңгелеккә ярата.

Беренче мәхәббәт – мәңгелек мәхәббәт. Әгәр беренче мәхәббәтең белән гомерлеккә бергә булмасаң, башка кеше белән тормыш корып, ничек кенә җиңел яшәсәң дә, кыен тормыш кичерсәң дә - барыбер беренче яраткан кешеңне оныта алмыйсың, син аны һич кенә дә искә төшермичә калмыйсың. Гомер буе үз-үзеңне мәҗбүр итеп , балалар хакына , сиңа яшьлеген , гомерен ышанып тапшырган кеше хакына яши бирәсең.

Без синең белән көн саен хат алышып тордык, көн, аның ничек узуы турында бер-беребезгә яза идек. Бик тә җылы, яшьлек хисе аңкып торган хатлар иде алар.

...Беренче сентябрь көнне мин – интститутка , син унынчы классска укырга бардык. Институт тормышы турында язып тормыйм, шатлык ташып торган, мәңгегә кабатланмас ул тормышта син үзең дә яшәдең.

Институтны тәмамлагач, мине күрше авылга укытучы итеп җибәрделәр. Бераз өс-башларны карап, чак кына акча туплагач, кышкы каникул вакытында синең янга, сөйгәнем янына шәһәргә очтым.

Хәтерлисеңме, син укый торган аудиториядә лекция бара иде. Мин ишек пыяласы аша сине эзләп таптым. Кинәт безнең күзләр: синең иң саф , аяз күк йөзедәй зәңгәр күзләрең белән, сагынып , сагыш катыш очрашу шатлыгы белән тулган минем кара күзләр очраштылар.

Синең яктан, чыгарылыш курс студенткасы тарафыннан, дорфа килеп чыкты чыгуын: кинәт кенә сикереп тордың да ишеккә ташландың. Билгеле, син соңыннан профессордан гафу үтендең. Профессор, эшнең нәрсәдә икәнен аңлады ды, күзлеген салып керсез елмаеп, синең аркаңнан йомшак кына сөйде: “ Яшь чакта минем белән дә андый хәлләр булганы бар иде”, - дип әйтүе иде бу чал чәчле профессорның.

Институт сезнең йорттан ерак булса да, җәяү кайтып киттек. Күбәләк карлар талгын гына бүрек-пальтоларга төшәләр дә, безнең ташып торган йөрәк җылысында эреп, юкка чыгалар. Әй, шатландык та соң без бу очрашуга! Әти-әниләрең дә , мине бик тә якын итеп, үз итеп каршы алдылар.

Икенче көн якшәмбе иде. Без ул көнне бергә үткәрдек: шәһәрне карадык, театрга бардык. Мин ул кичне сиңа тәкъдим ясадым. Син моңа бик шатланып риза булдың, ләкин институтны тәмамлап , диплом алгач, бергә булырбыз дип, мине юаттың, мин-синеке, бары синеке  дип, мине назладың. Мин ЗАГСка барып язылышырга , ә бергә тормыш итүне институт тәмамлагач, ягъни алты-җиде айдан башларбыз, дидем. Без ул кичне төгәл бер карарга килә алмадык. Ничектер уен-көлке белән очлап куйдык.

Беләм, синең тәкъдимең дөрес иде. Җиде ел көткәнне , алты-җиде ай гына көтәрбез инде. Шулай да минем күңел төбендә нindидер бер ят төер калды.

Син-врач, сине - Саратов шәһәренең бер больницасына хирург итеп җибәрделәр. Бүлү комиссиясенә син: “Мин тормышка чыгам, мине Татарстанга җибәрегез”,-дип үтендең. Ләкин комиссия членнары синең үтенечеңне,  синең күз яшьләреңне исәпкә алмадылар. “Әгәр ул сине ярата икән, яныңа үзе килер”, - дип, эшне ансат кына хәл итеп куйдылар.

Эх, әгәр алты ай элек мине тыңлап, имтиханнарыңны бирер алдыннан ЗАГСка гариза биргән булсак...

Мине дә синең янга, Саратовка җибәрмәделәр. Кайчагында кайбер җитәкчеләр кеше күңелен аңламыйлар шул, кеше язмышын кырыс кына хәл итәләр.

Шулай итеп, ничектер җиңел генә язмышка буйсындык, тагын бераз көтәргә булдык.

“Язмыш” дигәнең әллә нинди нәрсә икән ул.Тагын без эшкә чумдык. Башта хатлар еш килсәләр дә, соңга таба сирәгәя башладылар. Аралар салкынаеп киткәндәй тоелды. Бу минем өчен бик тә авыр  хәл иде. Башта “вакыты юктыр, эшләре күптер”,- дип уйладым. Телефон аша сөйләшергә чакырдым. Син телефон трубкасын алып: “Исәнме, сөйгәнем!” дип кенә әйттең дә, елый башладың. Син еладың, ни өчен, белмим. Мин аны бүгенге көнгә кадәр белмим. Тик син бу сөйләшүең белән йөрәгемне телгәләдең, гомерлеккә яра ясадың.

Хатлар килми башлады. Бер ай, өч ай җавап юк. Җәйге отпуск вакытында синең яныңа Саратовка киттем. Ләкин син ул вакытта Новосибирскида уздырыла торган яшь  врачлар семинарында идең...

Көзен чит телләр укытучы кызга өйләндем... Әллә ничек кенә килеп чыкты бу хәл. Ике ел бергә эшләп, бер-беребезне белгәнгәме, укытучылар алдында ярымшаярып ясаган тәкъдимемә риза булды ул кыз.

Минем өйләнүемне авылдагы иптәш кызларың аркылы ишеткәч, син кайттың. Ләкин соң иде инде. Миңа үзенең яшьлеген, сафлыгын ышанып тапшырган кешегә хыянәт итә алмыйм. Без синең белән күрештек, аңлаштык. Гаеп икебездә дә булган икән: гаепнең күбрәген үз өстемә алыдым. Чөнки хакыйкать шулай куша.

Саратовка китеп эшли башлаганыңа ике ай ярым узгач, әниең вафат булган. Бик зур кайгы кичергәнсең. Ник язмадың? Бу хәсрәт артыннан икенчесе: операция ясаганда кулыңны җәрәхәтләп , чир йоктыргансың, больницада бик авыр хәлдә яткансың. Озак яткансың син анда. Ник дус кызларың миңа язмадылар, ник соң дусларың миңа әйтмәделәр?. “Сине борчыйсым килмәде” дисең. Нигә мине, киләчәктә гомергә бергә булырга ант иткән, иң яраткан кешеңне борчымаска!? Бу борчу түгел ич, үзеңнең исәнлегеңне белдерү. Мин белмәдем, хатлар килми башлагач, врач врачны очраткандыр, бәлки безнең арада булган ярату чын ярату булмагандыр, чын яратканын очраткандыр дип уйладым. Гафу ит!

Ни өчен савыкканнан соң үзең язмадың?Мин язмаганга язмадым , дисеңме? Юк, алай кирәк түгел иде. Бәхет өчен, сөйгәнең өчен көрәшергә , горурлыгыңны бераз тезгенләргә кирәк иде...

Соң инде...

Бу синең өчен дә , минем өчен дә җан тетрәткеч фаҗига булды. Беләм, син пар шомырт агачларын сөя-сөя эчеңнән генә, кешегә күрсәтмичә еладың да , шул ук көнне авылдан киттең. Минем бөтен акыл-зиһенемне, йөрәгемне алып киттең.

Соң инде...

Сине ничек сөюемне тойган, гомерлеккә дип тормыш иптәше булган хатыным миңа: “ Гомер буена шулай әрнеп , газапланып яшәрсеңме, балабыз юк чагында аерылышыйк, мин сине бик тә аңлыйм, син аны һичкайчан исеңнән чыгара, мине аны яраткан кебек ярата алмассың” – дип, берничә тапкыр тәкъдим ясады. Ул безнең, синең белән минем бәхетле булуыбыз өчен үзенең бәхетен корбан итәргә әзер иде. Нинди олы йөрәкле хатын! Мин аңа бу сүзләрне башка кабатламаска сүз бирдердем.

Бер елдан кызыбыз дөньяга килде. Хатыным аңа синең исемеңне куштырды.

Мин өйләнгәннән соң , әле син тагын өч ел кияүгә чыкмыйча, мине сагынып, мине көтеп яшәвеңне, егерме җиде тулып , егерме сигезенче яшь киткәч, үзең теләгәнне очратуыңны да, улыгызга минем исемне кушуыңны да, хәзер КамАЗда яшәгәнегезне дә беләм. Бәхет телим. Бәхетле бул...
Без әле дә шул авылда яшибез, эшлибез, ике бала үстерәбез. Әмма...

Мин авылыбызга кайткан саен икәүләп утыртып, су сибеп, карап үстергән пар шомырт агачы уртасында тирән уйга чумып, унҗиде яшь чагыма кире әйләнеп кайтам... Ул агачлар зурлар инде. Ни дисәң дә , гомер уза, агачлар үсә: аларга бит бу язда унҗиде яшь тула. Ни өчендер мин утырткан агач синекенә караганда начаррак үсә. Утыртуым, кадерләвем җитенкерәмәгәндер, күрәсең. Ә синең сылуның ябалдашлары да киңрәк, чәчәкләре дә күбрәк, аның ап-ак чәчәкләре минем агачныкына караганда соңрак та коела.

Һәр яз саен алар ап-ак чәчәккә төренә. Һәр яз саен бер- берсенә яз сәламе, яшьлек сәламе бирәләр. “Исән-сау кышладыңмы, өшемәдеңме?”- дип, бер-берсенә гомернең соңгы көннәренә кадәр бергә үсәргә, бер-берсен җил-давылдан сакларга сүз бирешәләрдер кебек тоела.

Шулайдыр шул, аларга бит бу язда унҗиде яшь тула.

Унҗиде яшь…

Марсель Гыймазетдинов,
14 апрель, 1979 ел.

## Әйтер сүзем калды

(Уйлану)

Күңелемнең иң-иң түрендә, кабатланмас яшьлегебезнең ядкаре булып, сиңа әйтер сүзем калды. Ул сүз бүгенге көнгә кадәр йөрәгемне әрнетә, шул әрнетү сине онытырга мөмкинлек бирми. Шул сүз минем көннәремнең, очар коштай тиз-тиз талпынып, бик тиз узуына китерә. Шул сүз мине киләчәккә ашыктыра. Әйтерсең лә, мин ул сүзне бүген булмаса иртәгә, яисә аның алдагы, киләсе көнендә, синең зәңгәр күзләреңә төбәп карап әйтәчәкмен: кып-кызыл чиядәй мөлдерәп торган иреңнәреңнең әкерен генә дерелдәп: "... Мин дә", - дип әйтүен ишетермен кебек тоела.

Ләкин ул сүзне, бергә чагында һич кенә дә әйтергә батырчылык итмәдем шул. Хәтереңдәме, тау башында яшеллеккә күмелеп утырган авылымның, тирә-як авыллардан ничәмә-ничә буын кешеләре аң-белем алган, якты тормышка юл башы булган мәктәбебезнең хуш исләргә күмелгән кичке бакчасында мин ул сүзне әйтергә дип авыз ачкан идем. Син: "Кирәкми, әйтмә. Хәзергә сер булып калсын. Менә шушы туган мәктәбебез, синең сереңне, син армиядән кайтканчы саклап торсын. Син кайткач, яңадан шушы бакчага килербез, шул чагында ул сүзне миңа әйтерсең", - дидең.

Әйе, ул мәктәп, шул мәктәп бакчалары безнең сабый чагыбызның, бөреләре ачыла башлаган тәүге мәхәббәтебезнең бер шаһиты иде. Ләкин мәгърур булып ераклардан күренеп торган, авылым халкының барчасы белем алган ул мәктәбебез юк инде: һәр язда яшеллеккә, аллы-гөлле чәчәкләргә күмелә торган, бик күпләрнең серен саклаган бакчалар, әйтелергә тиеш булып та, әйтелмичә калган сүзләрне мәңгелеккә үзе белән алып киттеләр. Аларны һич кенә дә кире кайтарып булмый шул! Яшьлегебезнең җуелмас хәтирәләрен саклаган мәктәбебезне сүтеп утынга якканнар: барлык сабый чак хыялларын көлгә, төтенгә очырганнар. Хәер, авылыбызның күрке булып ап-ак, яңа унъеллык мәктәп авыл башында һәркемне сәламләп тора торуын. Шулай да, ул мәктәбебезне бераз төзәткәләп, авылыбызның чал тарихын, кешеләребезнең батырларча хезмәтен сөйләүче музей, пионер лагеры итәргә була иде. Кемнәрнең генә ихтыяр көче җитеп, шул мәктәпне сүтәргә кушты икән? Кемнәр батырчылык итеп сүтте, бакчаларны таптады икән? Бәлки шул мәктәптә тәрбияләнгән, хәзер ир уртасы булган җансыз кешеләр сүткәндер аны. Кемнәрнең генә кулы барып, шул бүрәнәләрне утынга турады, мичендә якты, нәфрәтле җылысында изрәп йокыга талды икән? Мин һәр язның бер көнендә шул биек тау башына менәм дә, бик авыр булганлыктан, алып кителмичә калган туган мәктәбебезнең нигез ташына утырып, тирән уйга чумам... Уйларга чумам. Узган яшьлегебезгә, кайгы-хәсрәт белмәгән шаян, шатлыклы елларыбызга әйләнеп кайтам. Ниләр уйласам да, хисләрнең очы сиңа, әйтелмичә калган сүзгә килеп тоташа. Әйтелми калган сүзем йөрәгемне газаплый. Ни өчендер мин ул сүзне сиңа шул мәктәп бакчасында әйтә

алмыйча калдым. Аны мин сиңа, бары тик сиңа гына әйтергә тиеш идем. Әммә...

Май аеның соңгы төнен без бергә үткәрдек. Табигатьнең дә, кеше күңеленең дә ярсып-ярсып яшәргән, матурланган, нәфисләнгән, сафланган чагы иде ул май ае. Бар җиһан яшеллеккә, ап-ак чәчәкләргә төренгән. Җилнең әсәре дә юк: әйтерсең лә, шул чәчәк исләре барсы бергә кушылып, һаваны куеландырганнар. Шундый гүзәл иде ул май аеның, сөю һәм сөю аеның соңгы төне. Без таң атканчы җитәкләшеп авылыбызның барлык урамнарын әйләндек, авыл читендәге яшел уйсулыкларны буйладык, мәктәп тау башларында йөрдек. Җырламаган җырыбыз, сөйләшмәгән сүзебез калмады. Әмма бер сүз, бары бер сүз әйтелмичә, тел очына җитеп тә, әйтелмәгән бер сүз калды.

Саубуллашканда син: “Мин сине көтәрмен!” – дип кенә әйтә алдың.

“Мин сине көтәрмен!”

– Бу сүзләр әле дә минем колак төбендә. Кайчагында, җиз кыңгырау каккандай, зеңгелдәп яңгырыйлар, кайчак назлы моңлы бер җыр, май аеның соңгы киче булып, күңелемне ярсыталар, җилкендерәләр...

Ике елдан соң мин , сержант погоннары тагып, туган авылыбызга әйләнеп кайттым. Ләкин син, авыл башына чыгып: “Мин сине көттем”, - дип, каршы алмадың. Син минем кайтуымны көтмичә, Алабуга шәһәрендә яшәүче бер егеткә тормыш юлдашы булган идең инде.

Ел ярым буе атна аралаш хатлар алышып торсак та, ун көнлек ялга кайтып, мәхәббәтебезне яңартып китсәм дә, син минем кайтуымны көтмәгән идең... Бәлки шулай кирәк булгандыр... бәлки...

Әнә шул “бәлки”ләр бүгенге көнгә кадәр мине газаплыйлар, йөрәгемне телгәлиләр. Авыр булды шул миңа бу газапны кичерү... Йөрәгемне, үз-үземне кая куярга белмәгән минутлар бик күп булды. Шундый газаплы хисләргә күмелеп, мин мәхәббәтебезнең нигез ташында тирән уйга чумып күп утыра торган идем. Әммә түздем, бирешмәдем.

Билгеле, син аның белән бәхетле түгел идең. Мин шулай икәнен күңелем белән тойдым: синең хакта кешеләр дә бик күп хәбәрләр җиткереп тордылар. Башта ирең белән начар торуыңа шатланган идем. Чөнки минем сиңа нәфрәтем чиксез көчле булды. Тора-бара синең өчен борчыла башладым. Синең кайгы минем кайгыга, шатлыкларың минем дә шатлыкка әверелде. Тик син генә аны белми идең...

Бүгенгедәй күз алдымда: без автобуста очраштык. Син автобусның - бер, мин икенче башында идек. Безнең күзләр көтелмәгәндә очраштылар. Карашларыбызны ничек кенә читкә алырга тырышсак та, булдыра алмадык: нииндидер бер тылсымлы көч ирек бирми иде. Бер-беребезгә шулай күпме карашып торганбыздыр – белмим. Кондукторның соңгы тукталыш икәнен белдерүе безне тирән уйлардан айнырга мәҗбүр итте. Кинәт сискәнеп уянып киткәндәй булдык. Син уңайсызланып, югалып калдың. Әммә мин сине кыен

хәлдән чыгарырга тырыштым: хәл-әхвәлләреңне сораштым. Син бары тик “яхшы”, “ярыйсы”, “әйе шул”- дип әйтүдән узмадың. Озын керфекләреңнең чылануын, мөлдерәмә тулган күзләреңне күрсәтмәскә тырышып, ашыгам дип китеп бардың. Ә мин сине җылы карашым белән күздән югалганчы озата бардым. Бик тә авыр иде шул бу минутларда миңа. Менә шул мөлдерәмә тулган күзләр биш ел буе мине эзәрлекли, төшләремә кереп тилмертә, йөрәгемне телгәли, әрнетә. Шул күзләр миңа бүгенгәчә тынгылык бирмиләр... Миңа кылган хыянәтеңне инде күптән гафу иттем. Бәлки, ул хыянәт тә булмагандыр. Язмыш шулай кушкандыр. Дөнья бит бу. Ниләр генә булмый, ниләр генә эшләнми бу якты дөньяда.

Сайлаган тормыш иптәшең сиңа хыянәт итте, синең өстән башкалар белән йөрде. Балаң дөньяга килгәч, сине тагын да кыерсытты, тагын да көчлерәк җәберли башлады. Син түздең: “Үзем ялгышканмын икән, үзем гаепле”, дип, бу мәсхәрәләргә түзә килдең. Һәм, ниһаять, түземлелегеңә чик куелды: биш яшьлек балаңны алып, аннан китәргә мәҗбүр булдың. Ә ул, икенче көнне үк, сөяркәсен хатынлыкка алып кайтты.

Эшли торган коллектив кешеләре дә, иптәшләрең дә синең кайгыңны уртаклаштылар, киңәшләре белән синең хәсрәтеңне бүлештеләр. Җәмәгатьчелек ярдәмендә иреңнең чын йөзе ачылды һәм ул шәһәрне, эш урынын калдырып, сөяркәсе белән Төмән якларына чыгып китте.

Менә хәзер елга якын тол яшисең. Мин сине элеккечә якын итсәм дә, элеккегә караганда ныграк яратсам да, синең тарафка килергә батырчылык итмим: кимсетермен кебек тоелам. Ни өчен дисәң, мин аерылышкан майның соңгы төнендә сине бәхетле итәргә сүз биргән идем, шул биргән сүземә тугрылыклы булып каласым килә. Бәлки мин синең янга килеп кыерсытырмын, бәлки шул килүем белән йөрәк яраңны кузгатырмын, газапларга салырмын кебек тоела. Шуңа күрә дә яныңа килеп, җиде ел элек әйтелми калган сүземне бүген дә әйтергә батырчылык итмим. Ә минем сиңа әйтер сүзем бик тә бар. Ул сүзне мин бүген булмаса – иртәгә, яисә аның киләсе көнендә үзеңә генә сер итеп әйтәчәкмен. Ә хәзергә әйтә алмыйм, бары тик яза гына алам. Чын йөрәктән чыккан, бары син генә ишетергә лаек булган ул сүзне бүген мин туган мәктәбебезнең, бик тә авыр булганлыктан, алып кителмичә калган нигез ташына зур хәрефләр белән, ераклардан күренеп торырдай итеп, язып куярмын. Син биек тау башына күз сал әле: яшьлегебезнең ядкаре булган ул сүзләр ераклардан ук күренеп торалар: “Мин сине өзелеп яратам!...”

Марсель Гыймазетдинов,<br>“Яңа Кама” газетасы,<br>31 декабрь 1983 ел.

## СЫЕРЧЫКЛАР КИТӘЛӘР, БЕЗ КАЛАБЫЗ...

(Чыпчык монологы)

Нәсер

Кешеләрне һич кенә дә аңлап бетереп булмый. Һәркайсы – табышмак. Табышмакның да чишә алмастае. Табышмакларның төрлеләре булган кебек, кешеләрнең дә төрлеләре була.Яхшылары, кече күңеллеләре, эчкерсез, юмартлары булган кебек, хәйләкәрләре, мәкерлеләре, саранннары, һай, яманнары да бар кешеләрнең.

Менә без, чыпчыкларга, һәрчак кешеләр арасында күбрәк булырга туры килә. Кышын, җәен дә, көзен, язын да – гел кешеләр арасында булабыз без. Чөнки безнең якларда табигатьнең дүрт фасылы да була торган бер үзенчәлелек бар. Яз урталарыннан алып, җәй аша көз урталарына кадәр безнең, чыпчык ише җан иясенең, кайбер вак-төякләрне искә алмаганда, хәсрәт-кайгылары юк дияргә була. Без ул чорларда кешеләр янына сирәгрәк килергә, аларны артык борчымаска тырышабыз. Чөнки, үзегез беләсез, табигать бу фасылларда безгә үзенең назлы да, юмарт та, рәхимле дә, азык-төлеккә, орлык-җимнәргә, чык-суларга бай булган кочагын иркен итеп ача. Тик кадерен генә белергә кирәк ул чакларның!

Ә менә инде салкын көзләр җитеп, безне җылытучы да, туйдыручы да булган рәхимле Җир-Ана өстенә кырпак карлар төшкән көннән башлап, май айларына кадәр безнең өчен хәсрәтле, борчулы чорлар башлана.

Минем сезгә сөйлисе кечкенә генә хикәятем дә узган ел нәкъ менә шул салкын кыштан соң бик тә ягымлы, бик тә яхшы күңелле күршеләребезЧыпчык һәм Чыпчыкбикә белән булган бәхетсезлек турында.

Хикәятемнең башы да кешеләр турында сөйләү белән башланган иде, шул сүземне дәвам итәм. Аңлый алмыйм мин кешеләрне. Иртә яздан ук кешеләр, җылы яктан әйләнеп кайтучы кошларны, оялар әзерләп каршы алалар. Мин тора торган түбәнең йорт хуҗасы малае Марат, узган язда өч сыерчык оясы ясап, юан тополь агачының урта өлешенә бау белән бәйләп, беркетеп куйды. Шул ук көнне ул ояларда сыерчыклар өй туе ясадылар. Талпына-талпына сайрадылар. Янәсе, рәхмәтләрен белдерделәр кешеләргә.Әгәр дә безгә дә шулай кадер-хөрмәт булса, без дә шулай шатланмас идек мени?! Без, чыпчыклар, салкын кыштан куркып, кешеләрне ташлап, җылы якка китеп бармыйбыз. туган якларыбызда, туган төбәгебездә яшәп калабыз. Яңгырлы көздә дә, салкын кышта да, буранлы язда да гел кешеләр арасында булабыз. Үзебезчә җыр да сузган булабыз, сандугач, сыерчыклар кебек сайрый алмасак та, узебезчә, чыпчыкларча җырлап-чыркылдап, кешеләргә үткән җәйне хәтерләтеп, киләчәк язга рухландырып, күңелләрен күрәбез. Кешеләр арасында безне аңлаучылар да юк түгел, бар алар, бар. Кыш көннәрендә азык-җим таба алмый башлагач, кайберләре фанера кисәкләрен агачларга бәйләп, шуларга җим салалар. Без чыпчыклар, якын туганнарыбыз песнәкләр белән, аларга бик зур рәхмәтләребезне белдерәбез. Җылы якларга китмичә, алар белән бергәләшеп, кышның

рәхимсез салкыннарына бергә-бергә каршы торганыбызны алар бик тә аңлыйлар. Тик андыйлар азлар шул, азлар...

Кешеләр безне үзләренә зыян китерүчеләр дип саныйлар инде, билгеле. Без аны беләбез, инкарь итмибез. Бодай-тарыларны бераз чүплибез-чүпләвен басуларда, амбар, ындыр табакларында. Ни хәл итәсең инде, шушы фани дөньяга шулай яратылганбыз,монда безнең ни гаебебез бар соң? Без дә бит бакчаларны корткыч бөҗәкләрдән арындыруда үзебездән байтак кына өлеш кертәбез. Шуны әйтәсем килә, кешеләргә китергән зыяныбызны эшләгән файдабыз белән каплыйбыз без, ышансагыз.

Шулай да кешеләр безне гел кыерсытырга гына торалар. Ни өчен икәнен аңлый алмыйм.

Бер генә мисал китерәм мин сезгә: әле бер генә кешенең дә чыпчык оясы ясап куйганын күргәнем юк бу якларда. Күбесе сыерчык оясы ясый.

Минем белән бер түбә астында яшәүче күрше чыпчык иртә язда өй кыегына беркетеп куелган сыерчык оясын бик яхшылап чистартты. Берничә көн чистартты ул ояны: узган ел сыерчыклардан калган чүп-чарларны, тизәк-мамыкларны ташып читкә түкте. Авызына кар сулары кабып ташып, матурлап юды. Минем киңәшемә колак салмыйча, мамыклар ташып җылы урын әзерләде һәм биш йомырка салды.

Йомыркалары өстендә атна-ун көн утырганнан соң, ояга җылы яктан әйләнеп кайткан бер пар сыерчык килеп кунды. Куна-кунуга, эти сыерчык ояга башын тыгып карамакчы булды, әммә шунда ук башын оядан алды. Ниндидер хәвеф –хәтәр булгандай, икесе дә ят-яман тавышлар чыгарып, чыркылдый-чыркылдый оя тирәли оча-әйләнә башладылар. Бу көнне бик озак әйләнделәр алар шул оя тирәли. Ата чыпчык ана чыпчыкка ярдәмгә килеп тә карады, кая ул, теге сыерчыклар аны ояга якын да җибәрмәделәр. Икенче, өченче көнне дә шундый ук хәл кабатланды. Ана чыпчык, авызына бернинди азык та, тамчы су да капмыйча, дүрт көн утырды йомыркалары өстендә. Ташлап чыгып китәр иде бераз тамак ялгарга, булачак нәниләрен һәлакәт астына куясы килмәгәндер инде. Юкса, аның йомыркаларын сыерчыклар күз ачып йомганчы чәрдәкләп бетерәчәкләр.  Ана чыпчык, балаларының язмышы өчен зур җаваплылык тоеп, ояда утыруын дәвам итте. Бишенче көнне дә теге сыерчыклар ояга керү юлын һөҗүм иттеләр: ояны чукыдылар, канатлары белән шап-шоп суккаладылар. Әммә ана чыпчык ояны калдырып чыгып китмәде. Ата чыпчык, авызына суалчан кабып, бик күп тапкырлар ояга очып керергә омтылды. Барысы да уңышсызлык белән тәмамланды. Соңгы килүендә, пар сыерчык икесе берьюлы, уктай очып, ата чыпчыкка ташландылар.Йон-мамыклар очты. Шуннан соң ата чыпчыкның оя янына очып килгәне күренмәде. Шундый тавыш-гаугада алты көн үзып китте. Җиденче көнне ни күрим, тавыш-тынсыз гына ояга ана сыерчык кереп китте дә, авызына үлгән чыпчык гәүдәсен кабып килеп тә чыкты. Шул арада минем күршемнең җансыз гәүдәсе биек, юан тополь ботакларына бәрелә-

сугыла аска, яңа гына шытып чыккан хәтфә-җәймә “биби” үләне өстенә килеп төште. Аның артыннан берәм-берәм йомыркалары да җиргә төшеп, чәлперәмә килделәр. Йомыркалар эченнән, яңа гына яралып килгән, әле яңа гына җан керергә өлгергән нәни чыпчык балаларының гәүдәләре дә, шул хәтфә келәм өстендә, әниләренең җансыз гәүдәсе янында ятып калдылар...

Шул ук көнне, озак та үтмәде, теге пар сыерчык оя түбәсенә басып, башларын мәгърур югары күтәреп, үзләренчә, сыерчыкларча,

Аңламассың кешеләрне. Ни өчен соң алар ояларны безгә, ел әйләнә үзләре белән бергә яшәп, тормышның әчесен дә, төчесен дә бергә-бергә кичерүче, туган төбәкләреннән беркая да китмичә яшәүче чыпчыкларга атап ясамыйлар икән? Вакытлыча гына килгән яз, җәйнең барлык рәхәтлеген алып, көз җитү белән яңадан кешеләрне ташлап китүче сандугач, сыерчыкларга гына атап ясыйлар икән ояларны? Аңламассың кешеләрне...

Марсель Гыймазетдинов.

Менделеевск шәһәре,

“Октябрь байрагы” газетасы,

4 январь 1990 ел.

**Мизгелләр... Хатирәләр...**

(Ялгыз уйлану)

Гомер узган саен, күңелләрне җилкендереп , яшьлек еллары искә төшә. Искә төшә дә, йөрәкләрне сулкылдатып, чеметеп-чеметеп ала. Күңелләр тула. Юксынудан нәрсәнедер, кемнедер сагынудан күзләргә яшьләр килә. Әмма без еламыйбызз. Юк, еламыйбыз инде. Еларга, үкенергә соң инде. Узганнарны һич кенә дә кире кайтарып булмый шул.

Менә бүген дә, әллә ничек иртәдән үк күңел җилкенә, башка төрле-төрле уйлар килә, яшьлек елларыбыз, җиз кыңгырау челтерәгән тавышлар чыгарып, күз алдыма килеп баса. Мин яшьлегемә әйләнеп кайтам...

Күрше тирә-як авыллардан безнең мәктәпкә укырга йөзләгән укучылар килеп йөри иде. Иң ерак авыл – Таш Чишмә авылы. Егерме биш чакрым җирне һәр дүшәмбе һәм шимбә көннәрен җәяүләп үтә торган иделәр укучылар. Аркаларында капчык, кулларында төенчек булыр иде аларның. Илдус, Минемулла, Нургали, Асия, Сания, Илсөяр, Наилә - мин сезне онытасым юк. Без шундый якын дуслар идек. Кайда сез? Кай җирләрдә яшисез сез, ташчишмәле дусларым?

Әле дә хәтеремдә. Илдусның күзе Мәүлидәгә төшкән иде. Ярата иде Илдус аны. Ярата иде. Тау башына урнашкан , яшьлегебезнең бөреләре ачылган мәктәбебезнең бер бүлмәсендә сөйләшеп утырган бер гөнаһсыз ике йөрәкне – Илдус белән Мәүлидәне күпме әрләделәр, күпме сүкмәделәр безнең мөхтәрәм укытучыларыбыз. Әле аларга унҗиде генә яшь иде бит ул чакта. Нәрсәләрдә генә гаепләргә тырышмадылар аларны...

Балачак, яшьлек дустым Габделхәй дә Наиләне - иң беренче тапкыр Аны яратты. Минегали дустым Фәния өчен күпме өзгәләнеп йөрде...

Шулай инде ул, язмыш икенче төрле эшләде...

Безнең мәктәбебез бик киң күңелле иде. Анда өч сменада укырга туры килде. Бар иде заманалар... Әтәс авылыннан Гөлсәрия мәктәпкә килеп керсә, кояш чыккандай – мәктәп яктырып китә торган иде. Һәрчак елмайган , һәрчак көләч йөзле , матур иде ул. Әле хәзер дә шулай ул Гөлсәрия. Мәүлидә дә, авыр тормышта үсүенә дә карамастан , һәрчак шаян, мөлаем, матур һәм мәхәббәтле иде... Аларга инде илленең теге ягына чыгарга туры килде бу елларда. Гомер уза. Яшәү дәвам итә. Гөлсәрия, Мәүлидәләр гомер буена үзләренең профессияләренә тугрылыклы булып калдылар. Алар бездән 2-3 яшькә өлкәнрәк иделәр. Әмма, алар безнең күңелләрдә аерым урын алдылар.

Мәктәбебезнең иң матур кызы Гөлүзә дә , үзе матур, үзе яхшы укучы, үзе шаян , үзе тәртипле – бүгенге көндә туган авылыннан беркая да китмәде, тупырдатып өч ир-егет үстереп бирде туган колхозына. Өчесен дә агроном итте. ..

Якын дустым Сәетҗан да үзенең туган төбәгенә тугрылыклы булып калды: туган авылы тирәсендәге авылларда укытып , мәктәп директоры булып йөрде дә, туган авылына кайтты. Бүгенгесе көндә районыбызның иң алдынгы исәпләнгән Тукай исемендәге колхоз белән җитәкчелек итә... Тамырларың имәннекедәй тирәнгә китсен, Сәетҗан дустым. Без – бу төбәк кешеләре. Без монда тудык, монда үстек, монда эшлибез, мәңгелек йортыбыз да шушында булсын... Амин... Куркып эшләмә. Дөреслекне таш яргандай ярып әйт. Синең белән әйтәсе сүзләребез бар әле безнең киләчәктә. Ә ул киләчәк ерак түгел. Дөрес бул. Кешеләрне рәнҗетә күрмә, дустым. Дөньяга кеше мәңгелеккә килмәгән. Бездән дә бу дөнья калачак. Кешеләргә яхшылык эшлик, яшьлек дустым...

Безгә унҗиде яшь. Без егет-кызлар булып киләбез. Мәктәптә атнаның пәнҗешәмбе көнне һәрвакыт кичәләр оештырабыз. Биибез, җырлыйбыз, танец әйләнәбез. Аннан соң кайсыбыз - өйләренә, читтән килеп укучылар иске мәчеткә - интернатка кайталар. Без, егетләр, кызларны озата кайтабыз. Кызларыбыз ашыгалар: Мәсгүдә апа, Лена апа ачулана, имештер. Ниләргә генә ашыктыгыз соң сез, сөеклеләребез? Ачулансыннар, шелтәләсеннәр, сүксеннәр иде. Ашыкмаска, күбрәк безнең белән бергә булырга тырышырга кирәк иде. Менә хәзер ул чакларны кире кайтарасы иде. Күктән ташлар яуса да игътибар итмәс идек. Ашыкмас идек, Илсөяр, Рәүҗидә, Шәмсия, Тәскирә, Фәния, Наилә, Рәсимә, Гөлүзә, Сания, Асия... Дөньяны сулар басса да , сездән аерылмас идек.

Уйлар, уйлар... Хыяллар. Хәтерлим, 1961 нче Яңа елны мәктәптә каршыладык. Яңа ел бал-маскарадында бик матур биедек, уйнадык, күңел ачтык. Балдан соң кызларны озата киттек. Ап-аяз айлы төн. Бөтен тирә-як ап-ак. Безнең кызларның да күлмәкләре ап-ак . Итекләре дә ак. Шундый

гүзәлләр, шундый матурлар. Күзләрендә очкын , яңак-битләре салкыннан алсуланып тора иде без интернатка кергәндә. Тәрбиячеләре , безнең бәхеткә, юк иде. Без рәхәтләнеп сөйләшеп утырдык егермеле лампа уты яктысында. Нинди рәхәт иде, шундый кабатланмас мизгелләр иде алар... Минем бүгенгедәй күз алдымда: Илсөяр йөгерә-йөгерә чәй кайнатты. Наилә Яңа ел күчтәнәчен өстәлгә куйды. Рәхәтләнеп чәй эчтек. Нинди матур иде Илсөяр бу мизгелләрдә... Менә шул мизгелләр гомер буе күңелемә тынгылык бирмиләр, уеп-уеп алалар да, күңелләремне моңга салалар. Гомеребезнең ахырына кадәр саклый алмадык шул без ул мизгелләрне. Тугры булып кала алмадык шул без беренче мәхәббәтебезгә. Әйтегез әле, кем беренче мәхәббәтенә тугры калды? Әйтегезче?

Чыгарылыш имтиханнары беренче июньдә. Беренче имтиханны, икенчесен дә, өченчесен дә тапшырдык. Дүртенчесе – химиядән. Һәр имтиханга чәчәкләр алып киләбез. Бу юлы да иртән иртүк тордык та, дустым Габделхәй белән сирень  чәчәкләре өзеп (сәгать иртәнге дүртләр тирәсе иде) интернатка кертеп куймакчы булдык. Чәчәкләрне Илсөярләр, Рәүҗидәләр алып барырга тиеш иделәр. Интернат ишегенең келәсен тимер чыбык белән ачып җибәрсәк, каршыбызда Лена апабыз басып тора. Югалдык та калдык. Ә Лена апабыз безне, химиядән имтиханнар вакытында “провал” ясарга вәгъдәләр биреп, интернат ишеге төбеннән борып җибәрде. Билгеле, химияне без барыбыз да, укытучыбыз Фирая апабызны яраткандай, яратып, тырышып үзләштердек. Имтиханнарыбызны уңышлы гына тапшырдык без ул көнне. Мәрхәмәтле Лена апабыз да безгә чын-чынлып ярдәм итте имтиханда. Ул профессиясе буенча биология, химия укытучысы иде...

Педагогия институтына дустым Сәетҗан, Фәния, Илсөяр һәм мин укырга кердек. Илсөяр бер-ике генә ай укыды да, институтны калдырып, авылларына сыер савучы булып эшкә урнашты. Курыкмый иде ул эштән, ниндие генә булмасын, ерып эшли иде. Илсөяр – Тукай авылы кызы. Соңгы тапкыр без аның белән  Сабантуйда очраштык һәм гомерлеккә аерылыштык.

Заманаларның, дөньяның, тормышның җиңел, рәхәт чагын кем белә, әйтегезче? Дөнья, тормыш һәрвакыт авыр булды инде ул. Без- сугыш елы балалары. Туганнан башлап авызыбызга сөтсез имекәй алганбыз инде без. Аннан,сугыштан соң дип, җимереклекләрне торгызгач, җиңел тормыш киләчәгенә ышанып, ачлы-туклы яшәдек. Кигән күлмәктән, ыштаннан, сырган сырмадан башка нәрсәбез бар иде соң безнең? Сыер җигеп, әрәмәдән утын, күрән ташыдык, җәйләр буе “уфалла” арбасы белән сыерга азык әзерләдек.

... Эчә торган иде Галимҗан абый. Үзе менә дигән оста тимерче иде. Бәлки, эчмәсә, шундый оста тимерче дә була алмас иде.  Шуңа күрә эчкәндер дип тә уйлап куям хәзер. Әнкәй, караңгы төшүгә дә карамастан, әрәмәдән утыннан кайтып кермәде. Без апа белән пошаманга калдык. Төн караңгы, тик кар яктысы гына бераз караңгылыкны агарта төшә. Ярты төн дигәндә, сыерга

җигелгән чанага утырып, әнкәй кайтып керә. Соңга калуының сәбәбен безгә сөйләп бирә. Утын төялгән чана, чалулап читкә чыккан. Йөкне тотып кала алмыйча, әнкәй йөк астында калган. Сыер карга кереп баткан. Шул рәвештә алар бик озак ятканнар. Әрәмәлек аша Бондюгтан кайтып килүче Галимҗан абый очрамаган булса, бәлки без, ике сабый, ятим дә калган булыр идек. Рәхмәт, яткан туфрагы җиңел булсын Галимҗан абыйның. Әнкәй шуны миебезгә сеңдерде: кешеләрне яхшыга, начарга аермагыз. Үзегез яхшы булсагыз, кешеләр дә яхшы, үзегез начар булсагыз, кешеләр дә начар булырлар. Кешеләргә һәрчак яхшылык эшләргә тырышыгыз, диде. Без кешеләргә һәрвакыт яхшы мөгамәләдә генә булырга гомер буе тырышабыз инде...

Заманалар бүгенге көндә дә авыр. Бәлки, киләчәктә яхшырыр әле. Заманаларны җиңеләйтәсебез килсә, бөтен көчебезне хезмәткә бирергә кирәк. Тege вакыттагы кебек, сугыш һәм сугыштан соңгы еллардагы кебек... Бер сызган таякка түгел инде, акчага, эш хакына. Хәер, теге елларда да ул таякка – хезмәт көненә бернәрсә дә бирмиләр иде, хәзерге көндә алган акчабызга магазиннарда бернәрсә дә юк. Тарих кабатлана түгелме соң?..

Бүгенге көннәргә тукталып тормыйк, яшьлегебезгә әйләнеп кайтыйк әле... Бетмәс бу дөньяның мәшәкате...

Сагындыра, сагындыра шул яшьлек елларыбыз. Элек заманалар авыр булса да, яшәве ничектер рәхәтрәк иде кебек. Кешеләрнең кечесеннән алып өлкәненә кадәр киң күңелле, мәкерсез күңелле кебек иде, ахрысы. Булгандыр инде кешеләр арасында эчкерлеләре дә, мәкерлеләре дә. Бар иде алар ул елларда, бар иде. Әрәмәгә тал утынына барганда да, без, сабыйлар, кесәбезгә “чәкүшкә” тыгып төшә идек. Урман хуҗасы...Нур абзый очрап тотса, аңар бирербез дип. Еш очрый торган иде ул урманчы, еш кына “чәкүшкәләр”анының тамагына күчә торган иде. Безнекен генә түгел инде, билгеле...

Түздек, чыдадык. Җиңдек бар кыенлыкларны. Үсеп җиттеләр минем дусларым. Ир-егетләр, буй җиткән кызлар булдылар. Кайберләребез”әти” сүзен гомер буена да әйтмәгәннәребез бар иде. Барыбер үстек. Әниләр үстерделәр. Әтиләрдән ким үсмәдек үсүен, шулай да күңелләребезнең бер кырые китек иде. Аталы балалар “әти” дигәндә, күңелләребез томырылып, каядыр упкынга төшеп киткәндәй була торган иде. Кайберләребезнең әтиләре изге сугышта, кайберләребезнең сугыштан соң үлеп китте. Минем әтием дә, 1948 елда, безне ятим калдырып, бу дөньядан китеп барды. Авыру иде шул ул.

Үстек, барыбыз да үстек. Инде үзебез әти-әниләр булдык, кайберләребез инде әби-бабай да булды. Тик барыбызның да бер теләге бар: безнең балалар ятим үсмәсеннәр иде. Шуңа күрә дә, менә мин, барлык классташларымны, яшьтәшләремне берәмтекләп барлап чыктым: беребез дә ике тапкыр өйләнмәгәнбез, беребез дә ике тапкыр кияүгә чыкмаганбыз, ахрысы. Димәк, бер бала да ятим калмаган...

Уйлар, уйлар... Күз алдымда – балачагым мизгелләре, уйларымда – яшьлегем хатирәләре. Шуларның барысын да сәйләндәй тезеп, бер китап бастырып чыгарасы иде. Ул китапта яшьлек елларыбызны бергә үткәргән дусларымның кадерле исемнәре язылсын иде. Минем бу язмам, кайтаваз булып, дусларымнан хәбәрләр китерсен иде. Шундый татлы ул балачак, яшьлегем мизгелләре , шундый кадерле ул яшьлегем хатирәләре... Сезнеңчә ничек?..

М.Гыймазетдинов. Бәзәкә авылы.
“Менделеевск хәбәрләре” газетасы, 1992 ел.

***

**М. Гыймазетдинов турында язылган күпсанлы мәкаләләр районыбыз һәм республика газеталарында даими чыгып тордылар һәм аның оста җитәкче, кешелекле, тырыш, яңалыкка омтылучан, үзгәрешләрдән курыкмаучы, үтә сәләтле, башка бик күпләргә үрнәк кеше, эшлекле рәис булуын газета укучыларга җиткерделәр**.

## “Җирне яшәртергә сүз бирдек”

“Авылга – адреслар” рубрикасы “Татарстан яшьләре” газетасында 1987елның февралендә ачылды.Анда авылга даими эшкә күченеп килергә теләүчеләр өчен Татарстанның төрле районнарыннан адреслар бирелде.Алар арасында Менделеев районының Тукай исемендәге колхоз председателе М.Гыймазетдинов хаты да бар иде. Хужалык житәкчесе колхозның бүгенгесе һәм иртәгесе көндәге тормышын тасвирлаганда эшкә килергә теләүчеләрне кызыксындырырлык вәгъдәләр дә бирмәгән, әлегә чишелеп бетмәгән проблемаларны да яшереп калдырмаган. Газетаны илебезнең төрле якларында укыйлар, һәр язмага игътибар белән карыйлар икән.Укып кына калмаганнар,гаиләләре белән шушы артта калган хужалыкка күченеп килгәннәр.Ул чакта Марсель Гыйльфанович менә болай дип хәбәр иткән иде: “Утыздан артык белгеч, терлекче, тракторчы, шофер безнең хужалыкта урнашып, әйбәт кенә эш башлап җибәрде. Колгозга килүчеләрнең барысы да диярлек канәгать.Бары тик дүртесе генә кире китте. Нишлисең, әлегә бар да ал да гөл түгел шул.Эшләргә, көч түгәргә кирәк”.

Шуннан соң елга якын вакыт узды.Тукай исемендәге колхоз бүген нинди сулыш белән яши? Колхозның үсеш перспективасы ничегрәк? Алга таба үзгәреш сизеләме? Газета чыгышының нәтиҗәлелеге ни дәрәҗәдә булды икән? Менделеев районына юлга чыгуыбызның максаты нәкъ менә шулар белән кызыксыну иде.

....Авыл кешеләренең әйтүенә караганда, колхозның байтактан чын хуҗасы булмаган.Моннан ун еллар элек җитәкчелек иткән председатель «яшел елан»белән мавыккан,аның хуҗалык итәргә,эшкә күңел бирергә

вакыты да,теләге дә калмаган.Җитәкченең әлеге йомшак ягын бик күпләр үзләренчә файдаланып калырга тырышканнар. Шул ук вакытта яхшырак яшәргә һәм эшләргә теләге булган колхозчылар өчен идарә тарафыннан бернинди шартлар тудырылмаган. Нәтиҗәдә кеше урлашырга яки үз йомышы өчен сораусыз-нисез колхоз техникасыннан файдаланырга мәҗбүр булган.Әмма аңа карап кына андыйларның хәле җиңеләймәгән:авылда тәрәзәләренә такта кадаклаган өйләр арта торган.Әнә шулай алты йөздән артык эшләүче кешесе булган колхоз авыллары таркалу хәлендә калган.”Үз тәртипләрен урнаштырырга тырышучы әлеге хуҗадан котылгач та,күпләр утырып карый председатель кәнәфиенә. Һәркайсы үз “мирас”ын калдырып китә. Терлекчелек комплексы мәшәкатьләреннән Марсель Гыйльфановичның әле дә арына алганы юк. Дүрт миллион сумга төшереп салганнар аны.Әмма ул зыяннан башка берни бирмәгән.Чуен челтәрле идәннәр савым сыерларын әкренләп иткә генә озатырга яраклы хәлгә китергән.

- Соңгы тугыз елга бишенче председатель булып килдем мин,-ди М.Гыймазетдинов. – Исәпләп чыгаргач, колхозны алып бару өчен 560 кеше кирәк булуы ачыкланды.Ә бездә аларның яртысы да калмаган. Авылның шулай ятим хәлгә төшүе күңелгә борчу салды.Эшли башлагач, “каян эшче куллар җиткерергә?”дигән уй ярты ел буена баш миен бораулап торды.

Һәм,ниһаять,тәмам гаҗизлеккә бирелгән яңа председатель, соңгы өмет белән редакциягә хат язган.

Председатель ел ярым эчендә килгән хатларны кулына алды.

- Реликвия итеп сакларга уйлыйм мин боларны,-диде ул.- Һәркайсына төн утырып хат язарга туры килде.Һәрберсендә кеше авазы,кеше өмете,ышанычы.

....Колхоз үзәге булган Песәй авылына беренче булып күчеп килүчеләр өчен тиз арада берьюлы унҗиде фатир әзерләгәннәр. Кайчандыр кешесе китеп, бушап калган йортларны эттерергә трактор китергәч, хуҗалары кайтып төшкән. Өйне сүттермиләр дә, сатып та бирмиләр,ә килгән кешегә торырга урын кирәк.Ашыгыч рәвештә яңа йортлар төзиләр.Барлык кирәк ярак : утыны-күмере, мал-туары, печән-саламы бирелә.Хәтта йоклау өчен урын-җир әйберләренә кадәр кызганмыйлар килүчеләргә. Теләкләре генә булсын,эшләсеннәр генә!

-Кичә генә тагын бер машина Чиләбе ягына китте,- дип сүзгә кушыла партком секретаре С. Әхмәтгәрәев. – Ике гаилә шуннан күченеп киләчәк. Калининград өлкәсеннән дә транспорт җибәрүне сораганнар иде, анысы ераграк шул.Мөмкинлек җитмәде, хат кына язарга туры килде...

Сәетҗан Әхмәтгәрәев белән Марсель Гыймазетдиновның хезмәт биографияләре бертөсле. Бергә мәктәптә, институтта укып, укытучы, мәктәп директоры булып эшләгәннәр. Һәм менә язмыш аларны тагын туган төбәкләрендә очраштырган. Берсе – колхоз председателе, икенчесе партия оешмасына җитәкчелек итә.

Песәйдә хәзер әйтерсең “кайнар нокта”. Илнең төрле төбәкләреннән килеп кешеләр шушында төпләнергә, шушында гомер кичерергә уйлыйлар. Менә Илеш районыннан килгән җиде гаилә арасыннан бер нәсел кешеләре белән танышабыз. Өч бертуган Сәяповлар – Татыш авылннан. Түбән Кама ГЭСында су күтәрелгәч, төзелгән дамба аларның киләчәккә өметләрен өзгән. Авыл бүленеп калган. Печән, утын хәстәрләү мәсьәләсе авырлашкан. Шунлыктан, өлкән яшьтә булсалар да, туган якларыннан китәргә уйлаганнар. Башта, быелның январенда, кече энеләре – Бәхти Биканов гаиләсе күчеп килгән. Ул биредә терлек карый. Абыйлары Фәвит һәм Рәшит Сәяповларның биредә оя коруына әле ай ярым гына. Алар да терлекчеләр. Ирле-хатынлы Дания һәм Рәшит Сәяповларның ике улы Вәдим белән Назыйм да эти-әниләре һөнәренә тугрылыклы. Яңа колхозга килгәч, алар гаилә подряды нигезендә эш җәелдереп җибәргәннәр. Энҗе һәм Фәвит Сәяповлар да – терлек караучылар. Аларның кызлары исә ярты гына чакрым читтә урнашкан Татар Сарсазы авылы кибетенә сатучы булып урнашачак. Бу ике гаиләгә, килү белән, яңа төзелгән йорттан өчәр-дүртәр бүлмәле фатир биргәннәр. Матур итеп обойлар ябыштырылган, идәннәр юылган, чистартылган, буялган. Якын киләчәктә мондый йортларда туалетын-ваннасын эшләтү, өйне газ белән җылытуга көйләү күздә тотыла.

Песәйдә күчеп килүчеләр өчен генә каралты-курасы белән 56 йорт төзелгән яки колхоз хисабына сатып алынган. Яңа урамнар барлыкка килгән. Ике ел элек балалар бакчасында 20 бала тәрбияләнсә, хәзер аларның саны 35кә җиткән. Урта мәктәптә укучы 60 бала янына тагын унбер укучы өстәлгән.Күптән түгел яңа проект белән балалар бакчасы салып куйганнар. Шәһәрдәгедән ким җире юк.Спорт, музыка залларын, кухняны, гомумән, һәрбер бүлмәне иң затлы, иң яхшы җиһаз белән җиһазларга тырышканнар.”Балалар өчен бернәрсә дә кызганыч түгел, - диләр колхоз җитәкчеләре. – Менә урта мәктәпне дә яңадан салсак...”

…Беркөнне председательне халык судына чакырталар. Элеккеләрендә аноним яла ягу хатларын тикшерергә туры килсә, бу юлы колхозга күчеп килгән ике үзбәк аркасында суд эскәмиясенә утыра. Үзләрендәгечә, өйләнгәндә калым сорау гадәтен алар бирегә килгәч тә дәвам итмәкче булганнар икән. Менә шуннан тавыш чыккан, сугышып киткәннәр. Авылдан чыгарып җибәрүдән башка чара калмаган аларны.

Төрмәдән кайткан бер егетне дә, “эшлим, яшим”дип килгәч, кире бормаганнар. Әмма ул сүзен эш белән раслый алмаган. Алты ай яшәп, дүрт аен авыру кәгазе белән эшкә чыкмыйча үткәргәч, аны да көчкә озатканнар Песәйдән. Килүчеләр арасында да гел яхшы кешеләр генә түгел шул. Ә менә Мурманскида мул акча алып эшләргә күнеккән Рәхмәтуллин фамилияле Саба егетен биредәге хезмәт хакы канәгатьләндермәгән. Ул да берничә айдан кире китеп барган.

Ростов, Чиләбе, Ижевск, Пермь якларыннан килүчеләрне дә сыендырган авыл. Хан сарайлары вәгъдә итеп китермәсәләр дә, ирешелгән уңышларга сөенеп, матур яшиләр килүчеләр. Песәйдәге “тарихи” комплексны әкренләп үзгәртеп коралар. Хәзер савымчылар сөтүткәргечләрдән файдалана. Перспективасызлар рәтенә кертелгән кечкенә Тукай авылында 200 башка исәпләнгән ферма төзелгән, авыл янына скважина казытканнар, шуннан ук асфальт юл уза. Югала башлаган Тукай авылына “ җан өрү “өчен эшләнгән бу чаралар.

...Председательнең кабинетында кара такта тора. Нәрсәгә кирәкме? Кабинетка кергән кешеләргә җае чыккан саен аңлату эше алып бару өчен куелган ул. Үзе әйтмешли, эшләргә, яшәргә өйрәтү өчен кирәк. Кабинет хуҗасы педагог кеше ич, кара тактаны оныта алмавы да гаҗәп түгел. Бәлки әле, бераз эштән бушап, үзе генә калган тын минутларда күңелендә туган шигырь юлларын да шунда төшерәдер. Марсель Гыйльфанович – шигъри җанлы хыялый кеше. Әнә бит,колхозга кергәндә үк, шигырь китабының беренче бите ачыла:

Җирне яшәртергә сүз бирдек без,
Вәгъдәбезне, дуслар, үтәрбез...

Тукай исемендәге колхоз яшьлеккә кире кайтырга тырышып, үр менә. Урта мәктәптән соң колхоз стипендиатлары булып укып кайткан егетләр һәм кызлар авылның алдагы көннәрен күзаллыйлар. Менделеев, Чаллы, Алабуга, Түбән Кама, Зәй шәһәрләренә кул сузымы гына булса да, туган авылларын якынрак күрүчеләр гел арта. Күперләрне тәртипкә китерү, йортларга газ кертү, ферма тирәсенә асфальт җәю проблемалары алда тора хәзер. Урамнардан резина итек киеп озак йөрмәсләр ич инде!

Туган якны яшәртергә сүз биргән икән, председатель үз вәгъдәсеннән кире кайтмас, шәт. Ә эшкә килергә теләге булган һөнәр ияләре артмый биредән. Хезмәт кешеләренең эш шартларын яхшыртканнан яхшыртасы килә җитәкченең. Ә моның өчен, әлбәттә, тынгысыз җанлы, җирне ярата белүче, эшсөяр кешеләр кирәк

...Тукай исемендәге колхоз белән кызыксыну, хат язышу дәвам итә...

“Татарстан яшьләре”,
13 ноябрь, 1988 ел.

**Марсель Гыймазетдинов: “Башкача булдыра алмыйбыз”**

- XIX БӨТЕНСОЮЗ партия конференциясендә Азык-төлек программасы җәмгыятебез тормышында иң кискен, иң кыен нокталарның берсе буларак телгә алынды. Бу проблеманы хәл итүнең юллары күп. Ләкин аларның иң мөһиме – аренда нигезендә хезмәтне оештыруның прогрессив формаларына күчү.

Коллектив, гаилә подрядында һәм аренда договоры буенча эшләүче кешеләр бөртекле ашлык, сөт һәм ит җитештерүдә югары күрсәткечләргә ирешәләр.

Безнең колхоз бу елдан коллектив подрядына күчте. Гаилә подряды да үсә. Аларның экономик яктан нәтиҗәле булуына без торган саен күбрәк ышанабыз, шуңа күрә алар безнең производствоның барлык звеноларына да кертеләчәк. Колхоз экономикасын күтәрүдә башка юл юк. Бүген без башкача яши алмыйбыз.

**Подряд тәртип кертә.**

**Авыл экономикасы КИТлары**

Иртәнге җиденче яртыда председательнең планеркасы. Элек аны наряд дип йөртәләр иде. Марсель Гыйльфановичтан сораган беренче нәрсә КИТларның (коллектив интенсивного труда) хәлләрен белү иде.

-Безнең колхозда сөт өч КИТта тора, - дип шаярталар Песәйдә. Ләкин бу шаяруда бүгенге хакыйкать ята: биредә өч интенсив хезмәт коллективы сөт алу өчен көрәшә (менә кайдан алынган аларның кыскартылган исемнәре!). Подряд эшләүче өч КИТ.

200 баш сыерга исәпләнгән фермаларның берсендә 15 кеше эшләде – 8 сыер савучы, 4 терлекче, җиһазлар ремонтлау буенча слесарь, 2 тракторчы, аларның берсе азык кертте һәм өләште, ә икенчесе тирес түкте.

Шунысын да әйтергә кирәк, фермада сөт блогы операторы юк иде, ә ясалма орлыкландыручы һәм лаборант-учетчик берьюлы ике фермага хезмәт күрсәтте. Һәр савымчыга 25 сыер беркетелгән иде, бу инде алай ук күп тә түгел, ләкин чын файда сизелмәде.

- Нәрсәдер өчен конкрет бер кеше җавап бирмәде, - дияләр миңа колхозда.

Ә хәзер нәрсә үзгәрде соң?

Подряд фермасы коллективын тырыш, энергияле терлекче Әнвәр Хуҗин җитәкләде. Иң элек монда интенсив технология буенча эшләүчеләр санын минимумга кадәр кыскартырга карар кылдылар. Бер терлекче һәм слесарь хезмәтеннән баш тарттылар, алар өчен тракторчының да кирәге бетте. Хәзер җиһазларны үзләре ремонтлыйлар. Бернинди “хәйлә дә” юк икән бит монда ләбаса.

Хәзер 4 сыер савучыга да 50 шәр сыер бирелде. Сүз дә юк, күп. Ләкин бит алар үзләрен интенсив хезмәт коллективы дип атыйлар.

Шундый коллективларның берсен район Советы депутаты Гөлфәния Ситдыйкова җитәкли. Аның подрядында шулай ук 200 баш сыер. Өченче КИТта – гаилә подряды. Биредә 125 баш малны Дания һәм Рәшит Сәяповлар, Вәсимә һәм Бәхтигәрәй Бекановлар карый. Аларга Сәяповларның улы Вадим булыша, ул тракторчы һәм слесарь вазифаларын башкара.

Ирле-хатынлы Нәсимә һәм Фирдәвес Хәсәнҗановлар да колхозда гаилә подряды белән шөгыльләнәләр. Ташландык фермага алар ремонт ясадылар,

колхоздан 100 баш башмак тана алдылар. Нәсимә районда сөт саву буенча беренчелекне бирми.

Иске һәм ремонтланган фермада тагын бер арендатор – Илгиз Гыйлаҗев колхоздан 50 үгезне симертүгә алды. Аңа хуҗалыкның баш зоотехнигы Розалия Нурмөхәммәтова ярдәм итте.

-Кешеләр подрядның өстенлекләрен аңлый башладылар, - ди ул. – Бездә кызыклы һәм файдалы эштә үзләренең көчләрен сынап карарга теләүчеләрнең саны артканнан-арта бара.

Әйе, Тукай исемендәге колхозда подряд “тизлек” ала. Ул терлекчелектә тәртип сала, аны табышлы тармак итә.

Ә хуҗалыкның баш экономисты Финисә Сәләхиева бу көннәрдә машина-трактор паркын һәм механика мастерскоен подрядка күчерү шартларын эшли. Авыл хуҗалыгы машиналарына техник карау уздыру өчен биредә токарь, тимерче, сварщик, слесарь, мастер-көйләүче һәм мотористтан торган ремонт группасы төзеләчәк.

## Шәхси хуҗалыкларда.

Тыныч һәм берни белән дә күзгә ташланмый торган Тукай авылында яшәүчеләр саны да бары тик 28 генә. Алабуга нефтьчеләре һәм автомобиль төзүчеләр моннан ерак түгел насоска юл суздылар. Аның буенча су Алабугага суыртылачак. Колхоз җитәкчеләре алардан бу юлны “перспективасыз” авыл аша салуларын үтенде.

Тукай кешеләре үзләре турында беренче тапкыр кайгырту тойдылар. Ә халык кайгыртуга яхшылык белән җавап бирә. Ике семья – Фәтхетдин Нәбиуллин һәм Габденур Ситдыйковлар гаиләләре карауга 200 баш тана алдылар. Аларны күптән төзелгән фермага, аны инде ферма дип тә атап булмый, дөресрәге, печән саклау өчен җиткерелгән абзарга урнаштырдылар. 40 гектар җирдән терлекчеләр 860 центнер солы печәне әзерләделәр, аны пресcладылар. Киләсе елда аларга люцерна участогы биреләчәк.

Фермадан әллә ни ерак түгел скважина бораулангaн, аннан фермага су үткәрделәр. Сүз уңаеннан әйткәндә, авылның бөтен кешеләре дә бу скважина суын куллана алачак.

Мин Песәйдә колхоз терлекчесе Гәбдрәшит Яппаров һәм балта остасы Таймас Вәлиевларның шәхси хуҗалыкларында булдым. Беренчесе симертүгә – 5, икенчесе 4 үгез алган. Алар малларны үзләренең җаваплылыкларына алганнар. Бу эшнең күпмегә төшәсен, хезмәт хакларының күпме буласын алдан исәпләп куйганнар. Материаль файданың булачагы эшкә алынырга ярый икән дигән карарга китерде.

Яппаровлар һәм Вәлиевлар гаиләләре колхоз йортларында яши. Габдрәшитнең һәм Таймасның тормыш иптәшләре дә ирләренең ярдәмчеләре һәм подрядның тулы хокуклы членнарына әйләнделәр. Мин алардан, үгезләр

карау бик мәшәкатьле түгелме соң, дип сорадым һәм түбәндәге җавапны ишеттем:

- Без – авыл кешеләре. Хезмәткә кунеккән кешеләр. Әлегә барысы да без уйлаганча бара. Нәтиҗәләр яхшы булачагына ышаныч бар.

Банат Рәфыйковна Рәфыйковага өлкән яшьтә булуы да подрядка алынырга комачаулык итмәгән. Ул симертүгә 5 дуңгыз баласы алып, аларның артымын 666 граммга җиткерүгә ирешкән. Хәзер Банат апаның ишек алдында – 2 үгез, ул өченчесен дә алачак.

Бу әле – башлангычы гына. Песәйлеләр яңа эшне җентекләп өйрәнәләр, гаилә подрядының мөмкинлекләрен крестьяннарча үлчәүгә салалар. Колхоз председателе М.Г.Гыймазетдинов яхшы үрнәкнең дә тиз күчүенә ышана.

Җитәкчеләр авылда шәхси хуҗалыкларны колхоз производствосының состав өлеше дип саныйлар. Авыл халкына терлек азыгы да, фураж да җитәрлек күләмдә бирелә.

**Тоткарлану**

Ләкин шулай да Тукай исемендәге колхозда коллектив подрядның үсешен тоткарлаучы факторлар бар. Аларның берсе – сыерларны, үгезләрне, бозауларны һәм дуңгызларны асрау өчен биналар җитмәү.

Мондагы сөтчелек комплексын 12 ел төзеделәр. Аны сафка бастыру өчен тукайлыларга колхоз “каешын” тарттырыбрак бәйләргә туры килде: гаять зур корылма 4 миллион сумга төште. Андый средствога Терлекчеләр йорты, сауна, психологик киеренкелектән арыну бүлмәләре булган уртача зурлыктагы 20 ферма салырга мөмкин булыр иде.

Бу сөт “фабрикасы” колхозчыларга нәрсә бирде соң?

Зыяннан башка берни дә китермәде.

Бу могҗиза-комплекста сыерларны тоту куркыныч эш булып чыкты. Проектчылар уйлавынча, тирес ярымподвалга агып төшәргә тиеш. Бу үзагынты рәшәткәләп эшләнгән чуен идәннәр астыннан узачак. Теоретик яктан барысы да гади күренә.

Ләкин сыерлар “техника прогрессына” ни өчендер шатланмаган, чөнки алар, чуен идән ярыкларына кыстырып, тоякларын ярып бетергәннәр. Шушы “прогресс”тан соң колхоз байтак маллар югалтты.

Өстәвенә, идән астына аккан һәм биологик законнар нигезендә бирелә кыйммәтле органик ашламага әйләнгән сыек тиресне кырларга чыгару мөмкинлеге булмады. Сыер фермасының нигезе иске блокка түбәнрәк салынган һәм бернинди техника да тирес җыелу урынына керә алмады.

Колхоз экономикасына авыр йөк булып төшкән сөтчелек фермасына ашыгыч рәвештә реконструкция үткәрергә туры килде. Чөнки монда тирес җыю системасы тулысынча алыштырыла, бу максат өчен транспортер куела, идән бетонлана.

Хуҗалыкта башка производство биналарына да реконструкция ясыйлар: яңа җиһазлар урнаштыралар, су кертәләр. Кайчандыр ташландык хәлендә калган фермалар, ат абзарлары, складлар җанлана.

Аренда подрядының үсешен тоткарлаучы әле тагын бер фактор бар. Ул эшкә тулысынча бирелүне таләп итә. Ә моңа бар кеше дә бара алмый. Ә кешеләр аңында тигезләп бүлү “вирусы” нык урнашкан. Ул чорда намуслы эшләгәннәр дә, эшләгән булып кыланучылар да бер үк төрле хезмәт хакы алганнар. Җилкуарлар, намуслы хезмәтчәннәр артына яшеренеп, бик яхшы яшәделәр. Әлбәттә, андыйларга подряд кирәкми.

Авылдашларына экономика дәресләрен бирүче подряд энтузиастларының тырышлыгы бушка китми. Бүген тукайлыларның әлегә, элеккечә, югарыда торучы инстанцияләргә колхоз производствосының барлык звеноларын 100 процент арендага кертүләре турында “шатланып һәм горурланып” рапорт бирә алмауларының бернинди гаебе юк.

Аларның киләчәге – алда.

А.Тагильцев.

“Октябрь байрагы” газетасы,

22 октябрь, 1988 ел.

**Тормыштан ямь – тәм табып.**

Егерме минутлап та үтмәгәндер, председатель “Нива”сы безне Песәйгә кадәр китереп җиткерде. Иртә, бик иртә иде әле: җәйгечә җылы, әмма шул ук вакытта көзгечә томанлы иртә иде ул. Асфальт юл буенда, җиргә әкрен генә коелучы яфраклары белән үзара серләшеп, куе-кызыл төстәге көяз агачлар тезелгән.

– Тирә-якның гүзәллеген күр әле син,-дип хозурланып әйтте Марсель Гыйльфанович, машина тәрәзәсеннән карап барган җиреннән. Әйтерсең лә, бу агачларны да, тиз тарала барган томанны да аның беренче генә тапкыр күрүе иде! Шушы балаларча беркатлы соклануда ул бөтен барлыгы белән ачылды. Тукай исемендәге колхозның кешеләргә ачык, киң күңелле председателе үзенең көндәлек мәшәкатьләре белән табигать сюрпризларына куаныр һәм аның гаҗәеп үзгәрешләренә сокланыр өчен хәтта бер генә мизгелгә дә тормыш ыгы-зыгысыннан, чынбарлыгыннан аерыла алмый.

Колхозга бу баруымны мин бер елга якын вакыт узгач кына искә төшердем: октябрь ае иде, урып-җыю инде тәгәлләнгән, Марсель Гыйльфанович үзенә көтмәгәндә насыйп булган бу шатлыкны татырга рөхсәт итә алды. Ләкин хәзер, бу кешене бер генә көн белмәгәнлектән, кыю итеп әйтә алам: аңа табигать үзе матурлык хисләрен бүләк иткән.

Бу сыйфатлар колхоз председателенә кирәкме соң? Бик.

Туган авылы Бәзәкәдә Марсель Гыймазетдинов урта мәктәп тәмамлый. Яхшы укый. Мәктәп елларында аның программа нигезендә үзләштерелгән фәннәрдән тирән белем алуы гына бу төп нәрсә түгел әле. Нәкъ менә биредә аны җәмагать кешесе итеп тәрбиялиләр. Чөнки егет сигезенче класстан алып укучыларның комсомол оешмасын җитәкли. Аңа менә дигән сабак биргән тагын бер мәктәп була ул.

Аннан соң – Алабуга педагогия институты. Монда Марсель Гыймазетдинов укытучы профессиясе ала. Ул биредә өйрәнгән татар филологиясе аңа үз халкының рухи чыганагын, аның культурасын тирәнрәк аңларга булыша. Болар барысы да колхоз председателенә аның бүгенге эшендә ярдәм итәләр.

Марсель Гыйльфанович тормышыннан биографик мәгълүматлар белән генә мавыгырга теләмим. Шунысын гына әйтәм: белгечлеге буенча эшләргә ул армиядә хезмәт иткәннән соң, 1962 елда  башлады. Тойгуҗа мәктәбендә балалар укытты. Ык Тамагы авылында мәктәп директоры вазифаларын башкарды. Ә аннан соң Менделеевск махсус мәктәп интернатында җитәкче булды. Укыту эше ошый иде аңа, ләкин алай да күңеле башкага – тагын да җанлырак һәм җитдирәккә тартылды. Шулай итеп ул “Тойма” совхозы партия оешмасын җитәкләргә дигән тәкъдимгә шатланып риза булды. Тик бәла шунда: ныклап тотынырга, киңәергә дә өлгерми калды.

Ул торгынлык еллары иде. Партия оешмасы секретарьләре үзләре өстендә һәрвакыт шәһәр һәм район комитетларының авыр кулларын тоеп тордылар. М. Г. Гимазетдиновның беренче секретарь С.Г.Габдуллин белән холыклары килешә алмады. Китәргә туры килде.

Беркадәр вакыт ул 540нче төзү монтаж урынбасары булып эшләде.Әлеге коллектив Әгерҗе – Круглое поле тимер юлын торгызды. Марсель Гыйльфанович партия оешмасы секретаре итеп сайланды. Аның тормышының һәм эшенең бу чоры турында Ижевскиның “Удмуртия” нәшрияты тарафыннан чыгарылган “Алнаш җирендә” дигән китабыннан нибары бер абзац ачык сөйли: “ Поезд җитәкчелегенә начальник урынбасары Марсель Гыйльфанович  Гыймазетдинов уңышлы өстәмә булып тора. Элеккеге комсомол работнигы, ә хәзерге парторг яшьлек ялкынын, максатка омтылышын, сокландыргыч эшкә сәләтлелеген, бетмәс-төкәнмәс энтузиазмын югалтмаган. Ул җитәкчелек итә башлаганнан алып, СМП коммунистларының саны өчтән унҗиде кешегә кадәр артты. Табигый, партия оешмасы үз эшен киң җәелдерде. Аның кайгыртуы нәтиҗәсендә балалар бакчасы, ашханә, азык-төлек һәм промышленность товарлары магазиннары эшли башлады. Комсомол һәм профсоюз оешмалары үз эшләрен активлаштырдылар”.

Менделеевск районын кабат төзегәч, Марсель Гыйльфанович “ Батыр кул” колхозы партия оешмасы секретаре булып эшләргә килде. Ә тиздән аны Тукай исемендәге колхоз председателе итеп сайладылар. Ул бу җыелышны яхшы хәтерли. Монда колхозчылар аны яклап яки аңа каршы тавыш бирергә тиешләр иде.

– Мин: авыр булыр – булышырсыз, өйрәнермен, дидем

Залдан колхоз ветераны, Песәйдә хөрмәтле кеше, Ленин һәм Октябрь революциясе орденнары кавалеры, коммунист Нурулла Зарифуллин торып басты. Ул да күп сөйләп тормады:

– Марсель Гыймазетдиновта – безнең Песәй каны, аның әтисе Гыйльфан абзый шушы авылда туып-үскән, 1929 елда колхозның беренче председателе итеп сайланган. Әйдәгез, аңа хуҗалыкны ышанып тапшырыйк, – диде ул.

Яңа председательгә беренче көннәрдә авыр, һай, бик авыр булды. Элек тупланган хуҗалык эше тәҗрибәсе монда кулланырлык булып чыкмады. Биредә әүвәлгедән килгән крестьян тормышы тәртибенең үз законнары, үз кануннары яшәде. Һәм аны монда командалык итәр өчен түгел, ә таләпчән

һәм кешелекле җитәкчелек итәргә сайлап куйдылар. Бик тиздән Марсель Гыйльфанович моны аңлады һәм кешеләр белән үз-үзен тоту стратегиясен эшли башлады.

Бу, әгәр, белергә теләсәгез, тулаем политик концепция иде, моны барлыкка китергәндә аңа укытучы күнекмәләре һәм 22 еллык педагогик стаж бик ярап куйды. Марсель Гыйльфанович бу концепция үзәгенә кешеләр белән эшне куйды. Чөнки бүген башкача мөмкин түгел: кеше факторы – чираттагы теоретик уйдырма түгел, ә чынбарлык. Моннан сүз куерту демагогиясе томанында качып котыла алмыйсың.

Марсель Гыйльфанович министр һәм гади сыер савучы белән дә, чал чәчле ветеран һәм нәни мәктәп баласы белән дә сөйләшә белә. Һәркемгә сүзен таба, һәркемне инандыра ала, әгәр эш шуны таләп итә икән, кешенең табигый шөһрәт яратуында “уйный” белә.

Нәкъ менә шуңа күрә колхозда эшлексезләр юк. Биредә язгы, җәйге эш өстендә яки көзге урып- җыюның киеренке көннәрендә карты да, яше дә эштә.

Песәй укучылары бернинди эштән дә курыкмыйлар. Аларны ындыр табагында, дуңгызчылык яки сөтчелек фермасында, кырда очратырга мөмкин. Терлек азыгы хәзерләгәндә пенсионерлар хуҗалыкка нык булышалар. Терлек азыгы җитештерү звеносын җитәкләүче дә – сугыш һәм хезмәт ветераны Мөхәммәтнур Габиевич Габиев. Аның турында колхоз председателе ифрат җылы итеп телгә ала.

Сүз уңаенда шунысын да әйтеп үтим, Марсель Гыйльфанович – яхшы сүзгә, гомумән, юмарт кеше. Ул колхозчыларның кайсысы турында булса да беркайчан да яман сүз әймәс. Колхоз хезмәтчәннәренең барысын да алтын бәясендә исәпләп йөртә ул, аларның һәркайсын үзенчә бәяли, һәркайсына хөрмәт белән карый. Кешеләр моны аңлыйлар һәм колхозга ярдәмгә дигән чакыруга һәрвакыт бик теләп кушылалар.

Үзәк усадьбага илтүче юл буена чүп үләннәрен чабарга кирәк иде. Бу эшкә пенсионерлар алынды. Алар шимбә өмәсенә чалгылар белән чыктылар һәм чүп үләннәрен чабып алдылар. Салам эскертләргә яки агачларны агартырга кирәк икән – колхозда янәдән ветераннарга мөрәҗәгать итәләр.

Кешеләр, алар кәефе турында кайгырту - Марсель Гыйльфанович өчен көндәлек мәшәкатькә әверелде. Тукай авылын, 5 ел элек тулы нигез белән перспективасызлар рәтенә кертергә мөмкин иде. Биредә 12 өйдә нибары 22 кеше яши. Шул рәвешле, авыл җир йөзеннән юкка да чыккан булыр иде, ләкин председатель: авылны яңадан торгызырга, аңа яшәү сулышы өрергә кирәк, дип карар бирде. Монда аркалы ферма төзеделәр, анда 200 баш бозау асрый башладылар. Бозау абзарын арендага бирделәр. Кешеләр судан файдалана алсын өчен аның янәшәсендә скважина борауладылар. Авыл халкы урамнар яктыртылмаганлыктан, озак җәфаланды. Хәзер монда яңа электр линиясе сузылды, урамнарга көндезге яктылык лампалары урнаштырылды.

Кешесез калган авылларны Марсель Гыйльфанович үзенең шәхси трагедиясе кебек кабул итте. Ул бүген дә бу турыда тыныч кына сөйли алмый. Республикабызда башланган районнарны һәм хуҗалыкларны вакландыру процессы аның өчен ул вакытта тукайлыларның бер бригадасы булган Тойгуҗа авылында үз колхозларын төзү турындагы мәсьәләне хәл итүнең башлангыч ноктасы булды.

– Бары тик чын мөстәкыйльлек кенә авылны саклап кала алачак, – ди М.Г. Гыймазетдинов. Һәм ул моны исбатларга тәвәкәлләде: Тойгуҗага бригадир итеп чын крестьян характеры, хуҗаларча зирәклеге өчен бәяләгән элеккеге үзенең шоферын куйды.

Әнвәр абый Габбасов эшкә кыю алынды. Тукай исемендәге колхозның Тойгуҗа исемендәге колхозның Тойгуҗа бригадасы председательнең өметләрен аклады: аның ягыннан ярдәмсез-нисез чәчүне вакытында башкарды, ярыйсы гына уңыш үстереп алды. Бу инде бередә мөстәкыйль колхоз оештырырга мөмкин булуын күрсәтә иде. Һәм Марсель Гыйльфанович партия райкомында бу турыда мәсьәлә күтәрде.

Фирдәвес Мулланурович Латыйповка Орджоникидзе исемендәге яңа колхозда председатель булып эшли башлау ансаттан булмады. Алай да кыска гына вакыт эчендә аның хуҗалыгы аякка баса алды. Ә иң мөһиме: бередә зур социаль проблемалар хәл ителә башлады. Тойгуҗада производство объектларын, торак салу алып барыла. Мин шуны ышанып әйтәм, кыска вакыт эчендә аның хуҗалыгы аякка баса алды. Ә иң мөһиме: бередә зур социаль проблемалар хәл ителә башлады. Тойгуҗада производство объектларын, торак салу алып барыла. Мин шуны ышанып әйтәм, килер вакыт, моннан китүче күпләр туган төбәкләренә кире әйләнеп кайтыр.

Бүгенге колхоз председателе яки совхоз директоры грамоталы экономист булырга тиеш. Син белгечлегең буенча кем генә булсаң да, заман таләбе шундый. Укытучы М. Г. Гыймазетдинов шуңа ия булды да. Ул бүген – иртәгәге көнгә карый белүче, кыскасы, шушы мизгелдәге файданы да кулдан ычкындырмаучы җитәкчеләр арасында. Колхоз экономикасын күтәрүдә ул иң перспективалы юнәлеш дип хаклы рәвештә производствоның барлык тармакларын аренда подрядына күчерүне исәпли. Аренда аларны бары тик табышлы итәргә генә булышмаячак, бәлки ул кешеләрне җирнең чын хуҗалары итеп раслаячак.

Колхозны тулы арендага күчерүдә партия оешмасы секретаре Сәетҗан Хаҗиевич Әхмәтгәрәев председательнең ышанычлы һәм тугры ярдәмчесе булды һәм аны председатель “аренда оркестрының баш дирижеры” дип атый.

Тукай исемендәге колхозда үсемлекчелек һәм терлекчелек кооперативлары төзелде. Аларны баш агроном Илдар Батталов Һәм баш зоотехник Розалия Нурмөхәммәтовалар җитәкли. Бу, М.Г. Гыймазетдинов фикеренчә, гаять мөһим. Чөнки белгеч арендада кызыксынган, анда катнашкан булырга тиеш. Баш инженер Илшат Мөхәммәтгалиев җитәкчелегендә механизаторларның үз кооперативы бар. Аерым аренда звенолары үлән оны, терлек азыгы хәзерләү белән шөгыльләнәләр. Колхозда дуңгыз һәм яшь мөгезле эре терлек симертү буенча гаилә подряды киң таралыш тапты.

Председатель кабинетында кара такта тора, Айга ике тапкыр монда урта звено җитәкчеләре социалистик хуҗалык итү мәктәбенә занятиягә җыелалар. Аны Марсель Гыйльфанович алып бара.

– Бу мәктәп асылда конкрет экономика мәктәбенә яки тормыш экономикасы мәктәбенә әверелде, – ди ул. – Аны бары тик хуҗалык белгечләре генә түгел, бәлки сыер савучылар да, терлекче-көтүчеләр дә, механизаторлар да яхшы белергә тиеш. Моңа иманым камил. Менә ни өчен занятияләрдә мин аларга хезмәтне оештыруның прогрессив формасының экономик максатка яраклылыгын исбатларга тырышам. Безнең алга таба

юлыбыз фәкать аларны практикага керткәндә генә мөмкин булуына инандырам. Шулай итеп, мәктәп тактасы миңа, элеккеге укытучыга, бүген дә хезмәт итә.

Соңгы елларда безнең тормыштан “Ел заданиесен – срогыннан элек” тибындагы лозунглар үзләреннән-үзләре юкка чыкты. Чөнки алар, кагыйдә, буларак, киметелгән планнарга, теләсә кайсы юл белән, хәтта ялганга барып, аларны үтәргә омтылуга каралган иде. Бу җиңү шатлыкларына һәм бүләкләргә генә түгел, бәлки законнарны тупас бозуга, авыл хуҗалыгында рөхсәт ителмәслек даими штурмчылык обстановкасы тууга китерде.

Тукай исемендәге колхоз күптән түгел дәүләткә бал һәм үлән оны сатуда уникенче бишьеллык планнарын тормышка ашырды, ә ит һәм сөт тапшыруда бишьеллыкның дүрт елы заданияләрен үтәде. Монда бу уңышларга, отчетларга өстәп язуларсыз ирешелде.

Колхоз инде күптәннән дуңгыз үрчетү һәм симертү белән шөгыльләнә. Терлекчелекнең бу тармагы монда табышлыга әйләнде. Дуңгыз караучылар Суфия Ясәвиева, Кәүсәрия Садриева, Мөгаздәмә Юлдашевалар аеруча уңышлы эшли. Баштагы ике терлекченең малларны кышлату чорында алган тәүлеклек артымы 387 грамм тәшкил итте. Ә өченчесенең күрсәткече 400 граммга якынлашты. Узган ел Наилә Галиәхмәтова рекордлы үрчем алды: бер аңа дуңгыздан – егермешәр баш.

Һәр кешедә шагыйрь яшәргә тиеш. Марсель Гыйльфанович шулай исәпли. Бу аеруча гаҗәпләнерлек: чөнки аның, эш-мәшәкатьләргә чумган кешенең, хәтта Кама өстеннән кояш бату күренешенә хозурланырга да вакыты юк. Ә кояшка яки яңгырга ул чын рационалистик позицияләреннән чыгып карый. Бүген игенчегә алар кирәкме, юкмы, дип уйлый.

Алай да ул – шагыйрь. Тик мин колхоз председателенең моңа кайчан вакыт табуын белмим: әмма ул шигырьләр һәм җырлар яза. Аның беренче шигырьләр җыентыгы “Аккош канат кагына” дигән лирик исем астында ике ел элек Татарстан китап нәшриятында дөнья күрде. Ә киләсе елга шул ук нәшрият Песәй шагыйренең “Тормыш максаты” исемле тагын бер китабын чыгаруны планлаштыра.

Кайчандыр татар халык шагыйре Сибгать Хәким Марсель Гыйльфановичка болай дигән: “Әгәр синең бер җырыңны кешеләр җырласа, димәк, халык хәтерендә син мәңге яшәячәксең”. М.Г. Гымазетдинов берничә җыр язды. Алар республика радиосы аша тапшырылган концертларда еш яңгырыйлар. Шулай булгач, ул исән чагында ук үзенә ныклы һәм гүзәл һәйкәл “торгызды” дип исәпләргә мөмкин.

Үз халкының тугры һәм эчкерсез улы буларак, Марсель Гыйльфанович татар культурасы өчен чын күңелдән борчыла. Ул авыл кешеләренең тик икмәк үстерүен генә түгел, ә аларның поэзия, музыка ратуларын да тели. Менә ни өчен ул, хуҗалык җитәкчеләре арасыннан бердәнбер кеше буларак, үз колхозчыларын Менделеевскига гастроль спектакльләренә һәм концертларына җибәрә. Менә ни өчен Песәйгә Татарстан АССРда Башкорстан әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә катнашучыларны чакыра.

Менә ни өчен җирле культура йортында шагыйрьләр һәм артистлар еш чыгыш ясый. Менә ни өчен авылга илтүче юл өстендә безнең өчен гадәти булмаган транспарантлар куелган. Аларда рәссам сөт муллыгын арттыруга өндәмә язмаган, бәлки күңел кылларына кагылучы шигырь юллары тезгән.

Кеше хыялсыз яши алмый. Ләкин колхоз председателенең хыяллары эшкә ашарга тиеш. Ике ел элек Марсель Гыйльфанович колхоз авылларына газ кертү турында уйлый гына ала иде. Хәзер Тукай исемендәге колхоз районда беренчеләрдән булып күптәнге планны тормышка ашыруга кереште: газ торбалары сатып алынды һәм кайтартылды, проект документациясе хәзерләнде. “Уралстройреммонтаж” тресты эшчеләре газ бүлү пунктының нигезен сала башладылар.

Быел Песәйдә зур төзекләндерү эшләре алып барылды: яшелдән киенгән шушы матур авылның урамнарына асфальт җәелде. Ә председатель инде иртәнге көн турында уйлый, чөнки башкача яшәргә ярамый. Киләсе елдан колхоз идарәсе күп производство объектларын җиткерүне башларга ниятли. Өстәвенә, ул хуҗалык ысулы белән алып барылачак.

Әмма алай да иң төп төзелеш Песәйдә яңа мәктәп салу булачак. Колхозчылар балалары заманча югарылыктагы мәктәптә укырга тиешләр: хуҗалык идарәсе шулай хәл итте.

Марсель Гыйльфанович тагын бер уй-нияте турында миңа серен чиште: авыл читендә ике катлы сигез квартиралы дүрт йорт салырга планлаштыра ул. Аларның беренче катында ялгыз хезмәт ветераннары өчен бер бүлмәле квартирлар проектлатырга тели. Әлеге микрорайон төзелешенә инде 20 гектарлы участок бүленгән. Председатель кешеләрнең торак йорты белән янәшәдә гаражлар, базлар һәм хәтта магазин булуын тели.

Мин М.Г. Гыймазетдиновтан, председатель эшенең шундый зур киеренкелеген җиңәргә сез ничек булдыра аласыз, дип сорадым. Чөнки ул колхозда иртәнге алтыдан кичке тугызга кадәр була. Ә ул болай дип җавап бирде:

– Минем өчен кыенлыклар, мөгаен, 90 процент тәшкил итәдер. Ләкин алай да калган 10 проценты синең нәрсәдер эшли алганың өчен куаныч һәм ләззәт бирә. Менә шушы 10 процент өчен мин эшләргә һәм тагын бер кат эшләргә әзер.

Тагын ул миннән аның җиңел булмаган хезмәтендә гаиләсенең: аңа кадерле хатынының, педагогик хезмәт ветераны Миңнур Муллануровнаның, уллары Рөстәм һәм Маратның рухи теләктәшлеген даими тоеп торуын язуымны үтенде.

Эшли белү осталыгы. Нәрсә бу: кешенең тумыштан, табигатьтән килгән сәләтме, әллә еллар узу белән туплана торган үзлекме? Барыннан да элек, тегесе дә, бусы да дөрестер. Әмма кеше тик хезмәт белән генә яшәми. Марсель Гыйльфанович Гыймазетдинов белән үземнең бер ел танышлыгым эчендә мин шуңа инандым: ул бары тик эшли белергә генә түгел, бәлки тормышка куана, аның барлык күптөрле төсмерләрен бәяли һәм ярата белергә дә сәләтле.

Александр Данилов,<br>журналистларның Хөсәен Ямашев исемендәге<br>республика премиясе лауреаты,<br>Менделеевск ш.,<br>“Октябрь байрагы” газетасы,<br>1989 ел.

**Үзгәртеп коручы.**

Белгечлеге буенча филолог ул. Яшьлек елларындагы теләге – укытучылык итеп, заманга лаек буын тәрбияләү булган. Менә шундый ук изге максат белән кулына каләм алган. Уй-фикерләре, теләк-омтылышлары дәфтәр битләренә шигъри юллар булып күчә барган, һәм соңгы елларда әдәби җәмәгатьчелек аны шагыйрь буларак таныды. Республика, район матбугатында аның әледән-әле шигырьләре дөнья күрә, нәшриятта китаплары басылып чыга, СССР Язучылар союзы члены итеп алу турында сүз бара.

Әдәбият сөючеләргә шактый ук яхшы мәгълүм әлеге шагыйрь колхоз рәисе буларак та һич кенә дә төшеп калганнардан түгел. Ул җитәкләгән хуҗалыкларда тотрыклы үсеш өчен ныклы нигез булдырылды, колхозчылар таза, мул тормышта яшиләр.

- Яшьлек хыялыма мин тугърылыклы калдым, - ди ул.Кеше тәрбияләү хуҗалык җитәкчесе вазифасына кермимени?! Ничек кенә әле!

Хәзер инде якыннанрак танышыйк. Ул дигәнебез – Марсель Гыймазетдинов. Менделеев районының Тукай исмендәге колхоз председателе. Бөек шагыйребез исемен йөрткән колхозның шаулаган чаклары бар иде. Ләкин моннан ун-унбиш ел элек. Соңгы вакытта бу хуҗалык артка тәгәри башлады, колхоз бурычка чумды. Колхозчылар саны кисәк кенә 400 кешегә кимеде. Авыл кешеләре, үзләре турында кайгыртучанлык тоймаганлыктан, шушы төбәктәге гигант төзелешләргә юл тотты. Районның яңа җитәкчеләрен бик нык борчый иде бу хәл.

Һәм Тукай исемендәге колхозда председатель булып Марсель Гыймазетдинов эшли башлады. Байтак еллар балалар укыткан, соңгы вакытта район хуҗалыкларының берсендә партия оешмасы секретаре булып эшләгән.

- Колхозның элеккеге данын кайтарасы иде, - ди аңа партия райкомының беренче секретаре Мансур Хаснуллин.

Колхозчылар да артталыктан зар-интизар булган.

Биредә колхоз председателе вазифасын ул буш нигезләрне барлаудан башлый. Хуҗалары калдырып киткән йорт- җирләрне колхозга сатып алу чарасын күрә, хуҗалыкның үзендә дә берничә йорт җиткерелә. Һәм председатель Казан телевидениесенә килә дә“Мин әле яңа гына эшли башлаган колхоз председателе, авыл хуҗалыгы мәсьәләләренә багышланган тапшыруларның берсендә катнашырга рөхсәт итсәгез иде” дигән теләк белдерә. Телевидение аша чыгыш ясаганда ул колхозның хәзерге хәле турында, үзенең планнары хакында тәфсилләп сөйли. “Колхозны тернәкләндерүгә минем белән бергә алынучылар табылмасмы икән?” дигән сорау да куя. Шундый теләк белдереп, хуҗалыкка килүчеләрне йорт-җир белән тәэмин итүне гарантияли. Председатель, шул ук вакытта, авылларын ташлап китүчеләргә шигъри юллар белән мөрәҗәгать итә:

Юксынам, дисең син,
Нигә соң?
Гомерең узмаган бит әле.
Туган як туфрагын сагынып,
Әйләнеп авылга кайт әле.
Саф чишмә сулары, һавасы,
Тугае, болыны, урманы
Кочаклап алырлар үзеңне-

Шулардан кадерле җир бармы?
Күзләрең ямансу, боеклар,
Алар да авылны сагына;
Кайгырма, моңайма, юксынма,
Әйләнеп кайт әле авылга.

Председательнең мөрәҗәгате бик күпләрнең күңеленә үтеп керә. Кайталар авылга. Килүчеләрне колхоз үзәгендәге авылга да, аннан ерактагы торак пунктларга да урнаштыралар. Барысы да эш белән тәэмин ителә. Хуҗалыкта тәртип һәм дисциплина мәсьәләләре беренче планга куела. Председатель үзе көн дими, төн дими, әле басу-кырларда, әле фермада була, һәркемнең көченнән, сәләтеннән килгән кадәр эш таләп итә. Эленке-салынкы йөрүчеләрне тәртипкә чакыра. Әлбәттә, инде шактый ук тыныч яшәргә өйрәнгән, колхозда миннән башка эшче көч юк, миңа ни кылансам шул килешә, дигән фикерне алга сөргән кайберәүләргә председательнең мондый активлыгы ошап җитми. Тик алар ризасызлыкларын турыдан-туры җитәкченең үзенә әйтергә базмыйлар, тора-бара район, республика оешмаларына шикаять хатлары ява башлый. Гыймазетдинов, янәсе, читтән килүчеләрне яклый, аларга гына шартлар тудыра, колхозда уңыш җыеп алу сузыла, фермаларда кайнар су юк, кемгә нәрсә кирәк, шуны өйләренә ташыйлар. Председательнең берүзенә дүрт машина һ.б.

... Комиссияләр килә, тикшерүләр башлана. Шул вакытларда бер кичне председатель кулына каләм ала. Барлык күңелендәгесен кагәзьгә терки һәм район газетасында “Анонимчыга ачык хат” дигән баш астында мәкалә дөнья күрә.

“Куркак җан, сиңа ачык хат язарга булдым. Әгәр синең чыннан да колхоз үсешенә файда китерәсең килә икән, син күргән, белгән эшләр дөрес икән, нигә син чын исемеңне атамыйсың? Син үзең дә күреп торасың булыр – минем дә, колхоз партоешмасы секретареның да, авыл Советы председателенең дә ишекләре һәркемгә ачык. Әйе, әле һаман да төгәл ритм белән эшли алганыбыз юк. Синең шикаятьләреңне мин колхозчыларның хезмәткә карашы уңай якка үзгәрүгә көнләшүең дип кабул итәм. Син шуны аңла: Тукай исемен йөртүче хезмәтчәннәр дә, районыбызның һәр намуслы кешесе кебек үк, КПСС Үзәк Комитетының 1985 елда үткәрелгән апрель Пленумы һәм партиянең XXVII съезды караларын үтәүгә зур көч куялар, һәм без җиңеп чыгачакбыз. Ә син, анонимчы, үзгәртеп кору эшенә аяк чаласың. Уйлан әле, вөҗданың газапламас микән?”

Тукай исемендәге колхоз эшчәннәре Бөек Октябрь социалистик революциясенең 70 еллыгын барлык тармак буенча да ике еллык планнарны үтәп каршылады. Соңгы вакытта хуҗалыкта төзелеш киң колач җәйде. Халык аз яши торган авылларны саклап калу, аларда яшәүчеләрнең һәртөрле ихтыяҗын тулы канәгатьләндерү чаралары күрелә. 20-30 йортлы авыллардагы шәхси хуҗалыкларда вакытлыча кибетләр, балалар бакчалары ачу нияте белән йөри председатель. Музыка мәктәбе булдыру, авылларда асфальт салу, йортларга газ кертү буенча да эш җәелдерелгән. Соңгы ун ел дәвамында торгынлыкны тиз генә киметү, әлбәттә, җиңел генә бирелми. Шулай да инде телгә алырлык үсеш сизелә.

- Үзем дә йорт җиткерәчәкмен, - ди председатель. – Минем йорт колхоз үзәгендә түгел, анда яшәүчеләр болай да җитәрлек, моңарчы перспективасыз дип исәпләнгән авылларның берсендә, мөгаен, иң ерактагысында булыр.

Озакламый колхозчылар өчен ун квартира торгызылачак. Килергә теләк белдерүчеләр хәтсез.

Председатель өстәлендә йөзләрчә хат. Аларның барысына да җавап язылган. Тик хәзер инде колхоз идарәсе үтенечләрнең барысын да канәгатьләндерә алмый. Эшче кулга аеруча кытлык кичерүче һәм шул ук вакытта килүчеләрне йорт-җир белән тәэмин итәргә әзер торучы хуҗалыклар, Тукай исемендәге колхоз председателенә хат язып, кайбер гаиләләрнең үтенече-гозеренә колак сала алалар. Авылга кайтырга теләк белдерүчеләргә ышанычлы ярдәм кулы сузарга иде. Буш торучы йортлар республикада ай-һай күп бит әле, алар меңнәр белән исәпләнә. Чүпрәле, Мамадыш, Арча, Биектау районнарында буш нигезләрне яңадан торгызу өчен зур оештыру чаралары күрәсе бар.

Председатель белән бер очрашуыбыз игеннәрне җыеп алу төгәлләнгән чакка туры килде. Үтә дә авыр кыр эшләренең уңышлы төгәлләнүеннән колхоз җитәкчесе канәгать. Аның хисләре шигырь юлларына күчкән.

Зәңгәр күктә тургай тынган күптән,
Килер язда тагын җырлар ул.
Ятып җирне кочам –
Сездән башка
Тора алмам иген кырларым.
Кайтып киләм басу сукмагыннан,
Тук башаклар нидер серләшә,
Туган илнең иркен басулары
Һәр кешегә бәхет өләшә.

- Тормышчан шигырьләр, - дим. – Мөгаен, алар да булышадыр...

Председатель елмая. “Әле күптән түгел генә республика оешмасыннан бер иптәш тикшерү белән килгән иде, - дип сөйли ул. – Комплекстагы сыерларның аз сөтле булуының сәбәбен нәкъ менә минем шигырь язуымнан күрде”.

Аннары җитди төстә дәвам итә:

- Комплекс дигәннәре колхозны кабул итүемнең беренче көненнән үк мине хәсрәткә салды. Заманча дип төзелгән үзе, ә заманчалыгы чамалы гына. Беренчедән, тиресен чыгара алмый җәфа чигәбез, узган ел бер трактор тирес чокырына батып та кала язды. Икенчедән, аслыклары да без теләгәнчә түгел, сыерларның тоягы бозыла. 4 миллион сумга төшереп комплекс төзелгән, ә нәтиҗәсе тиеннәр белән генә үлчәнә. Хәзер менә, байтак чыгым тотып, комплексны реконструкциялибез. Сөт җитештерүдәге кимчелекләр дә комплекстагы җитешсезлекләр белән бәйле.

... Иртән эшкә килгәндә дә, кичен өенә кайтып киткәндә дә председательнең юлы Бәзәкә авылы зираты яныннан үтә.

- Бу зиратта минем әтием һәм кызым күмелгән, - ди ул. Тоткан юлымның дөреслеген һәр көн саен әтием белән киңәшкәндәй булам. Җитешсезлекләрем булса, ул шелтә белдерәдер кебек, үсеш булса, инде шатланадыр сыман тоела миңа.

Марсель Гыймазетдинов әтисе Гыйльфан ага колхоз оештырган. Песәй авылының беренче председателе булган. Гыйльфан агадан соң шул ук колхозда аның ике улы председательлек иткәннәр. Аннан соң күп кенә председательләр алышынды. Хәзер менә Гыйльфан аганың өченче улы Марсель әтисе һәм абыйлары эшен дәвам итә.

“Синең әтиеңне “коммунист Гыйльфан” дип атап йөртәләр, - дип язган аңа Арчадан заманында Песәйдә туып үскән һәм укытучылык иткән Шәйхенур Гайнетдинов. (Бу хат председательгә атап Октябрь революциясенең 70 еллыгы якынлашкан көннәрдә язылган була.) – Бүгенгедәй мул, тыныч тормыш бүләк итүчеләрнең исемнәрен мәңгеләштереп калдырырга иде безгә. Песәй авылының күренекле большевигы, укытучы Мортаза абый Шәймәрданов партячейка оештыручы, аның беренче секретаре булган кеше. Ул авылда Совет власте урнаштыруда да, колхоз төзүдә дә актив көрәшче. Нәкъ менә аның тырышлыгы белән егерме гектардан артык җирдәге җиләк-җимеш бакчасына нигез салына. Әле дә хәтеремдә: Мортаза абыйны без, вафат булгач, үзенең васыяте буенча, шул җиләк-җимеш бакчасына җирләдек. Җирләгәндә “Интернационал” башкарылды. Аның кабере бүгенге көндә дә шунда. Кабергә юл өзелмәсен иде.

Республика Министрлар Советы председателе булып эшләгән Сәет Шәрәфиев, хәрби начальник Шакирҗан Сабирҗанов, Турайдан коммунист Шәяхмәт Галиев, Камали Баһаветдинов, Шәргыя Гыймазова, Гаян Гарипова һ.б. – шулай ук бүгенге Тукай исемендәге колхозның горурлыгы, Октябрь казанышларын саклауда, аны тулыландыруда армый-талмый, хәтта гомере белән дә исәпләшмичә көрәшүчеләр”.

Марсель Гыймазетдинов Октябрь юбилее көннәрендә нәкъ менә әле генә телгә алып үткән каһарман авылдашлары хөрмәтенә багышлап әдәби-музыкаль композиция оештыру хәстәрен күреп йөрде дә. Әдәбият- сәнгатькә гашыйк председатель район үзәгендә “Ядкарь” дип исемләнгән әдәби берләшмәгә нигез салган. Берләшмә членнары халык алдында берничә тапкыр чыгыш та ясап караганнар инде. Якын араларда “Ялгыз яшәп кара...” дигән исем белән кичә, керәшен татарларының фольклор ансамбльләре чыгышын оештыру күздә тотыла.

- Барысына да өлгерергә кирәк, барысын да җиренә җиткереп үтәргә кирәк. Һәм аларның барысы да үзгәртеп кору рухында булырга тиеш. Аннан-моннан эшләүне яратмыйм мин,- диде председатель, саубуллашканда.

Габделбәр Ризванов,
“Үзгәртеп коручылар” китабыннан. 1990 ел.

## Туган җир моңнары

(Яңа китап укыгач)

СОҢГЫ елларда безнең әдәбиятта бер сәер тенденция – чынбарлыкны тоташ кара буяу белән сурәтләү модага кереп бара. Тормышны ал да гөл итеп ялтыратып, лаклап күрсәтү чиреннән арынып бетәргә өлгермәдек, менә хәзер шуның киресе – әлеге дә баягы, һаман шул берьяклылык – күпкырлы мохитне тарайтып, дөресрәге, кыек көзгедә күрсәтү өстенлек ала башлады.

Бу җәһәттән Марсель Гыймазетдиновның күптән түгел Татарстан китап нәшриятында чыккан “Яшәү мәгънәсе” исемле шигырьләр җыентыгы уңай якка аерылып тора, шигырьләренең оптимистлыгы, эчке җылылыгы белән җәлеп итә, кайберләре композиторлар тарафыннан көйгә салынып, радиодан, сәхнәләрдән яңгырый. Автор тормышны хәзерге заман авыл кешесе күзлегеннән карап күрә, шуның фикерләве, кичерешләре аша тасвирлый.

Ата-бабаларыбыздан изге мирас булып калган туган җиргә турылыгын ихлас күңелдән җырлый:

Очар кошлар очсын,
Зәңгәр күкне кочсын,
Ә без калыйк туган төбәктә.
Туган җирнең яме –
Яшәешнең тәме
Тамыр җәйгән безнең йөрәктә.

Күренә ки, болар күп кулланудан таушалып беткән шаблон сүзләр түгел, ә йөрәктән шытып чыккан, үз тавышы белән яңгырашлы ихлас моңнар. Әмма авторның оптимистлыгы – чынбарлыктагы каршылыкларны, кыенлыкларны күрмәү, алсу күзлек киеп фикерләү түгел, чөнки тормышта:

Җырлап бетмәгән җырлар бар,
Сөйләшеп бетмәгән сүзләр бар,
Сөрелеп бетмәгән җирләр бар,
Сөелеп бетмәгән күзләр бар...
Өзелеп-өзелеп көтеп тә
Кавыша алмаган ярлар бар...

Беренче карашка, интим лирикага тартым кыска гына шигырьдә автор тормышны киңрәк колачларга омтыла, сугыш еллары, яшьләрнең тирән фаҗигасе белән уралып, әсәр киң иҗтимагый аһән ала.

Җыентык башлыча авыл яшьләренә багышланган тормышчан сюжетлы шигырьләрдән гыйбарәт. Бу үзенчәлек мәхәббәт хисләре белән сугарылган шигырьләрдә аеруча ачыграк төсмерләнә. Менә “Үпкәлә” шигыреннән бер өзек, ул тугрылыксыз сөйгән ярга җавап рәвешендә язылган:

Беренче мәхәббәт...
Ярату...
Кирәкме яраны яңарту...
Яр таптың. Син киттең,
Мин калдым...
Боларның барсын да,
Барсын да
Син дә бит күптәннән беләсең.
Үпкәлә!
Ләкин мин гаепсез.
Язмышны син үзең алдадың...

Һәм моны гомумиләштергәндәй, икенче бер урында менә шундый гыйбрәтле дүртьюллык бар:

Бәхетлемен, дип син бер дә һаваланма –
Бәхет белән хәсрәт һәрчак йөри бергә.
Бәхетсезмен, дип син бер дә хафаланма –
Өйрәтә ул бәхетнең кадерен белергә.

Хәлбуки, кыска гына рецензиядә бөтен җыентыкка анализ ясау мөмкин түгел. Максатым – үзенчәлекле шагыйрьнең яңа китабын укудан туган тәэсирләрем белән уртаклашу, аның бүгенге авыл яшьләренең уй-хисләрен, шатлык-кайгыларын тоеп язган ихласлы шигырьләрен поэзия сөючеләр игътибарына тәкъдим итүем генә.

Марсель Гыймазетдинов – авыл кешесе, ул авылда балалар укыткан, мәктәп директоры, колхоз рәисе булып эшләгән, быел яз халык депутатларының Менделеевск район Советы башкарма комитеты рәисе урынбасары итеп сайланды. Күрәбез: тормыш казанында кайнап яши. Димәк, киләчәктә замандашларының рухи дөньясын, тормыш процессларының эчке пружинасын, этәргеч стимулларын тагын да тирәнтенрәк ачарга бөтен мөмкинлеге бар.

Сафа Сабиров

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре,

“Октябрь байрагы” ,

1 сентябрь 1990 ел

**Безнең делегат.**

**Шушы елның апрелендә С. Гассар исемендәге Культура сараенда Менделеевск районының халык җыелышы булды. Чыгышлардан, тикшерүләрдән, фикер алышулардан соң, җыелыш рәисе М.Г.Гыймазетдинов җитәкчелегендә 32 кешедән торган район Милли Мәҗлес депутатларын сайлады. Анда Марсель Гыйльфанович биш континенттан татарларның алда торган Бөтендөнья конгрессына делегат итеп сайланды. Ул үз эшен иртәгә – 1992 елның 19 июнендә Казан шәһәрендә башлый.**

Бу съездга китәр алдыннан аның белән әңгәмә кордык.

– Марсель Гыйльфанович, иң элек бераз гына оешмагыз, аның максатлары һәм бурычлары турында әйтсәгез иде.

– Районның Милли Мәҗлесе составына лаеклы депутатлар керде. Рәиснең ике урынбасары сайланды. Болар – район художество остаханәсе рәссамы Ш. Фатыйхов, “Кама” колхозы рәисе И. Миңнебаев.

Безнең бурыч – кешеләр белән эшләү, татар халкының мәдәниятен, телен яңарту, татар мәктәпләре, балалар бакчалары яки һич югы класслары һәм группалары ачу. Бүген гимназия ачу өстендә эшлибез: бина сайлап алына. Бер вариант бар: “Уралстройреммонтаж” тресты идарәсе бинасы. Район администрациясе башлыгы һәм Л.Я. Карпов исемендәге химия заводы җитәкчелеге безнең тәкъдимне яклар һәм ризалашыр дип өметләнәбез.

Районыбызда яшәүче башка милләтләрне кысарга җыенмыйбыз, алар белән дуслыкта һәм бердәмлектә эшләрбез.

– Марсель Гыйльфанович, Милли Мәҗлес район Советы депутаталары эшчәнлеген күчереп бармасмы?

– Юк, аларның эшчәнлеге тагын да киңрәк: болар – төзелеш һәм сәламәтлек саклау, мәгариф һәм культура, башка эшләр. Әгәр культураны алсак, ул чакта район Советы Барлык халыкларның традицияләрен, йолаларын, телен яңартуга теләктәшлек күрсәтергә тиеш.

– Сезнең оешманың нинди вәкаләтлекләре бар?

– Тавыш хокукы белән район Советы сессиясе эшендә катнашырга хокуклыбыз. Шулай ук тиздән үз печатебез һәм исәп-хисап счетыбыз булачак.

– Марсель Гыйльфанович, Милли Мәҗлес инде үз вәкаләтләрен файдаланды. Сездән Татарстан халыкларының беренче съездына делегатлар күрсәтелде.

– Әйе, безнең районнан бу съезда Татарстан Республикасы Югары Советының халык депутатлары В. Вахитов, Г. Ахмедов, Илнәт урта мәктәбе директоры В. Вершинин һәм мин катнаштым. Сугыш һәм хезмәт ветераннарыннан Ф.Юнысов барды. Съезд зур тәэсир калдырды. Чөнки ул дуслык җыелышы булды. Монда Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче барлык милләтләр делегат булып катнашты. Узган съездның максаты барлык көчләрне, хәрәкәтләрне, иҗтимагый-сәяси оешмаларның барысын консолидацияләү иде. Ул барча кешегә үз фикерен әйтү мөмкинлеге бирде һәм Татарстан халыклары тормышы һәм эшчәнлегенең конкрет юнәлешләре билгеләнде.

– Сез Бөтендөнья конгрессына нинди уй-фикерләр белән барасыз?

– Зур теләк белән барам. Шушы олы форумда үзебезнең Менделеевск районын күрсәтәчәгем миңа бик тә куаныч бирә. Дөрес, ул бик үк уңайлы вакытта уздырылмый. Чөнки печән өсте башлана. Ләкин мондый чара беренче мәртәбә үткәрелә һәм район Мәҗлесе кушканны үтәмәү дөрес булмас. Башка илләрдән килгән кунаклар белән танышу һәм алар арасында чиркәүне торгызу, мәчет төзү, район авылларында яңа мәктәпләр ачу өчен иганәчеләр табу нияте белән барам. Конгресстан кайткач, үз тәэсирләрем белән газетада һәм радиода һичшиксез бүлешермен.

Йомгаклау өлешендә район газетасы укучыларына тынычлык, сабырлык, намуслы хезмәт һәм дуслык телим.

*Редакциядән.*

М. Г. Гыймазетдинов – шушы зур форумда – татарларның Бөтендөнья конгрессында шәһәр һәм район халкын безнең районнан тәкъдим итәчәк бердәнбер делегат.

Районндагы “Ядкарь” әдәби-иҗат берләшмәсендә җитәкчелек итә. Ул – районндагы Милли Мәҗлес рәисе, Татарстан халыкларының беренче Съезды делегаты, Журналистлар берлеге, район администрация советы әгъзасы, шагыйрь, күп популяр җырлар авторы.

Интервьюны Люция Газина алды.
«Менеделеев хәбәрләре» газетасы,
1992 ел.

**Халык бәяне дөрес куя.**

Тукай бүләге, Җәлил бүләге, Исхакый бүләге...

Аллага шөкер, төбәгебезнең талантлы татар шагыйре Егор Уткин хөрмәтенә дә бүләк булдырылды. Бик сөендем.

Лаек кешенең эшчәнлеге бездә гомер-гомергә дөрес бәяләнмәде. Гел өстән билгеләнеп, ялагайларга, хуҗа каршында койрык болгаучыларга өлеш чыгып барды. Чоры, заманы шундый иде дип, системаны сүгү, булган гаепне хәзер инде яшәүдән туктаган "пәйгамбәрләргә" аудару мәгъкуль эш түгел, әле дә шундый хәл. Тукай премиясе белән күпме сәүдә иттеләр. Демократия вакытында яшибез, инде дөреслек килде, дисәк тә, тупас бозып, классигыбызның әсәрләрен урыс теленә тәрҗемә иткән Липкинга тоттырдылар. "Китмибез" дип ачынып язган шигырендә "с этой единой русской земли прочь… единой целью мы идем, свободной мы хотим России…» дип, милләтебезгә күләгә төшереп тәрҗемә ясый.

Хәер, районыбызда мондый гаделсезлек булмас дип ышанасы килә. Шагыйрьләрнең исемлеген төзим дип алынсаң, Уткин исеме белән беррәттән, бернинди шөбһәсез, Гыймазетдинов исеме соралып тора. Тукай белән Такташ шикелле, Туфан белән Хәким шикелле, Зөлфәт белән Әгъләм шикелле. Болар да шулай, болар да бергә.

Марсель абыйның тормыштагы торткан урынына, эшчәнлегенә кагылсаң, күп язарга була. Мин шагыйрьнең поэзия бакчасына күз йөгертеп чыкмакчы булам. Бай ул бакча, матур, гүзәл ул. Әнә, анда "Туган якның китмәс кошлары" яз ясый. Күл буенда "Аккош канат кагына", ә гүзәл "Әнисә", сөйгәнен көтеп, "Ник килмисең көлеп" дип, уйланып йөри. Әйе, могҗизага бай поэзия бакчасы.

Тәнкыйтьчеләр, гадәттә, инде берничә китабы басылган танылган язучыларга игътибар бирәләр. Алай җайлырак, чөнки тегеләрне гел мактап торалар, еш басылалар. Миңа калса, шагыйрь Марсель Гыймазетдиновны тәнкыйтьче әфәнделәр почмак артыннан гына күзәтеп торалар. Иҗатына анализ ясасам, коллегалар ничек карар да, шагыйрь кыйбласын кай тарафка үзгәртер дип. Ни дисәң дә, ике китап авторының иҗади анализга мохтаҗ икәнлеге көн кебек ачык. Ә ул күңеленә авыр алмыйча, беркемгә игътибар итмичә, яза да яза. Кыйбласы туры аның, үзгәрми. Тегеләр авыз ачып торганда, иншалла, өченче китабы да дөнья күрер.

Марсель абыйның язганы гади, аңлаешлы, шигырьләре тыйнак. Менә генә укый башлыйсың, бетте дә мени инде дип, укып та чыгасың. Укыйсы гына килеп тора. Бу җөмләсе моның ничек була соң, монысында нәрсә әйтергә теләгән дип, башны кашып утырмыйсың. Син аңлаган, мин аңлаган әйберләр. Андый шагыйрьләрне "халыкчан" диләр, гарчә барыбыз да халык арасыннан чыксак та.

Танышлар, туганнар күрешсә, "Исәнме? Хәлләрең ничек?" дип сорашалар. Ә ул миннән "Языламы, Азат?" дип хәл белешә. Языла, дисәм, минем эшләр гөрләп бара, язылмый әле бу арада дисәм, димәк, эшләр хөрти. Шагыйрь шагыйрьнең хәлен шулай аңлаша.

Юлда туктап, машина түбәсенә куеп, кул астына эләккән кәгазь кисәгенә язган шигырен укыган иде бер. Шигырьләрен сөенеп, янып укый ул. Шуңа көнләшәм мин. Һәр шигыре кадерле аңа, үз баласыдай якын. Китабыннан, гәҗит битләреннән шигырьләрен композиторлар "умырып" кына торалар. Хәтта "Аккош канат кагына" дигән популяр шигыренә 3 (өч!) композитор көй язды. Ул үзенең җырларының санын да белми торгандыр. Алар берничә

еллар рәттән елның иң популяр җырлары исемлегендә призлы урыннарны алып килә.

Туган ягыбызның моңлы җырчысы Уткинның тәүге бүләгенә шагыйрь Марсель Гыймазетдиновны кулай кеше дип тәкъдим итәм. Алты ел буена оештырып, олы юлга алып чыккан әдәби берләшмә “Ядкарь” чын мәгънәсендә данлы юл үтте. “Ядкарь” өчен бүләккә ул тагын бер кат лаек.

Марсель абыйның эшчәнлегенә тукталмам дигән идем, булмады, каләмемне кулдан төшерәсем килмәде. Шигырь, җыр, моң белән күңелләребезне баетса, табыннан өзелеп тормаган икмәк, сөт-ит белән тамагыбызны туйдырып тора. Әлле-мәлле тормыш кичергән колхозга үз теләге белән рәис булып барып, поэзиягә дип калдырылган кичке-төнге вакытларын икмәк үстерүгә сарыф итте. Юк, шагыйрьне җирдән өзәргә, халыктан араларга кирәк түгел. Ул сүнә.Җиргә сыенып, халыкка сыенып яшәү генә шагыйрьне шагыйрь итә.

Иманы белән, җаны белән татар булган Марсель абыйның әле районыбызның Милли Мәҗлесе рәисе, Бөтентатар конгрессы делегаты булуы да очраклы түгел. Халык аның шигъриятенә дә, тормыштагы эшчәнлегенә дә яратып, үзенең бәясен бирде. Бу олуг бәя – халык бәясе, халык бәяне дөрес куя. Егор Уткинның беренче премиясен күңеле моң, җыр, халкым ихтыяҗы белән, милләтем хакында борчулар, өметләр белән тулган шагыйрь Марсель Гыймазетдиновка тәкъдим итәм.

Азат Мәрдан,
“Менделеев хәбәрләре” газетасы,
1992ел.

***

**Чыннан да, тәнкыйтьче әфәнделәр, М. Гыймазетдинов иҗатына бәя бирергә “озын-озак” уйланган мәлдә, шагыйребез иҗатына чын күңелдән сөенгән, теләктәшлек белдергән һәм аңа яңадан-яңа иҗади уңышлар теләгән якташлар, көй язу өчен шигырьләрен сорап торучы композиторлар, җырларын яратып җырлаучы артистлар бар.**

**Уважаемый Марсель Гильфанович!**

В любом человеке есть два начала, два поля:
- доброе
- злое

Многие наши товарищи, пришедшие поздравить Вас, думают, что знают Вас, знают лучше меня, больше меня. Не начиная ни с кем спорить на этот счет, хочу заверить всех, мало ли, много ли мы его знаем, знаем как хорошего человека, как мощного источника <u>добра.</u>

Знаем мы Вас как энтузиаста-универсала. Вы уникальны в своей неповторимой лирике, оптимизме, дружелюбии, человечности. Как результат такой широкой натуры, широк диапазон Вашего общения. Много близких для Вас людей среди:

- тружеников полей и ферм, Вы человек земной, человек труда;
- рабочего класса;
- советских, партийных, хозяйственных руководителей;

- творческой интеллигенции (писатели, артисты, художники, композиторы);

- трудовой интеллигенции (учителя, врачи, культработники)

Везде Вы свой, всем нужны, Вы желанный гость и приветливый хозяин.

Завершается год, год белой лошади тяжелый для страны, был до невозможности уплотнен делами, событиями и датами в жизни Марселя Гильфановича.

- Ваша песня «Аккош канат кагына» завоевала симпатии телезрителей и стала лауреатом республиканского конкурса. Марсель Гильфанович стал одним из популярных авторов татарских песен года.

- вышел второй сборник стихов.

- ваш сын стал студентом мед.ВУЗа, окончив службу в рядах СА.

-депутаты райсовета оказали Вам доверие, избрав зам.пред.райисполкома, теперь райсовета. На новой работе Вы внесли новую, мощную струю в жизни района, это всех сидящих здесь нас радует.

Но, как любой оптимист, Марсель Гильфанович не соглашается на достигнутом, смотрит вперед, дальше и выше!

Всю свою сознательную жизнь вы помогали людям. Вы носитель добра! Думаю, среди сидящих здесь нет никого, кому бы Вы не способствовали добрым словом, замечаниями, наконец добрым словом.

Пожелаем же ему и его семье радостей, счастья, чтоб ему повезло во всем, в чем можно. Полнокровной жизни с друзьями, творческих успехов.

Бәхетең алдан йөрсен, Марсель абый! Яхшы яшә! Һәрвакыт бүгенгедәй матур бул!

Хезмәттәшең, дустың Зөфәр Шәкүров.

*М. Гыймазетдинов*

*Сәлам Уфадан!!!*

*Саумысез Марсель абый, кайнар сәламнәр белән Фән дип белерсез. Сәлам шулай ук семьягызга. Хатыгызны алдым, бик зур рәхмәт. Көйләр икесе дә әйбәт килеп чыкты. Венерга да, синең адресны биреп,хат язган идем, сөенеп җавап язган.”Каеннарга сарган мәхәббәтем”гә икенче мелодия дә язып җибәргән, матур гына. Шул элеккесен калдырырбыз инде, ә теге көйгә, шул ук размерда, җыр тексты кирәк. Яңарак, әйтелмәгәнрәк тема табып булса, бик шәп булыр иде. Телевидениегә үзегез хәбәр итеп карасагыз, әйбәтрәк булыр иде. Җырларны, радиодан яки телевидениедән ишеттергәч кенә, ноталарын газетага бирербез.*

*Ярый, хушыгыз, тиздән телефон аркылы сөйләшкәнчегә кадәр.*

*01.12.1991 ел.*

*****

*Марсель абый, исәнмесез!*

*Сезгә Себер якларыннан күп сәламнәр белән хат язучы Венер Мөхәммадиев дип белерсез. Марсель абый! Җибәргән җыр текстлары өчен сезгә бик зур рәхмәт. Барысы да күңелгә охшап, көй язуны сорап торалар. Менә берничәсенә көй язылды инде:*

1. *Каеннарга сарган мәхәббәтем.*
2. *Көт әле дисең.*
3. *Язлар белән китәрмен.*
4. *Әлфия.*

*Үзебезнең татар халык ансамбле “Ләйсән”дә бу җырларны яратып башкаралар. Сургут каласындагы дуслар да үзләрендә җырлыйлар. “Каеннарга сарган мәхәббәтем”не ансамбль өч тавышка җырлый, аның музыкасы икенче, Фән Вәлиәхмәтов җырлаган түгел.*

*Бу җырларны Казанга Хәмдүнә Тимергалиева алып китте. Сезгә ноталарын язып җибәрермен. Яңа шигырьләр туса, берүк миңа җибәрергә тырышыгыз. Мин аларга һәрвакыт сусап яшимен.*

*Кабат сәламнәр белән Венер.*





Марсель!
Сезнең якты йөзегез өчен
зур рәхмәт!
[illegible]
[illegible]
Кулга-кул тотышып,
дөньяда яшәргә кирәк.
Ихлас теләкләр белән
Вафирә
13/IV – 1986 ел.

**Җирдән, туган туфрактан шыткан шигырьләр.**

Шушы көннәрдә Татарстан китап нәшриятында якташыбыз, Егор Уткин бүләге лауреаты Марсель Гыймазетдиновның “Язлардан алалмыйм күземне” дигән тагын бер шигъри җыентыгы басылып чыкты. Тупланмага авторның соңгы елларда язган шигырьләре һәм популяр җырлары керде.

“Җирдән, туган туфрактан шыткан шигырьләр... МарсельГыймазетдиновның бу китапка тупланган әсәрләренә иң төгәл

бәяләмә әнә шулдыр, мөгаен. Табигать белен бер сулышта яши автор, андагы матурлыкны, сафлыкны кеше күңеленә күчерергә омтыла...”- диелә җыентыкның кереш өлешендә.

Кадерле укучылар, бу сүзләрдә безнең дә әйтергә теләгән фикерләребез чагыла. Шигърият сөючеләр бу китапны яратып укырлар, осталыкларын чарларлар, тизрәк аны кибетләрдән сатып алу хәстәрен күрерләр дип уйлыйбыз. Сезнең исемнән дә шагыйрьне яңа уңышы беләп тәбриклибез һәм сезгә дә яңа иҗат җимешләрен тәкъдим итәбез.

**Йә, Ходаем, берүк арала.**

Гомерләрне айлар, еллар саный,
Саный аны сәгать, минутлар.
Гомердән дә иң кыска ниләр бар,
Гомерләрдән озын нәрсә бар?
Яшәргә иде, яшәргә.
Гомер берәү.
Икәү түгел гомер-
Яшеннәрдәй кирәк яшьнәргә,
Ай, белмибез кадерләрен аның,
Үткәрәбез ызгыш-талашта.
Шәп яшибез кебек.Ваклыкларга
Күп гомерләр кереп адаша.
Көйләрнең дә моңы бетеп бара,
Төсләрнең дә төсе югала.
Бу дөньяга ниләр булды икән
Ниләр булды икән, йә Алла....
Шул гомернең кадерләрен белеп
...Ришвәтче, бур түрәләрдән мине
Йә,Ходаем, берүк арала...

**Китмәс идем.**

Саумы, яшьлек,
Кая барыш шулай,
Ник ашыгып узып барасың?
Әйтерсең лә ямьле язларыңны
Күралмыйча гел дә каласың.

Узма әле! Ашыгып ла узма.
Яшьлегемдә килә яшисем,
Яшьлегемдә килә сөеләсем,
Яшьлегемдә килә яшьнисем.

Китмә әле, яшьлек! Язларыңда

Тукталып кал озак гомергә...
Китмәс идем әгәр мөмкин булса,
Унҗидедән, дуслар, мин бер дә...

**Тыңла минем йөрәк тибешен.**

Нурга манып язган хисләремне
Әйтеп бирер сиңа җырларым.
Сандугачы, тургайлары белән
Шул җырларны җырлар кырларым.
Хисләремне тап төшерми генә
Карлыгачлар илтсен иртәдә.
Чык суында коенган нурларда
Рәхәтлән син,бәгърем, иркәлән.
Шул пакь нурлар үпсен чәчләреңнән.
Ләйсән яңгыр юсын битеңне.
Синнән башка тормыш булмагандай,
Синсез яшәү кыен бит инде,
Таң чыкларын ярып кил яныма,
Тыңла минем йөрәк тибешен...
...Хыялларда яшьлек елларына
Синең белән кайтып килешем...

**Тынгы бирмәм.**

Дөреслекнең гел күзенә карап,
Күпме гомер яшим дөньяда.
Бюрократны кистем,
Ялагайны ярдым,
Ришвәтчегә көн юк мин барда.
Күпме түздем яла ягуларга,
Ябырылды алар үземә.
Куркыттылар,
Майлап карадылар,
Янадылар карап күземә.
Бирешмәдем. Түздем. Көрәшәмен.
Шул пычракны түгәм бу җирдән.
Тавышымны минем ишетерләр.
Үлгәчтен дә тирән кабердән.
Ирек бирмәм карак, ялагайга
Күз буярга, кеше таларга.
Яшен ташы булып томырылып
Тынгы бирмәм һичбер аларга.

**Язмышымда калдың.**

Очрашырга сүзләр бирештек тә,
Аерылды яшьлек юлыбыз.
Башланып та җырланмыйча калды
Икәү язган моңлы җырыбыз.
Еллар узды. Гомер агышлары
Алып китте безне кайларга!
Гомер кышым килсә дә мин кайтам
Вәгъдәләшкән яшел язларга.
Моңсу миңа. Кайда яшьлегебез?!
Туймас идек сөеп, сөелеп.
Язмышымда калдың, яшьлек дустым,
Язылмаган моңлы көй булып.

**Үрләр менү, үрләр төшү.**

Гомеремнең үрләренә мендем,
Инде аны төшеп барышым.
Хәлләр ничек, картлач, ди бер көнне
Якын гына булган танышым.
Уйланылды. Әллә чынлап инде
Шулай итеп картлач булдыммы...
Күзле-башлы итәсе бар әле
Иң яраткан төпчек улымны.
Төшерде дус искә: зур улымның
Тып-тып басып йөргән баласын.
Һәм шаярып алды: белсәң әгәр
Марсель була инде бабасы.
Һәм чынлап та риза инде йөз кат
Картаймыйча картлач булырга.
Сәламәтлек теләп алдым шул чак
Киленемә, өлкән улыма.
Үрләр менү авыр – бу хакыйкать,
Ул турыда инде сөйләмим.
Гел менәргә әзер шул үрләрне
Тик төшәргә генә теләмим...

Әлфия Саматова.<br>Менделеев шәһәренең махсус хәбәрчесе .<br>“Шәһри Чаллы”,6 ноябрь, 1992 ел.

**Шагыйрь ару-талуны белми.**

Март ае башында чаллылылар шагыйрь һәм сәясәтче Марсель Гыйльфан улы Гыймазетдинов белән якыннан танышу мөмкинлегенә ия

булдылар. Шәһәрнең концертлар залында аның 50 еллык юбилее билгеләп үтелде.

Кичә иҗади әзерләнгән иде. Шигырь белән матур җыр, истәлекләр белән мәзәк сүз алмашынып барды. Шагыйрьнең иҗатына хөрмәт йөзеннән җыелган халыкның ихлас кул чабып утыруы, яшьләрнең күп булуы күңелле уйларга этәрде. Димәк, элегрәк концертларга кызык, тамаша гына эзләп килә торган Чаллы тамашачысының зәвыгы үзгәрә башлаган.

Концерт-кичәне Татарстанның халык артисты, сүз остасы Рәшит Сабиров азакка чаклы ямьле итеп, ялыктырмыйча алып барды. Марсель Гыймазетдинов сүзләренә композиторлар Сафьян Ибраһимов, Марсель Иванов, Илгиз Закиров, Зөфәр Хайретдинов, Венер Мөхәммәдиев иҗат иткән җырлар яңгырады. Аларны Казаннан Зөһрә Шәрифуллина, Зөфәр Хайретдинов, Алсу Хисамиева һәм Зөфәр Билалов, Чаллыдан Илгиз Закиров, Уфадан Фән Вәлиәхмәтов башкарды.

Марсель әфәнде үзе сәхнә түренә чыгарга кыймыйча, тамашачылар арасында утыруны кулайрак күргән иде. Әмма халык моңа риза булмады һәм юбиляр, сәхнәгә чыгып, сорауларга җаваплар бирде, үзенең иҗаты хакында сөйләде, шигырьләрен укыды.

Ул үзе Менделеевск районында күп еллар колхоз рәисе булып эшләгән.Аннары район башкарма комитеты рәисенең урынбасары вазыйфасын үтәгән. Тик бөтен гомерен иген игүгә багышлаган тынгысыз йөрәкле ир авылдан, җирдән башка яши аламы соң? Ул үзе теләп районда иң артта сөйрәлүче “Татарстан” колхозына рәис булып киткән. Хәзер аны алдынгылар рәтенә чыгару өчен тырыша. Моңа ышаныч бар – әйткән сүзен җиренә җиткереп үти белә торган кеше Марсель әфәнде. Ә колхоз йөген тарта-тарта иҗади хезмәткә дә вакыт таба алуы - үзе бер табышмак. Кичәгә аны котларга районлашлары, авылдашлары, туганнары да килгән иде. Район администрациясе башлыгы Вәсил Хуҗаҗан улы Вахитов та, барлык колхоз рәисләре дә кичәдән читтә калмаганнар. Моны шагыйрьнең талантына, хезмәт һәм иҗат белән узган гомер юлларына ихтирам күрсәтү дип санарга кирәк. Чыннан да, үзенең шигырьләрендә яшәүгә, сөюгә, тормышка дан җырлаган олы йөрәкле шагыйрьгә ничек инде сокланмыйсың да, аның таланты алдында ничек баш имисең?

**Күңелем сандыгын актарам**

Буранда адашкан юлчыдай,
Адаштым уйларым эчендә.
Күзләрнең аерылу кичендә
Сөйләгән сүзләрең исемдә.
Сөйләгән сүзләрең күңелгә
Сап-сары яфрактай коелды.
Һәр сүзең, карашың, уйларың
Кургашын болыттай тоелды.
Болытлар җил чыкса тарала,
Таралмый һич кенә сүзләрең...
Юксынып, өздереп карыйлар
Бүген дә сагышлы күзләрең...
...Буранда адашкан юлчыдай,
Адаштым уйларым эчендә.
Күңелем сандыгын актарам
Кышларның буранлы кичендә.

**Минем халкым инде уянды**

Очын-очка ялгап күп яшәдек,
Бай булмадык гомер-гомергә.
Кара чырай күрсәтмәдек. Эчтән
Әйләнсәк тә кара күмергә.
Һәрчак булдык дуслар белән бергә,
Күңелләрне юктан күтәрдек.
Кайгысын да, шатлыгын да күрдек-
Авырсынмый бүлеп үткәрдек.
Заманалар кыен иде ул чак,
Юлдаш булды анам догасы.
Шул догалар ярдәм иткәннәрдер-
Ансыз тормыш авыр буласы.
Заманалар хәзер әллә җиңел?
Тормыш итү, ай-һай, кыен ла.
Ил болганып бетте. Сугыш бара-
Күпме җаннар юкка кыела.
Көчле рухлы булыйк.Киләчәктә
Заманалар, бәлки, үзгәрер.
Шундый өмет белән өметләнеп,
Яшәрләргә язган безгәдер.

**Яшьлек тора ташып**

Яз кошлары күктә,
Яшьләр язны көтә,
Кояш нуры көләч йөзләрдә.
Яшьлек тора ташып,
Моң агыла шашып,
Сөю хисе кунган күзләргә.
Яшьлек  яшьлек инде,
Гүя алып килде
Сөю тулы назлы язларны.
Су буенда парлар
Учак ягып алар
Каршылыйлар киек казларны.
Язлар белән бергә
Кыр казлары килә,
Тик нигә бар ялгыз ак казлар?!
...Шаулы язлар үтәр,
Сизми калыр күпләр,
Әтерсең лә яшьлек шул язлар.

Өмет бер хәл. Яхшы тормыш өчен
Көрәшмәсәк, кемнәр көрәшер.
Килер бер көн, әйтер халкым сүзен:
Безнең көрәш- изге көрәштер.
Очын-очка ялгап күпме яшик?
Эшчән халык шуңа түзәрме.
Халык аңлый, ул көрәштә бүген-
Гади халык бик тә үзгәрде.
“Волга”ларда кемдер элдерткәндә
Илем халкы яши талонга...
Күңел әрни, ярдәм итә алмыйм-
Халкым минем һаман талана.
Очын-очка ялгап яши халкым,
Беркайчан да ул бай булмады.
Килер бер көн, әйтер халкым сүзен-
Минем халкым инде уянды...

Чаллы,<br>21февраль 1993 ел.<br>Рахмай Хисмәт сценариеннан.

**P.S.** Бу урында, шушы кичәдә залдан бирелгән берничә сорауга шагыйрьнең җавабын сезгә дә ишеттерәсе килә.

Сорау: – Элек әсәрләрдә гел коммунизм дип язалар иде. Ә Сез хәзерниләр турында язасыз соң?

Җавап: – Мин политиканы шигырьгә кертмәскә тырышам, туганнар. Шигырь ул – сөю-сөелү, табигать, җир-ана, авыл, хуш исле чәчәкләр, болын-тугайлар, басу-кырлар, сандугачлар-тургайлар, матурлык, сафлык, эти-әни турында булырга тиеш дип уйлыйм.

Сорау: – Марсель абый, дөньяның буталган чагы, кытлык, ашарга җитми. Кайчан бер муллыкка чыгарбыз инде? Колхоз рәисе буларак, авылны кайсы якка борырга була дисез Сез? (Студент)

Җавап: – Иманым камил: чын кешеләр авылларда яши. Алар булмаса, ил ачка үлә. Күз алдында авыллар җир йөзеннән чыкмасын өчен, тизрәк эреләндерелгән колхозлардан вак хуҗалыклар ясарга кирәк. Шулай булганда гына авыл яшиячәк. Мин үзем колхозларны аеру чире белән авырыйм. Бүгенге көндә безнең районда җиде яңа колхоз барлыкка килде. Димәк, җиде авылга җан өрдек. Менә шулай...

Сорау: – Марсель абый, сезгә карыйм да, сезнең әниегез бик тә нурлы күңелле кешедер. Мин бүген бу очрашуда аңа багышланган берәр җырыгыз

башкарылса, бик әйбәт булыр иде дип уйлыйм. Ул залда булса, таныштырсагыз иде. (Әни кеше).

Җавап: – Юк шул, әнием юк шул инде минем. Әнием 1992 елның матур июль көнендә вафат булды. Бик тә сагынам үзен. Мине бик ярата торган иде.Төшләремдә бик күрәсем, сөйләшәсем килә үзе белән. Кадер-хөрмәт күрсәтеп бетерә алмадым кебек. Соңгы хөрмәтем шул: мәрмәр кабер ташына болай дип яздым.

Йөрәк үкси, сыкрап елый йөрәк,
Кочам, бәгърем, кабреңне.
Кичер, әнкәй, ахры белә алмадым
Исән чакта кадереңне.

Сорау: – Сез шулай популяр булгач, матур-матур җырлар язгач, бик горурланасыздыр инде. Сезне кызлар бик яраталардыр, әйеме? (Бер кызый)

Җавап: – Рәхмәт, сеңелем, йөрәгемә сары май булып ятты соравың. Горурлану бармы икән? Мин оялып кына иҗат итәм. Мин бит колхоз рәисе булып эшлим һәм, иптәшләр белән очрашкач, ничектер, үземне гаепле кеше кебек хис итәм. Әллә ничек, сүз белән әйтеп бирә алмыйм моны. Шулай булса да, язмыйча булдыра алмыйм. Белсәгез иде, сеңелем, шактый шигырьләрем көй көтеп тилмерә сыман. Ә гомер кыска, диңгез буе комындагы эз сыман. Басып үтәсең, ә әйләнеп карасаң, аны инде дулкын юып алып киткән була. Гомер җырда калсын, дип язам мин...

Сорау: – Минем әтием колхоз рәисе булып эшли. Аның эше мәхшәр бит. Шундый эштә эшләп тә, сез матур-матур җыр-шигырьләр язарга каян вакыт табасыз? Һәм киләчәктә язуны ташламассызмы? (Язилә)

Җавап: – Әйе, колхоз рәисе булып эшләү иҗатыма зур зыян китерә. Иртәдән үк колхоз эше өчен үртәлүләр, ачу чыгулар, йөрәкләрне дер селкетеп ачуланышулар... Сораулар, кешеләр үтенече, ихтыяҗы – буа буарлык... Йөрәк ничек түзәдер, белмим. Әмма шул ук вакытта файдасы да бардыр аның. Чөнки колхоз рәисенең бер эш көне – үзе бер повесть. Тик вакыт җитми. Язасыларым мәңгелеккә үзем белән китмәсә ярар иде, дип борчылам. Аһ, язасы иде, язасы!

Ничек, белмим, берәр сихерен табып,
Озайтасы иде гомерне.

**Туган якның китмәс кошы.**

Без еш кына: «Шагыйрьлек —профессия түгел!— дибез.

Бәлки бу чыннан да шулайдыр. Ләкин, алай бик гади икән, нигә соң эле көндәлек эше итеп әдәбиятка хезмәт итү юлын сайламаган, чын мәгънәсендә әдәбият хадиме, телисез икән, әдәбият корбаны булырга теләмәгән кайберәүләр дә гомерләре буена “җыру” чыгаралар? Хикмәт шунда ки: әйе, шагыйрьлек профессия түгелдер, әммә ул, ышанып әйтергә мөмкин, күңел

балкышы, әйләнә тирәне үзеңчә кабул итүнең гыйбрәтле бер билгесе, халәте, рухиятнең тәэссорат чишмәләре исән-сау икәнлеген искәртеп торучы тынгысыз кыңгырау буларак, һәркемне әсир, сәййәх итәргә сәләтле могҗизаи бер көчтер, тылсым ияседер. Чыннан да, шигъриятнең “тозлы бал” тәмен татып караган, күкрәгендә “илһам камчысы”ның татлы эзләрен тойган кешеләр, гадәттә, аңарга — үтә дә нәзберек холыклы Ханымга — хыянәт итмиләр, дөресрәге, хыянәт итә алмыйлар. Чөнки ул синең бөтен барлыгыңны биләп ала; чөнки Иҗат — ләззәтле газап! Ф. М. Достоевский сүзләре белән әйтсәк, үз теләгең белән газап чигүдән лә бөегрәк ләззәт юк ул! Корифейлар өчеп генә түгел, ә бәлки көне буе завод-фабрикаларда яки басу-кырларда тир түгеп кайтканнан соң җан сурәтен ак кәгазьгә төшерү өчен кулына каләм алган күп, бик күп әһле иҗат өчен дә бу изге хис таныштыр дип уйлыйм.

Бүгенге татар әдәбиятын менә шушындый Иҗат эшен икенче шөгыле итеп яшәүче каләм ияләреннән башка күз алдына китерүе дә кыен. Миңа калса, алар татар әдәбияты күперен иңнәрендә күтәреп баручы үзәк баганаларга терәк булып хезмәт итәләр.

Марсель Гыймазетдинов — шундый иҗаткярләрнең берсе. «Шигырь язу минем һөнәр түгел» дисә дә, аның кулыннан каләме төшкәне юк. Ул — җир кешесе! Халык әйтмешли, ул кендеге белән җиргә берегеп үскән. Шигырьләре дә изге туган туфрактан шытып чыкканнар. Аның шигырьләре аяз иртәләр шикелле үтә күренмәле, саф, самими; авыл өйләре тәрәзәседәй якты өлгеле, ачык хисле дияр идем мин.

Гөрләвекләр
Язгы ташкын булып йөгерә.
Якты көннең бизәкләрен
Алып була хәтта өлгегә...

Татарстан радиосыннан ясаган бер чыгышында ул үзенең ижаты турында фикер йөртеп болайрак дигән иде:

— Мин Менделеевск районында колхоз рәисе булып эшлим. Билгеле инде, ярты гомерем басу-кырларда үтә. Яз уянып кына килгән бер мәлдәме, яисә җәйге иртә-кичләрдәме, йә булмаса көзгә кергәчме — кырлар түренә карап уйланып торасың да, ирексездән күңелгә шатлык хисләре тула һәм үзең дә сизмәстән: «Матур бу дөнья!» — дип куясың. Мондый чакларда тормышның вак-төяк мәшәкатьләре бердән онытылып китә, иркен сулыш белән яшисе килә башлый. Һәм мин шул уй-хисләремне, кодрәтемнән килгәнчә, кәгазьгә төшереп барырга тырышам.

Ак кәгазьгә төшкән ак хисләр!.. Әйе, шундый бер мизгел өчен генә дә яшәргә ярый бу дөньяда. Марсель Гыймазетднов моны яхшы аңлап яши. Әгәр ул:

Китәсем юк сездән аерылып,
Ишетәсезме, басу-кырларым!
Гомеремне сезгә багышладым.
Сезгә булсын туар җырларым,—

дип әйтә икән, монда бернинди дә арттыру юк, бу чыннан да шулай. Шигырьләре—моның ачык дәлиле. «Гомерен басу-кырларга багышлаган шагыйрьнең» җырларына әле башаклар шавы, тургайлар моңы килеп кушыла («чыксам әгәр иркен басуларга, тургай җыры чыңлый колакта»); анда «буразналар кояш назлавыннан кара икмәк кебек күперә»; кырларда аның «йөрәккәе бәйгедәге аттай җилкенә» башлый. Ул тормышның тәмен белеп яши, ул — оптимист.

...Ак томаннарга төренеп,
Тездән чык ярып кайтам.
Сагышларым — якты сагыш —
Гомеремне озайта.

Кыскасы, Марсель Гыймазетдинов бүгенге авыл тормышының бай палитралы сүрәтен тасвирларга омтыла, авыл кешесенә — игенчегә мәдхия җырлый.

Җырлый дигәннән, аның бик күп шигырьләренә төрле композиторлар тарафыннан матур-матур көйләр язылуның сере дә әнә шунда, шигырь нигезенә җыр хасиятләре салынуда түгел микән әле? Ни генә булмасын, без бүген Марсель Гыймазетдиновны бик күп популяр җырлар авторы буларак беләбез. Аның «Аккош канат кагына», «Килмисең син көлеп», «Язлардан алалмыйм күземне», «Туган якның китмәс кошлары без» кебек җырлары эстрада сәхнәсеннән төшми диярлек. Шагыйрь:

Язгы күкрәү кебек,
Яздай карый көлеп —
Эреп аксын салкын кышлары.
Без — җилкенеп очкан,
Зәңгәр күкне кочкан,
Туган җирнең китмәс кошлары.
Яз ясаучы китмәс кошлары,—

дип язган иде. Амин, нәкъ менә шулай, «туган якның китмәс җырчы кошы» булып, җирдә яз ясап яшәргә язсын аңа.

Наис Гамбәр,
“Казан утлары” журналы,
4 апрель, 1993 ел.

***

**Шагыйрь Марсель Гыймазетдиновның вафатына мәрсия.**

1993 елның 19 апрелендә 50 яшендә «Татарстан» колхоз идарәсе рәисе Марсель Гыйльфанович Гыймазетдинов кинәт вафат булды.

М.Г.Гыймазетдинов 1944 елда Менделеевск районының Бәзәкә авылында хезмәткәр гаиләсендә дөньяга килә.Бәзәкә урта мәктәбен тәмамлагач, Алабуга дәүләт педагогия институтына укырга керә.Хезмәт эшчәнлеген районыбызның гомуми белем бирү мәктәпләрендә укытучы булып башлый.1978-81 елларда-

543 нче төзү-монтаж поезды начальнигы урынбасары. Аннары яңадан укытучы булып эшләү, урта мәктәп директоры урынбасары вазифасын башкару.1985-86 елларда "Батыр кул" колхозы партоешмасын җитәкли.

1986-1990 елларда-Г.Тукай исемендәге колхоз идарәсе рәисе, 1990-1991елларда халык депутатларының Менделеевск район Советы рәисе урынбасары. Аннан соң Марсель Гыйльфанович,үзе теләп артта калган «Бондюг"совхозын җитәкләргә алына. Аның тәкъдиме белән бу хуҗалык ике колхозга бүленә:шуның берсендә – "Татарстан"да ул рәис итеп сайлана. Шушы урында ул үзенең соңгы сәгатенә кадәр эшли.

М.Г.Гыймазетдинов шәһәр һәм районның иҗтимагый-сәяси тормышында актив катнаша.Халык депутаты булып сайлана.Шәһәр һәм район җитәкчеләре, җәмагәтчелек аның авторитетлы фикеренә колак сала.Кайда гына эшләмәсен,Марсель Гыйльфанович хезмәт коллективларында хөрмәт казана.Ул теләсә кайсы-халәттәге һәм статустагы кешеләр-җитәкчеләр һәм эшчеләр,яшьләр һәм ветераннар, колхозчылар һәм зыялылар белән уртак телне тиз таба алды.Ул гадилек һәм игътибарлылык кебек сыйфатлары белән аерылып торды.

Марсель Гыйльфанович Гыймазетдинов райондагы «Ядкарь» әдәби-иҗат берләшмәсендә җитәкчелек итте.Татрстан халыкларының 1съезды һәм Бөтендөнья татарлары конгрессы делегаты итеп сайланды,Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге,район администрациясе советы әгъзасы иде.

Эчкерсез кешенең, шагыйрьнең, күп популяр татар җырлары авторының, Егор Уткин исемендәге премия лауреатының йөрәге тибүдән туктады. Ләкин меңнәрчә кешеләрнең күңелендә һәм хәтерендә аның күркәм эшләре, сокландыргыч шигырьләре һәм чәчмә әсәрләре,аның турында яхшы истәлекләр мәңгегә калыр. Менделеевлы якташлары –авыл кешеләре дә, шәһәр халкы да аны ихластан яратты. Ул халыкка булган мәхәббәтен үзенең иҗатында тирән итеп чагылдыра алды. Марсель Гыйльфанович тормышны нык яратты, көндәлек авырлыкларга һәм проблемаларга оптимизм белән карады,ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә булыша һәм теләктәшлек күрсәтә белде.

Быел Марсель Гыйльфановичка 50 яшь тулган булыр иде. Алда торган юбилее уңаеннан Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә аның әсәрләренең презентациясе үткәрелде. Ел ахырында мондый юбилей тантанасын Менделеевскида да үткәрү ниятләнде. Ләкин шагыйрьнең тормышы әдәби иҗатының иң нык чәчәк аткан вакытында өзелде. Чын шагыйрьләр тормышы һәрвакыт көтмәгәндә һәм кинәттән өзелә шул. Моңа ачык мисал- якташыбыз Марсель Гыйльфанович Гыймазетдиновның тормышы һәм эшчәнлеге, иҗаты. Аның турында якты истәлек шәһәрдә, районда һәм Татарстан

Республикасында, меңләгән райондашлары йөрәгендә беркайчан да тоныкланмас һәм җуелмас. Авыр туфрагың җиңел булсын!

Район һәм шәһәр администрациясе,
халык депутатларының Менделеевск район Советы,
халык депутатларының Менделеевск шәһәр Советы.
“Менделеевск хәбәрләре”, “Алабуга нуры” газеталары, 22 апрель,1993 ел.

## Марсель Гыймазетдиновның вакытсыз вафатына бик күп оешмалар кайгы уртаклаштылар.

Менделеевск районы һәм шәһәре администрациясе, «Татарстан» колхозы рәисе **Марсель Гыйльфанович Гыймазетдиновның** кинәт һәм вакытсыз арабыздан китүе сәбәпле, аның гаиләсенең һәм якыннарыңның тирән кайгысын уртаклаша.

Менделеевскиның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе коллективы һәм АПК работниклары профсоюзы райкомы, “Татарстан” колхозы рәисе **Марсель Гыйльфанович Гыймазетдиновның** вакытсыз вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең туганнарының, якыннарының тирән кайгысын уртаклаша

Бәзәкә авыл Советы, урта мәктәп, авылдашлары, **Марсель Гыйльфанович Гыймазетдиновның** вакытсыз вафат булуы сәбәпле, мәрхүм гаиләсенең һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклаша.

“Илнәт” колхозы хезмәтчәннәре, “Татарстан” колхозы рәисе **Марсель Гыйльфанович Гыймазетдиновның** вакытсыз вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсенең һәм туганнарының тирән кайгыларын уртаклаша.

Тат. Чаллы авыл Советы, “Татарстан” колхозы рәисе **Марсель Гыйльфанович Гыймазетдиновның** кинәт һәм вакытсыз арабыздан китүе сәбәпле, аның туганнарының һәм якыннарының кайгысын уртаклаша.

“Татарстан” колхозы идарәсе, профкомы һәм әгъзалары колхоз рәисе **Марсель Гыйльфанович Гыймазетдиновның** кинәт вафат булуына тирән хәсрәт белдерәләр һәм мәрхүмнең гаиләсенең, якыннарының авыр кайгысын бүлешәләр.

Халык депутатарының район Советы президиумы, район Советы рәисенең элеккеге урынбасары, “Татарстан” колхозы рәисе **Марсель Гыйльфанович Гыймазетдиновның** кинәт вафат булуы сәбәпле, аның гаиләсенең, туганнарының авыр

Менделеевск район халык мәгарифе бүлеге һәм СПП рәисе **Марсель Гыйльфанович Гыймазетдиновның** вакытсыз үлүе сәбәпле аның туганнарының хәсрәтен уртаклаша.

“Кама” колхозы идарәсе, профком һәм колхоз әгъзалары, **Марсель Гыйльфанович Гыймазетдиновның** вакытсыз арабыздан китүе сәбәпле, аның гаиләсенең һәм якыннарының авыр хәсрәтен бүлешә.

Менделеевск районы милли мәҗлес президиумы, Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең район оешмасы президиумы, “Иттифак” фиркасе, “Ядкарь” әдәби-музыкаль берләшмәсе, шагыйрь, “Татарстан” колхозы рәисе **Марсель Гыйльфанович Гыймазетдиновның** вакытсыз үлүе сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсенең һәм туганнарының тирән кайгысын уртаклашалар.

“Алабуга нуры” редакциясе, газетаның актив хәбәрчесе, Менделеевск районындагы “Татарстан” колхозы рәисе, талантлы җырчы-шагыйрь **Марсель Гыйльфан улы Гыймазетдиновның** вакытсыз вафат булуы уңаеннан, гаиләсе һәм туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.

**Марсель Гыйльфанович Гыймазетдиновның** вакытсыз үлеме сәбәпле, Гыймазетдиновлар гаиләсенең хәсрәтен ихластан уртаклашабыз **Врач Васильев гаиләсе.**

# *Соңгы юлга*












***

**Марсель Гыймазетдинов вафатыннан соң, төбәгебез шагыйрьләре, “Ядкаръ”челәр, дуслары шагыйрьгә багышлап бик күп шигырьләр иҗат иттеләр.**

**Фәйзелхак Хөснетдинов**
**Җыры калды**

*Мәктәп елларында яратып укыткан укучым,*
*шагыйрь Марсель Гыймазетдиновның*
*якты истәлегенә.*

Күтәрелеп күккә балкытты ул
Авыл офыкларын ялгызы.
Көтмәгәндә кинәт юкка чыкты
Авылыбызның якты йолдызы.

Йолдыз атыла да юкка чыга,
Якты эз калдырып һавада.
Шагыйрь юкка чыкса, җыры кала,
Мәңге ядкарь булып дөньда.

**Илгиз Абдуллин**
**Шагыйрь истәлегенә.**

Син ашкындың һаман,

Әй, ашкындың,
Офыкларга карап алдың да,
Ә кичләрен сүнмәс йолдыз булдың,
Үзең генә уйга калдың да.

Җырлар яздың якты көнгә атап,
Яшәү ямен җирдә мактадың.
Болыннарың, урманнарың буйлап,
Иген кырларына атладың.

Син вакытны якасыннан тотып,
Бер мизгелдә очтың ук булып.
Әллә инде галәмне дә кочтың,
Бер мизгелдә җирдә юк булып.

Кайгыларым туфрагыңа тамар
Үләндәге зәңгәр чык булып.

**Рәйсә Авзалова.**
**Аккошларың кайтыр язлар җиткәч...**
Явыз үлем алып китте сине
Якты көннән, безнең арадан.
Аккошларың кайтыр язлар җиткәч,
Син кайтмассың инде яңадан.
Менә дигән ир уртасы кеше,
Матур-матур җырлар яздың син.
Иҗат көчең ташып торган чакта
Дөньялардан нигә киттең син?
Табигатьне артык яратканга
Җылысыннан мәхрүм булдыңмы?
Күпме җырланмаган җырың калды,
Күпме язылмаган шигырең?
Син тырыштың беткән авылларны
Яңартырга, кабат төзергә.
Тынып калган авыл урамнарын
Тальян моңы белән бизәргә.
Син үлсәң дә җыр-моңнарың калды,
Яшәр алар гомер-гомергә.
Язын кайтыр тургай моңы булып,
Ә җәйләрдә башак шавында.

**Фәния Шакирова**
**Балкыр өчен җирдә хаклысың.**
*Безнең арабыздан вакытсыз киткән иҗат дустым,*
*авылдашым Марсель Гыймазетдинов гаиләсенең,*
*туганнарының авыр кайгысын уртакалашам.*
*Аңа багышланган шигыремне җибәрәм.*

Авылыбызның бер улын югалттык,
Бик вакытсыз китте арадан.
Шигърияттә йөзек кашы иде,
Кайталмасың инде яңадан.

Бу дөньяда вакытсыз китүдән
Янды, көйде бик күп йөрәкләр.
Кабереңдә тыныч йокла, дускай,
Бездән сиңа изге теләкләр.

Иҗатыңда саф йөрәгең белән
Саф мәхәббәт, яшәү, дәрт бирдең.
Хезмәтеңдә бар көчеңне куеп,
Халкың өчен икмәк үстердең.

Киттең, ләкин исемең, даның калды,
Син бу җирдә мәңге балкырсың.
Хезмәт иттең сөйгән халкың өчен-
Балкыр өчен җирдә хаклысың.

**Роберт Набиуллин**

**Яшьлегемә сәяхәт.**

*Бу шигырем яшьлегемне сагыну һәм дустым Марсель Гыймазетдинов авылыбыз Тойгуҗада эшләгән вакытта бергәләп басу-кырлар, урман-таулар, чишмә буйларында йөргән хатирәләр турында. Ул табигать кочагында үзенең шигырьләрен илһамланып укый, мине дә иҗатка рухландыра, язарга өнди иде.*

Иркен сулап йөрдек туган якта,
Сандугач моң сузды таңнарда.
Урман-кырлар,шаулап аккан сулар,
Нинди рәхәт туган якларда.
Атлыйм алга, туктый алмыйм ялга.
Эх, авылым, тып-тын зәңгәр кичләрең.
Истән чыкмый дустым белән бергә
Салкын чишмә суы эчкәннәр.
“Ышна” тау ягыннан кояш чыга
Киң җиһанга сибеп нурларын.
“Төбәк” урманы, имәнле тауларны
Сәламлиләр шигъри юлларым.
“Корбан ай” ягында жылы кояш,
“Чыршылы бүләгем”- саф һава.
Иңләп-буйлап без йөргән җирләрдә
Күңелләргә табам мең дәва.
“Нарат борыны”ның җир җиләге,
“Ачы” әрәмәсе, баланы!
Кая китеп кайларга барсам да
Сездәй татлы җирләр табаммы?
Шул җирләрдә калган бала чаклар,
Яланаяк үткән эзләрем.
Йөреп туя алмыйм туган җирләремдә,
Туган якны күреп туймый күзләрем.

**Фазыл Шәех.**

**Син яшәрсең әле жырларыңда.**

*Вакытсыз вафат булган шагыйрь дустым*
*Марсель Гыймазетдинов истәлегенә.*

Апрель җиле, әй, елады үксеп,
Дустым, синең кабер өстендә...
Сибелдең син сагыш моңы булып,
Күкләреңнән егылып төштең дә.

Шул мизгелдә җаннар тетрәп куйды,
Сызылып алды күңел кыллары.
Тургай күтәрелде сине эзләп,
Моңы белән иңләп кырларны.

Омтылган да идең чын йөрөктән
Дөньяның бар йөген кочарга.
Мәдхияләр яздың туган җиргә,
Туган яктан китмәс кошларга.

Ярсый иде синең кайнар йөрәк
Мескен хәлен күреп татарның.
Борчый иде сине еллары да
Чабышларга барган атларның.

Якты язга оча аккошларың.
Сагышларын алып сөюнең.
Ник соң безне кайгыларга салып,
Иртә килде сиңа бу үлем?!

Апрель җиле әй елады үксеп,
Дустым, синең кабер өстендә...
Син яшәрсең әле җырларыңда,
Сөю тулы назлар төсендә.

## “СИҢА ДИЕП МОҢЛЫ БЕР ҖЫР ЯЗДЫМ, СӘЙЛӘННӘРДӘЙ ТЕЗЕП ХИСЕМНӘН...”

**Наил Тимербаев**

**Марсель абый бәете.**

Туп-туры карадың да, ник моңсу күренәсең,
Әйт, матурым, серләреңне,ник шулай тилмерәсең.
Әй, матурым, китәмен мин, инде ялгыз каласың,
Миңа туры карагандай, кемгә туры карарсың

Син, Ходаем, үзең алдың карлыгачның баласын,
Ялгыз ташлап китәм инде балаларым анасын.
Шигырь яздың, тиз китәрмен, дип, киттең мәңгегә,
Тиз киттең дә сүндереп лә йөрәгемне гомергә.

Бакчабызга орлык чәчтем – чәчкәләрем үрләми,
Без корган мәхәббәт уты сүнми дә ул, сүрелми.
Киштәләрдә китапларың, төшләремә кермисең,
Мине ташлап киттең, ник өй түрендә күренмисең.

Бар да яхшы булыр диеп, сакламадың үзеңне,
Ял да итми китеп бардың, тыңламадың сүземне.
Илле яшем тула – шатлыклар да, китә кайгылар,
Калганнары инде артта калды – усал язмышлар.

Еллар үтәр, кайгы үтәр, шундый авыр булса да,
Сезгә хәер-дога юллыйм, күз яшьләрем тамса да.

**Туып үскән йортым минем.**
Туып үскән йортым минем – моңлы йортым,
Яңа түгел инде, күптән искергән.
Мин шул уйчан малай инде, синнән китеп,
Сагыныплар туймый түзгән – тилмергән.

Туып үскән йортым минем – сиңа кайтам,
Синдә җырлар туса, көйсез җырланмый.
Өй түрендә агач бишек искә төшә,
Мөмкинме соң синдә, бераз уйланмый.

Туып үскән йортым – изге нигез минем,
Чиксез рәхмәт газиз – әнкәмә.
“Әннә-әттә”- дип, телем ачылган синдә,
Нурлы йортым син – ихлас әйткәндә.
1986 ел,
*(автор: М. Гыймазетдиновка кунака баргач язылды)*

**Сагынам...**
Сагынам…
Коңгырт кара күзле
Уйчан бер әдипне сагынам,
Эзлим аны туган якларыннан,
Киң арыш, бодай кырларыннан,
Хуш чәчәкле болын – тугайлардан.
Сагынам...
Уйчан сүзле әдип
Һәр агачның телен белә иде.
Һәр кешегә кушылып көлә иде.

Пәһлевандай олуг җанлы иде,
Истә генә булып калды инде.
Сагынам...
Коңгырт кара күзле
Хисчән бер әдипне сагынам.
Еллар аша аны эзләп барам,
Шигырьләрең безнең телләрдә.
Ә җырларың күңелләрдә һаман.
Сагынам..

**Гайшә Сәгъдиева**
**Һаман безнең белән.**
Исән булып йөрисеңдер кебек
Син бүген дә безнең арада.
Ләкин юк бит, шуңа әрни йөрәк,
Очрату юк сине кайда да.
Шигъри моңың туар һәр иртәдә
Сискәндереп көн дә уята.
Үлемеңнең шундый кинәтлеге
Әрнеткечле хисләр уята.
Кыска булган, ай-һай синең гомерең
Мәңге дәвам итәр бу җирдә,
Изгелекле, йомшак саф күңелең
Тояр төсле аны үзе дә.
“Яхшылыкны җирдә ятмый!” – диләр,
Шуңамы соң изге булдың син.
Көләч йөзле, шаян, туры сүзле
Шәхес булып истә калдың син.
Һаман безнең белән яшәү өчен
Күпме эшләр җирдә калдырдың.
Йөрәк җылың белән кышларда да
Язгы тамчыларны тамдырдың.

**Һәр язда әйләнеп кайтырсың.**
Язларны өзелеп яраттың,
Язлардан алмадың күзеңне.
Шуңамы ашкынды күңелең,
Язларда сизенеп үлемеңне?
Игенченең эш башы, өмете
Һәр елны тоташкан язларга,
Табигать яшәрә, яңара,
Бар ямен бирә ул аңарга.

“Язның бер көне ел туйдыра”, - дип
Уңган игенчеләр эшне башкара.
Җирне, игенчене хөрмәт итеп
Үрнәк булып калдың башкага.
Язларда әйләнеп кайтырсың,
Син һаман яшисең яз белән.
Язгы моң хисендә йөзгәнгә
Һәр язда кайтырсың, дип беләм.

**Николай Климов,**
**Шагыйрьнең вафатына.**

Язмыштан узмыш юклыкның
Шаһиты ич бу “җиңеш”.
Гыйльфанович вафат, диләр,
Инде Марсель “юк”, имеш.

Юк, шагыйрь Марсель Гыймазны
Юк итү ансат булмас...
Кылган изге гамәлләрен
Һичкайчан онытып булмас.

Ул җитәкләгән “Ядкарь»дә
Карт булсам да яшь идем.
Хак: гүренә туфрак сипкәндә,
Яшем түгеп баш идем.

“Ядкарь”не ядкарь итәргә
Сикәлтәләр кичте ул.
Аяныч: барыбызны “ятим” итеп,
Мәңгелеккә күчте ул.

**Радость Гильфанов**

*“Ватаным Татарстан” газетасына язылган хат:“Мин, Гильфанов Радость Закирович, 1934 елда Мөслим районында тудым. Байтак еллар Чаллы шәһәрендә яшим. М. Гыймазетдиновны күреп белмәсәм дә, радиодан аның чыгышларын тыңлаганым бар, аның шигырьләренә язылган җырларны яратам. Шуның истәлегенә язылган шигыремне басып чыгарсагыз яхшы булыр иде.”*

**Тирән эзләр.**
(*М. Гыймазетдинов истәлегенә)*
Илгә муллык өсти-өсти
Гомер үтте, ләкин аз булды.
Башкармаган хыял туктап калды,
Шул булдымы адәм гомере.

Илле яшьтә кеше гөрләп чәчәк ата,
Ир уртасы шунда сынала.
Туган җиргә баскан күпме эзләр
Азрак булды инде, санама.

Тукта, Ходай,бар бит син дөньяда,
Кеше белән кешене аера беләсең.
Кем кытлыкка бара, кем көрәшә,
Син бит аны алдан күрәсең.

Кырыс булды Марсель вакыты белән,
Караклыкны хурлап кыйнады.
Үткен каләменең очы белән
Теткәләде, яклап тормады.

Туган җиргә зур мәхәббәт яклап,
Җир сулышын тойды күңелендә.
Тулып ашкан моң, дәрт аша,
Халкын күтәрде туган җирендә.

Язылмаган күпме шигъри юллар,
Җырлар китте газиз җанында.
Зур өметләр белән канатланып,
Очып-очып йөргән чагында.

Дөнья мәшәкатьләрен читкә куеп,
Туган җиргә бирдең күңелеңне.
Халкым сине гүргә озатса да,
Заман җырлар синең шигъреңне.

Ни эшлисең бит, кәһар суккан үлем,
Җәлләде бит тагын утызны.
Туган җирем үз күкрәгенә алып,
Ким итмә әле горур улыңны.

Колач җитмәс киң кырларың
Сине сагынып искә алырлар.
Башакларның талгын шаулавы,
Сәлам булып сиңа яварлар.

Гомерең синең изге юлда узды,
Хаклы син булырга оҗмах түрендә.
Ерактагы якты йолдыз булып,
Гомерлеккә калдың күңелдә.

***

**Марсель Гыйльфан улы Гыймазетдинов исән вакытта да, вафатыннан соң да Менделеевск редакциясендә һәм республикабызның күпләгән газеталарында шагыйрь турында мәкаләләр басылды: “Ватаным Татарстан”, “Менделеевск хәбәрләре”, ”Менделеевск яңалыклары”, “Алабуга нуры”, “Яңа Кама”, “Шәһри Чаллы”, “Чулман дулкыннары”, “Көмеш кыңгырау”, “Якты юл” – Тукай районы, “Ленин нурлары” – Түбән Кама, “Таң йолдызы” – КамГэсЭнергострой берләшмәсе, “Хезмәт даны” – Кукмара районының газеталары.**

**Тарих әйтеп бетерсен.**

Кеше, шагыйрь, оештыручы арабыздан китте. Хәзер күпме генә әйтсәк тә, ул юк инде. Физик яктан юк. Ләкин аның эшләре, аның шигырьләре яшәр...

Туксанынчы елның декабрендә яңа оештырылган крайны өйрәнү җәмгыяте Менделеевскийда дәүләт музееен төзү зарурлыгы турында белдергәч. М.Г. Гыймазетдинов моны берсүзсез яклап чыкты. Ул вакытта аның район Советы башкарма комитеты рәисе урынбасары булып эшләгән чагы иде. Бүген крайны өйрәнү музее Татарстан Дәүләт музее филиалына әверелде һәм аягына инде шактый нык басып килә.

Аның турыдан-туры катнашы белән районда һәм шәһәрдә күп истәлекләр ачыкланды. Марсель Гыйльфанович крайны өйрәнү буенча зур белемле, кешеләрне, вакыйгаларны, фактларны яхшы белә иде, памятникларны тикшерү процессына булдыра алганча ярдәм итте.

Ул бик күп шагыйрьләр, җырчылар, музыкантлар һәм әдәбиятчыларны белде. Шигырьләре һәм җырлары өчен аның үзен дә яраттылар, оештыру сәләтенә ихластан сокландылар. Шәһәр һәм районның мәдәният тормышында нинди дә булса вакыйга аның өчен бик кызыклы иде. Ул шулар белән яшәде. Шәһәрнең 25 еллыгы хөрмәтенә мәктәп крайны өйрәнү олимпиадасында аны районда иң популяр кеше дип таныдылар.

Узган ел, хуҗалык эшләре бик күп булуына карамастан, Марсель Гыйльфанович Егор Уткинның 60 еллыгын оештыручыларның берсе булды. Шулай ук вакытсыз арабыздан киткән каләмдәшенең әдәби һәм крайны өйрәнү премиясенең беренче лауреатларыннан булды. Юбилей чараларында актив катнашуы – М.Г. Гыймазетдиновның крайны өйрәнү эшчәнлегендәге иң югары ноктасы булды.

“Туган як җыры” җыентыгында безнең өч якташ-шагыйребез: Егор Уткин, Дифкат Сирай һәм Марсель Гыймазетдинов шигырьләре урнаштырылган. Дифкат Сирайга багышланган (аңа быел 60 яшь тулган булыр иде) юбилей чараларын оештыручылар Марсель Гыйльфановичны Дифкатнең каләмдәше һәм дусты буларак күрергә теләгәннәр иде. Тик язмыш башкачарак шул...

Республиканың шигърият тормышында вакыйгага әверелгән аның “Язлардан алалмыйм күземне” дигән китабы соңгысы булды. Иҗат эшчәнлегенең чәчәк аткан чагында шагыйрьнең үлеме – милли татар

әдәбияты өчен зур югалту. Ләкин хәтта ул язган кадәресе дә аны Татарстанның иң күренекле шагыйрьләре рәтенә куя, моның белән горурланырга кирәк.

Без, крайны өйрәнүчеләр, аның милли байлыкны – халыкның телен һәм гореф-гадәтләрен, танылган кешеләрнең биографиясен, архитектура һәм табигать һәйкәлләрен, тарихи документ һәм музей экспонатларын күз карасыдай сакларга кирәк дигән үгет-нәсыйхәтләрен онытмыйбыз. Марсель Гыйльфанович Гыймазетдиновның тормыш һәм иҗат юлы шулай ук тикшерүгә, өйрәнүгә лаек. Җирләгән көндә Бәзәкәдә матәм митингысында аның исемен мәңгеләштерү турында әйттеләр. Моңа бүген керешергә кирәк. Югыйсә, без өлгерә алмасак, тарих үзе әйтер...

В. Соловьев (крайны өйрәнү музее директоры,
Менделеевск крайны өйрәнү җәмгыяте рәисе).
“Менделеевск хәбәрләре” газетаы, 1993 ел.

**Марсель Гыймазетдинов истәлегенә.**

10-11 декабрьдә якташыбыз, шагыйрь-җырлар чыгаручы Марсель Гыйльфанович Гыймазетдиновның тууына 50 ел тулуга багышланган тантана үтте. Ул администрация, халык депутатлары район Советы, җәмәгатьчелек, шәһәр һәм район зыялыларының инициативасы һәм актив әзерлеге белән оештырылды.

Тантана шагыйрьнең туган авылы Бәзәкәдә Хәтер кичәсе белән башланып китте. Культура сарае залында бәйрәм кунаклары: урта мәктәп укытучылары һәм укучылары, авылдашлар, администрация, район Советы вәкилләре, барлык колхозлар һәм совхозлар, район предприятиеләре һәм учреждениеләре җитәкчеләре, Чаллыдан һәм Казаннан танылган шагыйрьләр һәм поэзия сөючеләр, популяр җырчылар һәм музыкантлар, радио, телевидение, матбугат работниклары, Марсель Гыймазетдиновның дуслары һәм якыннары бар иде.

Бу көнне шагыйрь һәм кеше турында зур җылылык һәм мәхәббәт белән сөйләделәр, аның шигырьләрен укыдылар, җырларын башкардылар. Шушы ук көндә бәйрәм кунаклары авыл зиратына килделәр һәм шагыйрьнең каберенә тере чәчәкләр салдылар. Алар Марсель Гыйльфанович туган һәм яшәгән йортта булдылар.

Кичен Гассар исемендәге Культура сараенда әдәби-музыкаль бәйрәм булды. Ул өч сәгатьтән артыкка сузылды. Аның программасы кызыклы, бай һәм эчтәлекле иде. Шушы тантанага махсус төстә Казаннан шагыйрьләр һәм җырчылар килде. Алар арасында Вафирә Гыйззәтуллина һәм Зөфәр Хәйретдинов та бар иде.

11 декабрьдә Бәзәкә авылында шагыйрь Марсель Гыймазетдинов туган һәм яшәгән йортка мемориаль такта куелды.

Р.Булатова.
«Менделеевск хәбәрләре»,
14 декабрь 1993 ел

.

**Җир язмышы күңелен телгәләде,**
**Туган як, дип типте йөрәге...**

Мин Марсель Гыймазетдиновны үзем Алабуга районында чыга торган “Яңа Кама” газетасында эшли башлаганнан бирле беләидем. Җитмешенче еллар ахырында ул редакциягә килеп үзенең кульязмаларын калдырып китә иде. Ул вакытта Марсель Гыйльфановичның мәктәптә эшләгән чагы булгандыр, күрәсең, аның иҗатында тәрбия, әхлак темалары күбрәк чагылдырылды.

Районыбыз Алабугадан аерылып, яңадан оешып, “Менделеевск хәбәрләре” газетасы инде төбәгебез өчен махсус чыга башлагач, аның иҗаты өчен район матбугатында тагын да киңрәк мөмкинлекләр ачылды. Бу чорда ул “Батыр кул” партия оешмасын җитәкләде, Тукай исемендәге колхоз рәисе булды. Кайда гына эшләсә дә, аның бөтен сулышында туган җирне ярату, андагы кешеләрнең тормышы, авылның киләчәк язмышы тирән тасвирланды. Гавәм тоткасының, яшәүнең, киләчәкнең язмышы авылда булуны күреп, ул туган җирдә намуслы хезмәт куючыга дан җырлады, аңа чын күңеленнән, балаларча куанды. Камайда эшләгәндә язган күләмле генә “Җир улы” очеркы – шуның ачык мисалы. Укучым хәтерләсә, анда ул колхозның алдынгы механизаторы Рафыйк Нурмөхәммәт улы Миңнәхмәтов турында язган иде. Мин аның нинди мәкаләләре басылганын санап чыгуны максат итеп куймыйм. Алар бик күп булды. Һәр шигъри сәхифәдә аның иҗат җимеше дөнья күрми калмады.

Очерклар, хикәяләр, шигырьләр язу белән бер үк вакытта ул районкүләм татар шигърият дөньясының ни белән яшәвен, район каләм ияләренеңниләр турында язуын игътибар белән күзәтте, аларга киңәшләрен бирде, рухландырып торды. “Менделеевск хәбәрләренә” язып торучы җирле каләм осталарыбыз Шәфига апа Мусина, Илгиз Абдуллин, Николай Климов, яшь каләм тибрәтүче егетләребез Зөфәр Шәйхетдинов, ул чакта Менделеевскида яшәүче инде мәрхүм Рафаэль Җәлилов, Азат Мәрдәновларның шигырьләрен тулыландырып, күзәтеп мөхәрриятка тәкъдим итеп барды. Аның энтузиазмы белән районлагы шушы барлык шигъри көчләрне бергә туплаучы “Ядкарь” әдәби-музыкаль иҗат берләшмәсе төзелде. Анда шигърият сөючеләребез айга бер тапкыр җыйналып, үзләренең әле табадан гына төшкән шигырьләрен укыдылар, фикер алыштылар. Аннан соң, шуның нәтиҗәсе буларак, алар газетабызның “Ядкарь” сәхифәсендә дөнья күрде. Шулай итеп, Марсель Гыймазетдиновның үзенең иҗаты да изге “Ядъкарь» сәхифәсендә дөнья күрде, газета укучылар күңелендә уелып калды.

Районда “Октябрь байрагы” газетасы, яңадан чыга башлап ел ярым узуга, Марсель Гыймазетдинов “Җырлыйк әле...” дигән кичә оештырды. Менделеевскиның Гассар исемендәге Культура сараенда үткән бу чара, газетага яңадан-яңа иҗат көчләре туплауга ярдәм итте. Хәбәрчеләребез арткannan-артты. Бераздан “Ана һәм бала” кичәсе яраткан артисткабыз Вафирә Гыйззәтуллина һәм аның әнисе катнашында шәһәрнең “Коммуна” кинотеатрында төбәгебезнең барлык татар әдәбиятына битараф булмаган шигърият сөючеләрен, мөхтәрәм кунакларын бергә җыйнады. Шулай ук керәшен татарлары тарихына, ислам дине темасына багышланган һәм башка

кичәләрдә дә ул башлап йөрүче булды. Үзе, бик күп репетицияләргә йөреп, спектакльләрдә катнашып, төрле образлар иҗат итте. Күпкырлы иҗат дөньясында кайнады. Боларның барысына да ничек җитешкәндер дип гаҗәпләнеп карыйсың. Болар бит барысы аның менә дигән гаилә башлыгы, ике бала әткәсе, колхоз рәисе, аннан район Советы рәисе урынбасары буларак четерекле, катлаулы хезмәте белән бергә үрелеп барды. Аның шигырьләре генә дә ни тора. Алар иң тупас, иң битараф күңелләрне дә тибрәндерәдер, мөгаен, “Шундый матур шигырьләр дә язарга ничек вакыт табасыз Сез?” – дигән сорауга, ул: “Шигъри юллар теләсә кайсы вакытта күңелгә килә дә, куен дәфтәремне тизрәк теземә куеп, онытканчы шунда ук теркәп барам”, - дия иде. Чынлап та:

“Чыксам әгәр иркен басуларга,
Тургай җыры чыңлый колакта,
Язлары да безнең кызлар кебек,
Бигрәк назлы инде бу якта”, –

дигән юлларны шагыйрь җәйрәп яткан иген кырларыннан рухланып алгандыр, безнең гади күзләребез күрә алмаган матурлыкны, гүзәллекне күргәндер, туган туфракның изгелеген, бәрәкәтен тойгандыр кебек тоела. Миңа калса, инде халкыбыз арасында бик тә популярлашкан “Аккош канат кагына” ( СафьянИбраһимов музыкасы), “Сагышларым туган якта” (Венер Мөхәммәдиев көе) җырларының сүзләрен шагыйрь төн йокыларын калдырып иҗат иткәндер, кебек. Юкса, алар шундый үтемле булмаслар иде.

Соңгы вакытта Марсель Гыймазетдинов аеруча күпкырлы иҗади тормыш белән янды. Җөмһүрият газеталарында аның шигырьләре, җырлары еш басылды. Дөньядан иртә китәсен алдан сизенгәндәй, Казан телевидениясе, радиосы аша үзе дә бик еш чыгыш ясады, шагыйрьләр, композиторлар белән тыгыз элемтәдә торды. Аның сүзләренә композиторларыбыз Зөфәр Хәйретдинов, Фәнил Ишморатов, Фирзәр Мортазин, Владимир Мироваев һәм башкалар бик күп җырлар яздылар. “Язлардан алалмыйм күземне”, “Юксынам дисең син”, “Аккош канат кагына”, “Кайтчы яныма”, “Туган җирнең китмәс кошлары”, “Китмә син” җырлары әнә шул исемлекне тулыландыралар. Аларны дулкынланмый уку, хисләнмичә тыңлау мөмкин түгел. Тәнендә җаны булган, йөрәген мүк басмаган бер генә кешене дә бу юллар битараф калдырмыйдыр, мөгаен. Әйткәнемчә, шул юллар аша нечкә күңелле шигъри җан авылны ничек яңартырга, аңа каян эшче көчләр табарга дип, көн-төн уйланды. Шул фикерен әнә шундый үтемле формада лирик хисләр белән укучыга җиткерә алды. Авыл тормышын балачактан яхшы белгән шагыйрь бүгенге катлаулы заманда яшәү тоткасының бары тик авылда булуын аңлады. Шуңа күрә дә аның бөтен тормышында, күпкырлы иҗади эшчәнлегендә авылның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында нык борчылу, кайгырту һәм аны төзек итеп күрергә теләү ярылып ята.

Марсель Гыйльфанович нинди генә постта булса да минминлекне, тәкәбберлекне белмәде. Редакция ишеген ачып керүгә үк, һәркайсыбыз белән гади итеп, үз күреп ике куллап күрешеп чыга. Аннан: “Кызлар, (гәрчә без аннан өлкәнрәк булсак та, яшьрәк дигәннәребез дә икешәр бала әнкәләре булса да) минем фәлән темага язган шигыремне алдыгызмы? Фәлән көнгә урнаштыра алмассызмы?” – дип, сорау катыш үз тәкъдимнәрен, киңәшләрен

дә әйтеп, ашыга-ашыга чыгып та китә иде. Һәрвакыт каядыр ашкынып, энергиясе ташып торган бу шигъри җанның кәгазьгә төшерелмәгән күпме сүзләре калгандыр. Бер Ходай үзе генә белә.

Исән булса, бу көннәрдә үзенең 50 яшен уздырам дип йөрер иде. Ләкин арабызда ул инде юк. Бу хәлгә ышанасы килми. Әле һаман да тере кебек. Әйтерсең лә, ул яңадан редакциягә ашыга-ашыга килеп керә дә, ике кулын сузып, олпат кыяфәттә исәнләшергә килә... Әйтерсең лә, ул исән... Әйе, ул яши, үзенең үлемсез шигырьләрендә, җырларында, күңелебез түрендә яши.

Минеһөдә Хафизова.

Бу урында сезгә шагыйрьнең берничә шигырен тәкъдим итәбез.

**Әйтче, әткәй...**

Әйтче, әткәй,
Нәрсә соң ул бәхет?
Бәхетең булсын, диләр кешеләр.
Сорап бактым
Иптәш малайлардан,
Җавап биралмады күршеләр.
Кайберәүләр әйтә:
Акчаң бик күп булса,
Бик бәхетле кеше буласың.
Гаражыңда
“Жигулие”ң торса,
Иң бәхетле кеше буласың.
Алкаларың,
Йөзек, балдакларың
Чын алтыннан булса – бәхетле.
Шул алтыннар аркасында, энем,
Кайберәүләр булган тәхетле.
– Ашаганың  йөзем,
Эчкәннәрең – шәраб,
Ястыкларың – аккош мамыктан,
Нинди бәхет кирәк сиңа тагын,
Чөнки син бит барча халыктан, –
Дигән җавап
Алам кайчагында.
Ышаналмыйм мондый сүзләргә.
Әйтче, әткәй,
Әйтче, карап минем күзләргә.
-Улым, тыңла,
Иң дөресен әйтәм:
Тәүфыйк кирәк элек бу җирдә.
Тәүфыйк-инсаф сиңа хуҗа икән,
Син бәхетле кеше бу җирдә.
Алтын, байлык, акча, “Жигулилар”
Бәхет түгел, кайгы китерә.
Илгә хезмәт итү, туган халкың сөю

Тәхетенә кадәр күтәрә.
Бәхетсез ул кеше дус-ишләрсез,
Сөйгән эшсез, сөйгән һөнәрсез.
Һич бәхетле була алмый кеше
Ал кояшка чумган көннәрсез.
Белеп яшә, улым, иң зур бәхет
Сәламәтлек, тәүфыйк һәм хезмәт.
Син шуларны кешелеккә бирсәң,
Кешеләрдән булыр чын хөрмәт.

**Юлга чыктым.**

Юлга чыктым,
Озын-озын юлым –
Һич кенә дә чиге юк аның.
Биштәремә салдым хыялымны,
Йөрәгемә халык моңнарын.
Юлга чыктым,
Озын-озак барам,
Юлсыз да бит күпме үтелде.
Дус-ишләр дә таптым, югалттым да,
Күпме уйлар, хисләр сүтелде.
Дөнья гиздем,
Күпме кеше күрдем,
Кояшын да күрдем, болытын.
Юлга чыктым,
Иге-чиге юктыр
Гомер чикле, ә юл бик озын.
Юлдай чиксез булса гомерләр дә
Ничек булыр иде кешегә!
Юк!
Мин яшәр идем кыска гомер
Мәңгелеккә калсам кешедә.

**Еламагыз, яме, малайлар.**
*(Балачак һәм яшьлек дусларым истәлегенә багышлыйм)*
Шаян идек, түбәләрдән йөрдек,
Киң урамнар безгә тар иде.
Безнең дә бит, шук малайлар булып,
Уйнап йөргән чаклар бар иде.
Карт-корының тавык кетәкләрен
Күпме генә барлап йөрмәдек.
Яшь кызларны куркытабыз диеп,
Эт-бүредәй күпме өрмәдек.
Урамнарны иңләп йөри идек,
Тальян гармун тартып кичләрен.
Күрсәң иде ташып акканнарын
Шул чакларда безнең хисләрнең!
Таралыштык, тамырдай бәйләнеп

Бергә үскән авыл яшьләре.
Кемнәр безне ил буйлап таратты,
Түгелсен дип йөрәк яшьләре...
Бушап калды авыл урамнары,
Ятим йортлар тагын артканнар.
Кыяр урлап үскән малайлар да
Урта ирләр булып кайтканнар.
Түбәләрдән түбәләргә йөргән,
Шук малайлар, кая киттегез?
Җырлы урамнарны, әйтегезче,
Никләргә соң ятим иттегез?
Кая соң сез тавык кетәкләрен
Пыр туздырып үскән малайлар?..
... Күктән яшьләр тама, сыкрап елый
Түбәләрне япкан калайлар.
Яңгыр суын ерып кайта сыман,
Бергә уйнап үскән малайлар.
Тимер булып тимер елый диеп,
Еламагыз, яме, малайлар.

**Тальян моңы тансык күңелгә.**
Сагышларга бер чик булыр әле,
Ә беразга, бәлки, түзәрбез.
Без кайтырбыз тиздән. Урамнардан
Тальян гармун тартып үтәрбез.
Тальян моңы онытылган күптән,
Гармун моңы яп-ят күпләргә.
Их, бергәләп җырлап үтик әле –
Сагыш, моңнар ашсын күкләргә.
Авылларга иңсен таныш моңнар,
Кешеләрдә хисләр уянсын.
Карт-корылар үткән яшьлекләрен
Исләренә алып уйлансын.
Аларның да яшьлекләре булган,
Тальян моңы тансык күңелгә.
Их,бер җырлап үтсәк урамнардан,
Давыл кубар төсле күңелдә.
Шул давыллар алып кайтсын әле
Яшьлегебез булган елларга...
... Тальян чыңы – минем йөрәгемдә,
Үткәннәрнең эзе – юлларда.
Шул юллардан кайтам яшьлегемә,
Шул юллардан яшәү, дәрт алам.
Тальян тартып шул юллардан барам,
Кешеләргә моң һәм наз салам.
Сагышлар да бер чак бетәр әле,
Ә беразга, бәлки, түзәрбез.
Җиң сызганып җирдә эшләр өчен,
Авылыбызга кайтып киләбез.

Минеһөдә Хафизова,
«Менделеевск хәбәрләре»,
9 декабрь, 1993 ел.

**Кеше китә, җыры кала.**

10-11 декабрьдә якташыбыз, җырлар иҗат итүче Марсель Гыймазетдиновның тууына 50 яшь тулуга багышланган тантаналар үтте.

Тантана шагыйрьнең туган авылы Бәзәкәдә хәтер кичәсе белән башланып китте. М. Гыймазетдинов хактан да авылдашлары алдында халык ихтирамын һәм мәхәббәтен яулаган: культура йорты залына олысы да, кечесе дә килү шул хакта сөйли.

Сәхнәдә – Марсель Гыйльфановичның зур портреты. Аннан безгә, үз талантына баш иючеләргә, ул бераз уйланып карый.

Шагыйрьнең: “Шатлык булып җиргә ташыйк без...” –дигән сүзләре кичәнең девизы булды. Стендларда – фоторәсемнәр, газеталардан кисемтәләр һәм, әлбәттә, шигырьләр. Өстәлләрдә күнегелгән чәчәкләр урынына арыш һәм бодай башакларыннан бәйләмнәр куелган. Бу җиргә якын, аңа гашыйк, шунда күп хезмәт куйган кеше Марсель Гыйльфановичның эшенә үзенә күрә хөрмәт билгесе.

Залда бәйрәм кунаклары: Бәзәкә урта мәктәбе укучылары һәм укытучылары, авыл кешеләре, администрация, район Советы вакилләре, барлык колхозлар һәм совхозлар, район предприятияләре һәм учреждениеләре җитәкчеләре, Чаллыдан һәм Казаннан танылган шагыйрьләр һәм шигырь сөючеләр, шулай ук популяр җырчылар һәм музыкантлар, радио, телевидение, матбугат работниклары, М. Гыймазетдиновның дуслары, якыннары. Кунакларны милли гореф-гадәт буенча бәйрәм костюмнарындагы кызлар чәк-чәк белән каршыладылар.

Бәйрәмне мәдәният бүлеге мөдире Лилия Галиева ачып җибәрде:”11нче декабрьдә якташыбыз шагыйрь Марсель Гыйльфан улы Гыймазетдиновка 50 яшь тулган булыр иде. Көче ташып торганда, аның йөрәге кинәт тибүдән туктады. Ләкин шагыйрь безнең арада үз шигырьләре һәм җырларында яши. Бүген алар яңа көч белән яңгырар.”

Борынгы гадәт буенча, авыл мулласы, мәрхүмнең рухына багышлап, дини йоланы үтәде. Шагыйрьнең апасы Римма ханым мәчет өчен сәдака тапшырды.

Халык ышанулары буенча теге дөньяга кикән кешенең җаны безнең янәшәбездә яши. Чыннан да, залда утыручыларны Марсель Гыйльфановичны шушында, залда дигән тоемлау ташламады.

Шәһәр һәм районның администрация башлыгы Вәсим Вахитов үзенең тәэсирле чыгышында шул хакта әйтте: “Бүген искиткеч көн. Яраткан шагыйребез Марсель Гыймазетдиновка 50 яшь. Без моңаерга тиеш түгел. Хәзер ул ишектән килеп керер дә, һәркемгә елмаеп: “Хәлләр ничек, егетләр?”-дип, сорар кебек. Аны районда барысы да яраттылар. Марсель Гыйльфанович җырлар чыгаручы шагыйрь генә түгел, ә бәлки бик яхшы, аралашучан кеше, мәгънәле кеше иде. Барча шагыйрьнең тормышы кыска, әмма якты. Безнең бәйрәм дә шундый якты һәм матур булсын”.

Сәхнәдә Бәзәкә урта мәктәбенең балалар коллективын оештыручы Рәмзия Гәрәй кызы Мөхетдинова. Ул шушы бәйрәм-кичәне оештыручы һәм алып баручы. Рәмзия Мөхетдинова шагыйрьнең шигырьләрен рухланып һәм сәнгатьле итеп укый, чишмә башы тарихын сөйли. Р. Мөхетдинова – шагыйрь талантына чын-чынлап баш июче, аның иҗатын җаны-тәне белән пропагандылаучы.Уңышлы табышлар, билгесез шигырьләр, җырлар, язмалар, материаллар – боларның барысын да Рәмзия Мөхетдинова укучылары белән бөртекләп җыйган. Кичә әйбәт килеп чыккан икән – бу бәйрәмгә педагог ханым ифрат зур хезмәтен, җанының бер өлешен биргән дигән сүз.

Марсель Гыйльфановичның якын дусты Габделхәй Набиуллин үз истәлекләре белән бүлеште: “Иң якын кешеңне югалту йөрәкне әрнетә. Безне Марсель белән күптәнге дуслык бәйли. Икебез дә бер көнне – 11 декабрьдә туганбыз. Гаиләләребез белән дус булдык. Хәтта үләсе көнне дә ул минем гаиләм белән хушлашырга керде. Аның: “Эх, дустым, хәлләрем бик авыр...”– дигән сүзләре бүгенге көнгә кадәр колагымда яңгырап тора.”

Габделхәй Нәбиуллин шундый тәкъдим белән чыкты: авылның иң күренекле урынында шагыйрьгә һәйкәл куярга. Моңа кадәр Бәзәкәдә мондый танылган һәм хөрмәтле кеше юк иде әле.

Шагыйрьне якташыбыз, популяр җырчы, җөмһүриятнең танылган артисткасы Вафирә Гыйззәтуллина белән зур иҗат дуслыгы берләштерде. Үзенең дусты М. Гыймазетдинов турында ул җылы һәм тәэсирле итеп сөйләде “Үлем сорап тормастан безнең арадан көчлеләрне, яхшыларны чүпли бара. Ләкин без , иҗат кешеләре, шигырьләребездә, җырларыбызда яшәвебезне дәвам итүебез белән бәхетле”. Моны раслау итеп, ул үзенең Марсельгә багышланган үтә нәзберек һәм нәфис “Тагын кайттым” шигырен укыды. В. Гыйззәтуллина М. Гыймазетдиновның үзенә бик күп шигырьләрен, җырларын җибәрүен әрнеп һәм үкенеп искә төшерә. Ә аңа ул чакта боларны башкарырга нидер комачаулый. Бу хакта артистка һәрвакыт үкенеп искә алачак һәм киләчәктә, беренче чиратта, М. Гыймазетдиновның җырларын җырлаячагын ант иткәндәй ышандырды.

Шагыйрь үз ягын яратты, ул җир кешесе иде. Шуңа күрә аның тәүге җырларыннан берсе – “Туган авылым, Бәзәкә” – җырчының иң яратканы. Көйнең авторы – җирле композитор, Алабуга мәдәният көллияте укытучысы Владимир Мироваев. В. Гыйззәтуллина бу җырны, башка җырларга караганда, аеруча рухланып башкарды. Җырчыга танылган баянчы, Татарстан Республикасының атказанган артисты Рамил Курамшин кушылып уйнады.

Тагын бер якташыбыз, танылган шагыйрь Камил Гыйльмуллин үзенең укучысына, дустына, каләмдәше М. Гыймазетдиновка “Дустыма” шигырен багышлады.

Бәзәкә урта мәктәбенең 11нче класс укучысы Эльмира Хуҗиәхмәтова шагыйрьнең “Авылым чишмәсе” шигырен укыды.

Авыл укытучысы Фәйзелхак абый Хөснетдинов үзенең шәкерте турында зур җылылык белән яратып сөйләде. Тәүге шигырьләрен Марсель аңа укыган, аннары газетага җибәргән. Турай авылы укытучысы Гайшә апа

Сәгъдиева М. Гыймазетдиновка “Марсель улыма” дигән шигырен багышлады.

Марсель Гыймазетдиновның җырлы шигъриятен сөючеләрнең берсе, аның якташы - Наилә апа Зәйнуллина. Өлкән яшьтә булуына карамастан, ул шагыйрь истәлегенә багышланган җырын башкарырга Песәйдән килгән.

Чаллыдан шагыйрьнең бердәнбер апасы Римма Гыймазетдинова үзенең кызы Лилия һәм оныгы Диләрә белән килгән. М. Гыймазетдиновның өлкән улы, авыл хуҗалыгы институтының III курс студенты Рөстәм һәм кече улы Марат та бар иде.

Бәзәкәдә М Гыймазетдинов җырларын яраталар, аларны барысы да җырлыйлар. Фәридә Бәхтегәрәева, Әнисә Идаева, Айгөл Мөхетдинова, Эльмира Хуҗиәхмәтова составындагы кызлар квартеты да искәрмә түгел. Алар барысы да урта мәктәпнең 11 нче классында укый. Кызлар җырлаганда мәктәп директоры Дамир Гыймазов баянда уйнады. Кызлар шагыйрьнең “Юксынма” һәм “Туган якның китмәс кошлары без” дигән җырларын башкардылар.

Бәйрәмне халык депутатлары район Советы рәисе Сәлим Хәбибуллин төгәлләде. Аның чыгышы гаҗәеп эчкерсез һәм җаннарга үтеп кererлек булды: “Шагыйрьләрнең гомере кыска, ләкин мин моның белән килешмим. Әгәр шагыйрьләр М. Гыймазетдинов кебек сәләтле, кешелекле, үзенчәлекле икән, аларның гомере – иң озыны”.

“Кама” колхозы рәисе Ибраһим Галимов Бәзәкәдә үткән бәйрәмнең иганәчесе булды.

Шушы ук көнне бәйрәм кунаклары авыл зиратына килделәр һәм шагыйрьнең каберенә тере чәчәкләр салдылар. Алар шулай ук, М. Гыймазетдинов туган һәм яшәгән йортта булдылар.

Марсель Гыймазетдиновның тууына 50 яшь тулуга багышланган бәйрәм узып та китте. Аның кебек сәләтле, танылган шагыйрьләр белән Ходай Тәгалә туган ягыбызны еш куандырып тормый, андый шагыйрьләр еш тумый. Шуңа күрә М. Гыймазетдинов элеккечә үзенең шигырьләрендә, җырларында, ак кәүсәле каеннар шавында, иксез-чиксез Кама киңлекләрендә, ә иң мөһиме – игелекле эшләрендә безнең белән, безнең арада яшәр дип ышанасы килә.

Роза Булатова,<br>Менделеев хәбәрләре,<br>23 декабрь, 1993 ел.

## Эстафетаны кабул итеп

Чын-чынлап, сәләтле һәм талантлы кешеләр, хәттә үлгәннән соң да, безең хәтеребездә кала. Марсель Гыйльфанович Гыймазетдинов шундый кеше иде. 10 декабрьдә Бәзәкә авылында якташыбызның юбилее билгеләп үтелде. Әлеге тантана инициаторларның берсе Бәзәкә урта мәктәбенең балалар коллективын оештыручы Рәмзия Гәрәевна Мөхетдинова булды.Сезнең игътибарга аның белән әңгәмә тәкъдим итәбез.

**-Рәмзия Гарәевна, сез балалар белән ничә ел эшлисез?**

-Бу өлкәдә 1977 елдан бирле хезмәт куям. Алабуга дәүләт педагогия институтын тәгәлләдем. Вуздан соң Алабуга районының Юраш авылында мәктәптән һәм класстан тыш чараларны оештыручы булдым. 1983 елдан Бәзәкә урта мәктәбендә өлкән пионервожатый булып 30 ел эшләгән Әдия Сәлимовна Ибраевадан эстафетаны кабул иттем. Бер суз белән әйткәндә, ул минем – остазым.

**-Серегезне ачыгыз әле: Сез ничек шулай һәрвакыт энергияле, боекмаучан,күтәренке күңелле була аласыз?**

- Мин кече яшьтән үк җырларга, биергә һәм шигырь сөйләргә яраттым. Өченче класстан ук “Коммуна” театры сәхнәсендә чыгыш ясадым. Буем бик кечкенә иде. Шундый бер очракны хәтерлим: бервакыт “Химик” стадионында зур бер чара уздырылды.Мин микрофоннан сөйләргә тиеш идем, ләкин аңа буем җитми генә бит. Аяк астыма, каян табып өлгергәннәрдер, берничә китап куярга туры килде. Ниндидер яңаны, үземнекен ачу, башкару өчен омтылу – минем эшемнең максаты. Бу минем геннарга салынган дип уйлыйм: нәрсәнедер оештырырга, барлык вакыйгалардан хәбәрдар булырга. Минем абыем да – сәхнә кешесе.

Эшемдә кирәкле тагын бер сыйфат - һәр нәрсәдә таләпчән булу.Кайчак шулай да була: чараларга әзерләнгәндә балалар белән бергә елау дәрәҗәсенә җитәбез, ләкин үз максатыбызга ирешәбез.Балалар да канәгать кала: алар белән бергә уздырылган кичә яки бәйрәмнең тамашачылар хәтерендә озакка калырын белә бит балалар.

**-Мин нәкъ менә сезнең Марсель Гыймазетдиновка багышланган юбилей инициаторларның берсе икәнегезне беләм. Аны әзерләү барышы турында кыскача сөйләсәгез иде.**

- Иң башта “Шагыйрь белән очрашу” тематикасы белән класс сәгате үткәрерү уйланылды. М. Гыймазетдинов бит үзенең 50 еллык юбилеен Казанда, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында уздырды. Шул бәйрәмне төшергән, “Ватаным Татарстан” газетасы фотокорреспонденты Мидхәт абый Шакирҗанов белән элемтәгә кердем һәм ул миңа, безнең музей өчен, байтак фотосүрәтләрен җибәрде.

Аннары җирле рәссамнарга М. Гыймазетдинов портретын язу үтенече белән мөрәҗәгать иттек. Алар да безгә булышты. Марсель Гыйльфановичның хатыны Миңнур Муллануровнага зур рәхмәт белгертәбез. Аңа ярдәм сорап берничә мәртәбә Менделеевскийга барырга туры килде. Ул безгә якташыбызның үз тавышы яңгыраган кассеталар бирде. Сез аны юбилейда ишеткәнсездер, шәт. Миңнур ханым иренә тапшырылган призларны, грамоталарны, караламаларны бирде.

Финанслау белән безгә “Кама” колхозы рәисе И.М. Галимов ярдәм кулы сузды.

Мине шушы юбилейны үткәрүгә этәргән төп сәбәп: Марсель Гыйльфанович белән, үзе исән чакта, күп еллар дәвамында аралашып яшәвебез булды. Заманында, аны халык депутатлыгына кандидат итеп сайлаганда, миңа хәтта аның ышанычлы кешесе булырга туры килде. Ә “Ана һәм бала” кичәсендә бүләк иткән бизәкле яулыгын, ядкарь итеп, әле дә саклыйм.

**-Үзегезне шулай җәмәгать эшенә багышлавыгызга гаиләгездә ничек карыйлар?**

-Уңай. Туганнарым һәм якыннарым мине аңлыйлар һәм булышалар. Минем ирем, балаларым шулай ук үзешчән сәнгатьтә катнашлар, җырлыйлар, бииләр һәм спектакльләрдә катнашалар.

**-Газета укучыларына берничә җылы сүз әйтсәгез иде.**

-Халкыбыз үз традицияләрен, үзенең милли культурасын онытмасын дип хыялланам. Шуңа күрә үзем, 20 еллап, туган якны өйрәнүче “Мирас” түгәрәген җитәклим. Районыбызда шушы якны таныткан, данга күмгән кешеләр булуы белән горурланам.

Интервьюны
С. Савина алды.
Декабрь,1993 ел.

## Ул һәрдаим-күңелләребездә

Шагыйрь Марсель Гыймазетдиновның 50 еллык юбилеена багышланган кичәне районның администрация башлыгы урынбасары Илсөяр Гобәйдуллина ачып җибәрде.

Сәхнә бәйрәмчә бизәлгән. Гассар исемендәге Культура сараеның зур залында – Казаннан, Чаллыдан, Алабугадан килгән кунаклар, шулай ук район, предприятие һәм учреждение җитәкчеләре, шагыйрьнең туганнары һәм дуслары, аның талантына баш иючеләр.

“Мин яшәрмен әле, яшәрмен!” – дип язган иде үзенең бер шигырендә шагыйрь. Ул хаклы. Чөнки М.Гыймазетдинов, 3 сәгатьтән артыкка сузылган кичә барышында, (алып баручылар Илсөяр Гобәйдуллина (рус телендә) һәм Мөхәммәтнур Сабитовларның (татар телендә)) яңгыраган үзенең сокландыргыч җырларында һәм шигырьләрендә яши.

Кичә гаҗәеп эчтәлекле, җылы һәм бай узды. Тамашачыларны талантлы кешеләр, шагыйрьнең каләмдәш һәм иҗат дуслары, хезмәттәшләре белән очрашу көтте. Алар арасында Рахмай Хисмәтуллин, Рафис Гыйльфанов, Борис Казаков, Камил Гыйльмуллин, Мөдәрис Әгъләмов, Таңчулпан, Шәмсия Җиһангирова, Илгиз Абдуллин, Фәния Шакирова һәм башкалар бар иде.

Каләмдәш дуслары шагыйрь белән очрашулар турында истәлекләре белән бүлешеп, үзләренең Марсель Гыймазетдиновка багышланган шигырь-хатирәләрен укып кына калмады, ә бәлки аны югалтуның берни белән дә тулыландырып булмавы, шагыйрьнең гомере вакытсыз өзелүе турында сөйләделәр.

Әдәби-музыкаль композиция, шагыйрьгә гашыйкларны, аның биографиясе, хезмәт эшчәнлеге белән таныштырды.

Аның артык камил булмаган, ләкин ихлас күңеленнән ургылып чыккан беренче шигырьләре җирле матбугатта, Марсель Гыймазетдинов бишенче класста укыган вакытта дөнья күргән. Шул гомердән бирле район газетасы аның иҗат җимешен даими бастырып килә. Шуңа күрә Марсель Гыйльфановичның шигырьләре районның иң ерак почмакларына кадәр барып җитә.

Район һәм шәһәрнең администрация башлыгы Вәсим Вахитов үзенең чыгышында М.Гыймазетдиновны халык шагыйре дип атады.

Шагыйрьләр иҗатына багышланган мондый кичәләр инициаторы, районның крайны өйрәнү музее директоры Виктор Соловьев М.Г.Гыймазетдинов шигырьләре ярдәмендә татар поэзиясен тирән хөрмәтләвен һәм яратуын белдерде.

Мәдәният бүлеге мөдире Лилия Галиева җыелучыларга Марсель Гыймазетдинов шигъриятен яратулары өчен рәхмәт сүзләре белән мөрәҗәгать итте, шагыйрьнең шигырьләрен укыды.

Үзешчән артистлар Роза Софронова, Иван Качаевлар тантанада катнашучыларны җырлары белән куандырдырдылар.

Кичәдә очрашуны алып баручы Мөхәммәтнур Сабитовның шагыйрьнең якын кешесе, тормыш юлдашы, дусты, хатыны Миңнур Муллануровна турында сөйләве дулкынландыргыч, истә калырлык татлы мизгел булды. Кызганычка каршы, бик тә нигезле сәбәп аркасында кичәдә ул катнаша алмады. Ләкин иң матур чәчәкләр, иң җылы сүзләр һәм шушы сокландыргыч шигырь юллары аңа багышланды:

Нинди шатлык җирдә синең булу,
Нинди бәхет синең яшәвең.
Сөенәм мин-юлдаш булдың миңа,
Бәгърем, диеп сиңа дәшәмен.
Кайгыларны бергә-бергә җиңеп,
Ләззәтләндек тормыш көенә.
Бар булганым җаным-тәнем белән
Шөкер итеп шуңа сөенәм.
Якын дустым булдың миңа һәрчак,
Тормышымда булдың юлдашым.

Син бары бул минем белән генә,
Сөю гөле генә сүнмәсен...

Миңнур Муллануровна утыз ел гомерен мәктәпкә багышлады.Гыймазетдиновларның куанычлары да, борчу-хәсрәтләре дә булмады түгел, ләкин 27 ел буенча барысы да уртак итеп бүленде. Бергәләп ике ул: Рөстәм белән Маратны үстерделәр.

Шагыйрьнең апасы Римма ханым һәм аның кызы Лилия, кичәдә ихлас рәхмәтләрен әйтеп, чыгыш ясадылар.

Җөмһүриятебезнең популяр артистлары Вафирә Гыйззәтуллина, Рамил Курамшин, Зөфәр Хәйретдинов, Марсель Ивановларның чыгышы тамашачыларны һәм бәйрәм кунакларын шатландырды.

Бәйрәм халык депутатлары район Советы рәисе Сәлим Хәбибуллин чыгышы белән төгәлләнде: “Шагыйрьләрнең гомере кыска, ләкин мин моның белән килешмим. Әгәр шагыйрьләр Марсель Гыймазетдинов кебек сәләтле, кешелекле, үзенчәлекле икән, аларның гомере – иң озыны”.

Сәлим Хәбибуллин моны раслар өчен “Кешегә” исемле шигырь укыды һәм бәйрәмне әзерләүдә катнашучыларның барчасына шушындый җылы, матур кичә өчен рәхмәт белдерде.

Бәйрәм финалында сәхнәдә барлык тамашачылар, кунаклар, артистлар бергәләп “Аккош канат кагына” җырын башкарды.

Роза Булатова,
Менделеевск хәбәрләре,
12 февраль 1994 ел.

**Марсель Гыймазетдинов музее.**

Шагыйрьнең вафатына нәкъ 1ел тулган көнгә, Бәзәкә урта мәктәбендә, үзем укыткан укучыларым, шәкертләрем тырышлыгы белән Марсель Гыймазетдиновка багышланган бүлмә ачтык. Әлеге бүлмәдә шагыйрьнең туган һәм вафат булган көннәренә багышланган бик күп чаралар, “Ядкарь”челәр, Алабуга, Чаллы язучылары һәм шагыйрьләре белән очрашулар оештырылды. Сәнгатьле шигырь уку, шагыйрьгә багышланган әдәби иншалар язу конкурслары һәм башка төрле бәйгеләр үткәрелде. Менә шуларның кайберләре:

“Шагыйрь белән очрашу”–1993, апрель;

“Мин яшәрмен, мәңге яшәрмен”–1994, декабрь;

“Минем күңел җырны сөя, моңны ярата...”– 1995 ел (Бу композиция белән, район конкурсында катнашып, “Ел укытучысы” исемен яуладым.)

“Якташлар – сәнгатьтәшләр”–1996, апрель.

“Кеше килә, кеше китә –
Ә яшәү дәвам итә” – 2000 ел;      һәм башкалар.

Шагыйрь бүлмәсендә бик теләп күпләгән авылдашлар, райондашлар, танылган шәхесләр булдылар. Алар арасында Татарстан Югары Советы

депутаты, драматург Туфан Миңнуллин, язучы Нәбирә Гыйматдинова, шагыйрь Нәҗип Мадьяров һәм җирле композиторлардан Владимир Мироваев (ул гаиләсе белән һәрчак безнең чараларда актив катнашты), Зиннур Мөхәммәтдинов һәм башкаларның булулары, аларның бүлмәгә уңай бәя бирүләре – укучылар һәм укытучылар өчен зур шатлык булды.

1999 елда бүлмәгә Татарстан Мәгариф министрлыгы комиссиясе тарафыннан 306 нчы номерлы таныклык белән “ Менделеев районы Бәзәкә мәктәбенең әдәби музее” – дигән исем-статус бирелде.

Рәмзия Мөхетдинова.

**Исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен бел...**

Мәрхүм Марсельне күмү һәм хушлашу өчен ирем һәм якыннарым белән Бәзәкәгә бардык. Бәзәкә зияратының чисталыгына һәм андагы тәртипне күреп хәйран калдык. Шагыйрь Марсель Гыймазетдинов үзенең зурлыгын, бөеклеген кешеләргә үлеме белән исбат итте. Шигырьләрне бары илаһи көчкә ия булган иман җанлы кешеләр генә яза алганны күпләр белми:

Мәрхүмнең хөрмәтенә багышлап, Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлегендә эшләүче шагыйрь Рахмай Хисматулла Коръән укыды. Халык диңгезе эчендә Коръән укучыны табып рәхмәт әйтүе дә җиңел булмады.

10 декабрьдә Гассар исемендәге культура йортында мәрхүм Марсель Гыйльфан улы Гыймазетдиновның 50 еллык юбилее уздырылды. Юбилей кичәсе зур бәйрәм төсен алды. Адәм хатадан хали түгел. Зал тулы халык алдында, район Советы рәисе Сәлим Ханнан улы Хәбибуллин, матур итеп, саф татар телендә, үзенең дә Марсель алдында кайбер гәепләре булуына уфтанып чыгыш ясады. Марсельдән, аның туганнары алдында гафу үтенде. Бу чыгыш мине нык тетрәндерде. Сәлим әфәнде, моның белән халык алдында хөрмәт казанды, дип әйтергә батырчылык итәм. Миңа юбилей кичәсендә тагы Рахмай Хисматулла белән очрашырга насыйп булды. Ул миңа үзенең “Ак догалар” дигән шигырьләр китабын бүләк итте. Шулай бу кичәдә күптәнге хыялым тормышка ашты. Чөнки яраткан шагыйрем, талантлы Мөдәррис Әгъләмов сәхнәдән узенең Марсель яраткан шигырен укуын ишетеп шатландым һәм шагыйрь белән таныштым. Аллага шөкер, язмышым мине мөхтәрәм кешеләр белән очраштырып, күрештереп тора.

Марсель минем шигырьләр яратуымны белә иде. Шәһәргә язучылар, шагыйрьләр килгәндә, өебезгә кереп, очрашу кичәсенә чакырып торды. Үзенең яңа басылган шигырь китапларын бүләк итеп барды. 1990 елның кышында, әдәбият яратучылар белән очрашу өчен, Менделеевскийга язучылар: Газиз Кашапов-Үзиле, Рәшит Гәрәй, Мәдинә Маликова килделәр. Кашапов Хәсән Туфанга багышланган романының икенче кисәген яза башлавын шатланып сөйләде. Үкенечкә каршы, озак та үтми, май аенда

ахрысы, башлаган эшен бетерә алмыйча, ять-яшь килеш дөнья куйды. Шул кичәдә мин Марсельдән “Әй, кешеләр!”дигән шигырен укуын сорадым. Шул шигырьдән өзек китерәм:

Нишләдек без?-
Иманыбыз качты,
Гел алласыз түгел идек без...
Нишлибез без?
Гөлбакчалар чабып,
Урынына гараж төзибез.
Әй, кешеләр, сезгә эндәшүем;
Ташка әйләнмәсен күңелләр,
Җанварларда берсен-берсе сөя-
Без әлегә җанвар түгелләр...

Марсель аз яшәсә дә, данга күмелеп үлде. Мондый зурлау, хөрмәтләү бик аз кешеләргә генә насыйп була. Әнисе үлгәннән соң, ул безгә ешрак керә башлады, әнисен зурлап искә ала иде.

Әйтеп бетермәгән үкенечле сагышлары белән газаплануы сизелә иле. Аның үз кабере дә әнисе белән янәшә булды.

Сөембикә Ихсан Сәйфуллина,
“Менделеевск хәбәрләре”,
30 апрель, 1994 ел.

**Марсель турында хатирәләр.**

Шундый бер очрашу искә төште. Марсель, үзе теләп, иң артта сөйрәлә торган "Татарстан" колхозына рәис булып барганын күпләр беләдер. Кадыйр белән безгә шул колхозга барырга туры килде. Менделеевскийда безне аның шоферы каршы алган булса, соңыннан рульдә Марсель үзе булды. Басу-кырларыннан үтеп барганда, ул гел җырлар көйләп бара. Хозурлык инде! Бер арада: "Арпа да өлгереп килә, тиздән ураккадыр", - дигән булдым, үзенә күрә авыл баласы бит мин дә. Азрак баргач, шагыйрьләр икесе дә җиңел генә кабинадан сикереп төштеләр дә басу кырына юнәлделәр. Гәпләшер өчен бик аулак урын иде ул алар өчен. Кире килгәндә, Марсель учына тук башаклар җыйнап тоткан иде. Ул аларны миңа бүләк итте. "Бу арыш башаклары букеты сезгә, ханым. Исләре дә исләре!" – дип, кулыма тоттырды. Ә бит ул: "Ялгышасыз, арпа түгел, арыш ул, ханым", - дип тә әйтә алган булыр иде. Никадәр итәгатьлелек, зыялылык бөркелеп тора иде шул аңардан. Бу 1992 ел иде.

1993 ел. Марсель Гыймазетдиновны искә алу кичәсе. Секунд арасында булды бу хәл. Каты гына урындык шыгырдады. Янәшәдә утырган Наис Гамбәр, оста акробат шикелле, Кадыйр белән минем аша сикереп, үзен өстәл өстеннән атты һәм, җырлап торган Вафирә Гыйззәтуллина каршысына. тып итеп килеп басты. Карлыгач канатлары шикелле җәелгән куллары, биеп

китәргә җыенган кебек, һавада асылынып тордылар. Бүтән шып иткән хәрәкәт тә булмады. Табын тын калды. Каләмдәше, дусты үлеменә җаны сызланган шагыйрьнең, әлеге моңсу мәҗлестәге шушы сүзсез чыгышы – түзеп була алмаслык күңеле талпыну җанының атылуы иде бу.

Чүттән генә фаҗига булмый калды, диештек. Гамбәр җырчының каршына бик якын килеп төште. Вафирә, күп дигәндә, бер биш сантиметр гына артка чиккәндер. Ни гаҗәп, шундук икесенең арасында, шыбырдап койган су шәүләседәй, һава дулкыны уйнаклап алды да сүнде. Ул арада Вафирә җырын дәвам итте. Гамбәр дә үз хәленә кайтты.

И, дөньялыктан иртәрәк киткән изге җаннар! Вакыты-вакыты белән, сагындырып искә төшәсез дә, уйландырмый калмыйсыз шул.

Тагын бер хәтирә. 12 май 1993 ел. Бәзәкә авылы клубында Марсель Гыймазетдиновны искә алу кичәсе узды. Апасы Римма ханым сөйләве буенча, 19 апрель көнне, шушы клубта Марсель, 50 яшьлек юбилей елы уңаеннан, үзенең иҗат кичәсен үткәрергә уйлаган. Әмма шул көнне ул вафат була. Шуңа күрә, әлеге хәтер кичәсе, кара тасмаларга уралып үтте. Сәхнә бизәлеше: шагыйрьнең портреты, китаплар, башаклар...

“Хәл белергә килә авылдашлар,
Хәл белергә килә якын дуслар.
Бүген бары минем өчен генә
Җырлый-җырлый ага инешләр”.
(Марсель Гыймазетдинов)

Бу шигырьне сәхнә түренә язып элеп куйганнар иде. Әйе, килделәр дуслары, каләмдәшдәре Чаллыдан да. Каберенә чәчәкләр куйдылар. Дога укыдылар..

Кадыйр Сибгатуллин сөйли: "Марсель, чынлап та, армый-талмый эшли торган кеше иде. Хәтердә шулай калган, аның өчен ял юк, ялны белми иде ул. Талантларны югалтабыз. Кадерли белмибез. Эшләгән эшләрен җыеп, аны саклаучы була икән, рәхмәт аңарга. Ул әйберне онытмасак иде. Марсель бик намуслы кеше иде. Аллага шөкер, без аның истәлеген югалтмадык. Дөрес, без аны Союзга алырга өлгермәдек. Үзе белгән, үзе сизгән кебек, декабрьга кадәр 50 еллык юбилее да үткәрелде. Иҗатын бөртекләп, җентекләп җыйныйк, саклыйк Марсельнең!"

Җырчы Саҗидә Әхмәтгалиева Хәсән Туфан сүзләренә язылган җырны башкарды. "Белми калдым, сизми калдым..." Кичә җыр катыш моң, сагыш, күз яшьләре белән үтте. Чаллыга кайтышлый, Марсель хозурланып йөргән урман аланлыгына тукталмый булдыра алмадык, билгеле.

Фәния Хәммәтова
(Кадыйр Сибгатуллинның хатыны),
1994 ел.

## В твоих песнях — твоя муза.

Под таким названием недавно в средней школе Ижевке прошёл литературно-музыкальный вечер, посвященный памяти Марселя Гимазетдинова. В просторном кабинете татарского языка собрались гости: председатель районного Совета С. Х. Хабибуллин, глава администрации В. Х. Вахитов, референт аппарата Президента РТ Д. З. Габдрахманов, односельчане, преподаватели татарского языка школ района, учителя поэта, школьники. Кабинет был убран со вкусом.

– Уважаемые гости! Сегодня у нас большой праздник, день памяти известного поэта, нашего земляка Марселя Гимазетдинова. На днях ему бы исполнилось 51. Он родился и вырос в деревне и всю жизнь сохранял верность родной земле. — С такими словами обратились ведущие вечера, преподаватели школы Фания Шакуровна Мухаметдинова и Зухра Раисовна Гарифуллина. После этого они предоставили слово учителям и ученикам Ижевской средней школы. В их исполнении прозвучали стихи и песни на слова М. Гимазетдинова.

Учитель поэта, ветеран Великой Отечественной войны Файзелхак-ага Хуснутдинов рассказал о школьных годах М. Гимазетдинова. Его первые стихи начали печататься в школьной стенгазете и районной. Марсель тогда учился в пятом классе. Каждую школьную литературную стенгазету стали украшать его стихотворения. Часто печатались его рассказы, очерки о родном крае, о знаменитых людях, земляках.

Сейчас, когда у нас проснулась национальная гордость, когда мы чувствуем, что в нашей душе чего-то не хватает, имя М.Гимазетдинова, воспоминания о нём нам особенно дороги. Он созидал стихи о жизни, о любви к родной земле, о нравственности – это своеобразное наследие его жизни. В стихах достойное место занимает уважение к тем, кто растит хлеб. Поэт любил жизнь и к повседневным проблемам относился оптимистически. Всегда помогал нуждающимся, проявлял солидарность. Постоянно изучал национальное богатство, обычаи народа. Родную деревню, материнство считал святыми. Его благодарность и сердечные чувства к матери ясно видны в стихотворениях. Об этом говорили в своих выступлениях односельчане.

Автор многих песен Зиннур-ага Мухаметдинов из Псеева был на этой встрече в роли почётного гостя. Он рассказывал о совместной творческой деятельности с поэтом. Песни на слова М. Гимазетдинова прозвучали в исполнении самого композитора.

Учителю ветерану Гайше апе Сагдеевой тоже было чем поделиться. Она хорошо знала поэта. Г. Сагдеева декламировала свои стихи, посвященные М. Гимазетдинову, вспоминала интересные мгновения.

Песни на слова поэта «Аккош канат кагына», «Ник килмисең көлеп», «Туган ягым көзе», «Юксынам, дисең син» исполнили учащиеся и учителя школы. Когда учительница Р. Газизова исполняла песню В.Мироваева на слова поэта «Җырланмыйча калды безнең җыр», у многих в зале на глазах заблестели слёзы. Да он остался в своих песнях...

В конце ветеранам вручили памятные подарки. Председатель районного Совета С. Х. Хабибуллин, глава администрации В. Х. Вахитов поблагодарили организаторов и гостей встречи за прекрасный вечер.

М. Хафизова,
газета «Менделеевский вестник»,
7 января, 1995г.

**Мы помним о них.**

В один из морозных декабрьских дней возле дома номер 6 по улице Октябрьской собрались те, кто чтит и помнит нашего местного поэта Марселя Гимазетдинова. В этом доме Марсель абый прожил два последних года. И поэтому здесь состоялось открытие мемориальной доски. Присутствовали на торжественном событии родственники поэта, гости из Набережных Челнов (журнал “Аргамак”), из Казани, из Бизяков, а так же депутаты районного Совета народных депутатов. Перед открытием мемориальной доски выступили многие присутствующие. В частности, глава администрации нашего района. В.Вахитов особо отметил то, что на нашей земле Бондюжской- Менделеевской выросло много талантливых людей, чем мы и гордимся.

Стихи Марселя Гимазетдинова навсегда останутся с нами. Их читают множество менделеевцев, жители района. На его стихи сложены песни. И забегая вперёд скажу, что при беседе с заместителем главного редактора журнала «Аргамак» М. Г. Сафиным выяснилось, что вскоре редакция журнала намерена в рубрике «Новости культуры» печатать материалы о поэтах Менделеевского района. О талантливых людях нашего района, естественно, помним и мы. Поэтому после торжественного открытия мемориальной доски все участники были приглашены в выставочный зал краеведческого музея.

Присутствующие в этот памятный день смогли подробнее ознакомиться с творчеством Марселя Гимазетдинова. Стенд оформлен фотографиями, из которых видно, что М. Гимазетдинов был и поэтом, и педагогом, и спортсменом, и публицистом, и актёром. Здесь же стоит и гармонь, на которой когда-то играл наш земляк.

С. Савина,
газета «Новое время»,
28 декабря, 1995г.,
г. Менделеевск.

**Җырлы-моңлы очар кошыбыз.**

**Шигърият дигән бай тарихлы, дәвердән-дәвергә күңелләрне сугарып килгән олы дәрья бар. Мул сулы диңгезләр, зур дәрьялар бик кечкенә инешләр һәм вак чишмәләр исәбенә байый. Шигърият дәрьясын да бихисап күп кушылдыклар тулыландырып тора. Бу кушылдыклар- һәр шагыйрьнең иҗат чишмәсе ул. Сүзем соңгы елларда шушы дәрьяга үзенчәлекле агышы һәм иң мөһиме- тешләрне камаштырырдай саф, тәмле сулы инеш булып кушылган Марсель Гыймазетдиновның иҗат**

**чишмәсе хакында. Бу чишмәнең “яме, суы тәме” нидән гыйбарәт һәм күңелләрне ул никадәр сугара да, шигъриятькә сусаучыларның тансыгын ничек кандыра соң?**

11 декабрь көнне районыбызда җирле шагыйрь Марсель Гыймазетдиновка 55 яшь тулу көне билгеләп үтелде.

Иртәнге сәгать 9 да шагыйрьнең соңгы елларда яшәгән йорты янында митинг уздырылды. Анда Марсель Гыйльфан улының иҗатын хөрмәт иткән менделеевлылар, Яр Чаллы һәм мәркәзебез Казан шәһәреннән килгән кунаклар җыелды.

Алып баручы - татар китапханәсе хезмәткәре Чулпан Насыйрова тантананы түбәндәге сүзләр белән башлап җибәрде:

- Монан нәкъ 55 ел элек яраткан шагыйребез, якташыбыз дөньяга килгән. Декабрь аеның салкын җиле бу көнне кар баскан басулар, кырлар буйлап Бәзәкә авылының ямьле тугай- болыннары, саф сулы чишмә-елгалары, Кама буеның матурлыгы, туган як һәм авыл кешеләренә, икмәк үстерүчеләргә дан, мәдхия җырлаячак бер нарасый туу турында хәбәр тараткан булгандыр, мөгаен. Ул вакытта әле беркем дә, Марсель абыйның Татарстанга гына түгел, башка төбәкләргә дә билгеле булачак туган-якның садә җырчысы буласын башына да китермәгәндер, әлбәттә.

Син үлсәң дә җыр-моңнарың калды,
Яшәр алар гомер-гомергә.
Язын кайтыр тургай моңы булып,
Ә җәйләрдә башак шавында.

М.Гыймазетдиновның шигырьләре укучыны битараф калдырмый, чөнки алар халык күңелен телгәләгән хисләр белән сугарылган. Билгеле, һәр шагыйрьнең илһам чыганагы – аның туган ягы, туып-үскән нигезе. Һәркем аны үзенчә яктырта, аны сурәтләү өчен үзенә генә хас шигъри чаралар таба.

- Әлеге исем, аның белән бәйле истәлекләр, аның калдырган иҗат җимешләре безнең өчен кадерле,- дигән сүзләр белән башлап җңибәрде хакимият башлыгы В.Вахитов үзенең чыгышын. – Талантлы шагыйрь, күренекле шәхеснең гомере иртә өзелде, ләкин ул үзеннән соң якты эз, олы мирас калдырды. Аның кеше күңелендә уелып калырдай сүзләр белән язылган шигырьләрен халык яратып укый. Көн саен аның сүзләренә язылган җырлар радио һәм телевидение аша яңгырый. Менделеев төбәгендә туып үскән андый шагыйрьләр – районыбыз горурлыгы. Аларның иҗаты буыннан-буынга күчсен һәм халыкны сөендерсен.

Поэтик кичәдә Яр Чаллы язучылар оешмасының җаваплы сәркатибе Вахит Имамов әдип белән иҗади хезмәттәшлеге турында сөйләде.

Хакимият аппараты җитәкчесе Тәскирә Галиева да үзенең уй-фикерләрен җиткерде: “Без әдип белән бергә эшләдек. Кайда гына эшләсә дә, җаны-тәне белән бирелеп хезмәт куйды. Җитәкче булгач, төрле кешеләр белән очрашырга туры килә. Ләкин ул нечкә күңелле шагыйрь булгангадыр, күрәсең, кешеләр белән уртак фикер, аларның йөрәгенә үтеп керерлек сүзләрне тиз табучы, кешелекле, тормышны яратучан кеше иде”.

Туган якны өйрәнү музее директоры В.Соловьев Е.Уткин исемендәге премия бирү турындагы фикерне М.Гыймазетдиновның яклап чыгуы һәм аны

тормышка ашыруда ярдәм итүе турында әйтеп үтте. Район газетасының баш мөхәррире Рахман Шафигуллинның әйтер сүзләре күп иде бу көнне:

- М.Гыймазетдиновны мин 1984 елдан бирле беләм. Ул вакытта мин Казан телевидениесенең Яр Чаллы төбәге буенча үз хәбәрчесе идем. Менделеев районы оешкач, мин тапшыру әзерләдем, ә ул - "Батыр кул" колхозында партком сәркатибе иде. Шуннан соң безнең дуслык җепләре ныгый барды. Кеше күңеленә кагылган шигырьләрне фәкать эчкерсез һәм намуслы кеше генә яза аладыр, мөгаен.

Шигърият сөючеләрне сәгать 10 да шагыйрьнең туган авылы Бәзәкәдә көтәләр иде. Мәктәп музеенда Рәмзия Мөхетдинова М.Гыймазетдиновның тормыш һәм иҗат юлы турында мавыктыргыч итеп сөйләде. Менә аның китаплары, шигырь дәфтәрләре, язмалары. Фоторәсемнән, куе, кара чәчләрен кабартып, шат елмаеп карап тора.

- Әгәр дә кеше тырыша икән, ул барысына да ирешә. Үзенең бар сәләтен ул халкына багышлады, шуңа күрә халык та аны онытмый. Ул блокнотын әле тезенә куеп, әле руль артына утырган килеш, я иптәшенең аркасына куеп иҗат итте. Шуңа күрәдер, шигырьләре тир белән, кояш нурлары, башаклар шавы һәм иген исләре белән уралып-чорналып хасил булдылар. Алар җиңел укыла , күңелгә тирән уелып керә. Безнең җырлы –моңлы очар кошыбыз ул. Күңелебездә безнең һәрчак авыл өстендә аның рухы очар кебек,- дип тәмамлады Рәмзия Гәрәевна сүзләрен.

Дифкать Сирайның Казанда яшәүче тормыш иптәше Земфира Нәҗмиевна сүзләрендә дә тирән мәгънә ята иде:

"Шагыйрьләр исән чагында аларның фикерләре бер фикергә ия булса, гүр иясе булганнан соң алар икенче фикергә ия. Аны тоя һәм укый белергә кирәк. Бу музейны оештырган өчен хезмәт хакы түләнми. Сез аны ихтирам иткәнгә, аның хезмәтен яратканга күрә аның музеен булдыргансыз. Рәмзия ханым, бу күркәм эшләрегез белән сез авыл данын еракларга таратасыз".

Чакырылган кунаклардан Бәзәкә авылында яшәүче шагыйрә Фәния апа Шакирова әдипкә атап язган "Очар кошым" шигырен укып ишеттерде. Җирле шагыйрь Илгиз Абдуллин шигырь сөючеләргә китапларын бүләк итте. Мөхәммәтнур Гыйльфанов шагыйрь исән чактагы истәлекләрен кабат яңартты һәм аның гадел, туры сүзле, чын кеше булуына басым ясады.

Әйе, әдип китте, әмма иҗат иткән шигырьләре, басылган китаплары һәм кульязмалары халыкка торып калды. Ул күп эзләнгән, гомерен киеренке, тынгысыз хезмәт һәм иҗат өстендә үткәргән.

Тантана Бәзәкә авылы мәдәният йортында дәвам итте. Анда килеп керү белән, татар халкының тәмле - татлы, хуш исле ризык нигъмәләреннән сыгылып торган өстәл- күргәзмә сине үзенә җәлеп итә. Шунда ук татар милли киемнәр күргәзмәсе дә оештырылган. Халкыбызның күңел бизәкләре төшерелгән әйберләре күп нәрсәләр турында сөйли. Сәхнә түрендә - Бәзәкә авылының күренекле шагыйре Марсель Гыймазетдиновның чәчәкләргә күмелгән фотосүрәте. Менә ул, пәрдә ачылуга, елмаеп сәхнәгә атылып чыгар да авылдашларын сәламләр төсле тоела.

Концерт программасы бик бай, эчтәлекле һәм һәркемнең күңелен җәлеп итәрлек иде. Концертны алып баручылар – район мәдәният бүлеге җитәкчесе

Рәйхана Фәрхетдинова белән Бәзәкә мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе Айгөл Мөхетдинованың чиста, саф тавышлары сәхнәгә аеруча бер ямь өстәде. Бик күп җырлар яңгырады, дәртле биюләр халыкны чын күңелдән ял иттерде.

Газетабызның штаттан тыш хәбәрчесе Наил Тимербаев соңгы елларда шамаильләр эшләү белән мәшгуль. Ул Бәзәкә урта мәктәбенә Марсель Гыймазетдиновның "Аккош канат кагына" исемле җырына атап агачтан юнып эшләнгән аккош сурәтен бүләк итте. Анда гарәп телендә :

"Бисмилладыр һәрбер эшнең башы,
Бисмилладыр оҗмахларның ачкычы" дигән сүзләр язылган.

Концерттан соң халыкның күңеле күтәренке иде, чөнки җыр яшәтә дә, яшәртә дә бит. Кичәдә алган тәэсоратлар күңелләрдә бик озак сакланыр. Марсель Гыймазетдиновның туган көнен туган авылында зурлап үткәрү– үзе бер дәрәҗә.

М.Гыймазетдиновның иҗаты халык хәтереннән җуелмас. Аның җирдән, туган туфракта шыткан шигырьләре яшәргә көч-куәт өсти. Бу язмамны аның шигъри юллары белән тәмамлыйсым килә:

"Туган җирнең яме -
Яшәешнең тәме,
Тамыр җәйгән безнең йөрәктә".

Асия Мөхәммәтханова.
"Менделеев яңалыклары" ,
26 декабрь, 1998ел.

**Исеме хәтерләрдә саклана.**

Декабрь дә үтеп бара инде,
тик нигәдер карлар яумыйлар...

Бу юллар хакимиятнең архив бүлегендә М. Гыймазетдинов фондында сакланган шигырьдән.

Шагыйрьнең туган көнен генә көткән кебек, 11 декабрьдә, ниһаять, җир ак юрганын ябынды, беренче мәртәбә кар яуды. Бу көнне Октябрь урамының 6 нчы йорты янында Марсель Гыймазетдиновның туган көне хөрмәтенә шигъри митинг булды. Аны мәдәният бүлеге мөдире Л. Галиева һәм туган якны өйрәнү музее директоры В. Соловьевлар алып барды.

– Җирдән, туган туфрактан шыткан шигырьләр иҗат итүче шагыйрь, олы шәхес арабыздан иртә китте, - диде шәһәр Советы рәисе Р. Закиров үз чыгышында. – Халык аның сүзләрен, шигырьләрен, җырларын, васыятьләрен бервакытта да онытмас. Шигырьләренә яңа җырлар туар, аның тормышын өйрәнү һәрвакыт дәвам итәр.

Син тырыштың беткән авылларны
Яңартырга, кабат төзергә.
Тынып калган авыл урамнарын
Тальян моңы белән бизәргә.

М. Гыймазетдиновка багышланган бу юлларны Тойгуҗа авылы китапханәчесе Р. Абзалова язган.

Чыннан да, М. Гыймазетдинов табигать баласы иде. Табигать белән бер сулышта яшәде, андагы матурлыкны, сафлыкны кеше күңеленә күчерергә омтылды. Җир – Ана турында кайгыртып яшәде. Шигырьләре дә табигатькә, туган туфракка мәхәббәт белән сугарылган.

... Басуларда ап-ак юрган да юк.

Уңышларым инде туңарлар.

... Җир-Ананы төреп җылытырга

Салкын карлар кирәк, туганнар.

Митингка килгән җирле шагыйрьләр И. Абдуллин, Г. Сәгъдиева, Ф. Шакировалар, мәктәп укучылары, музей хезмәткәре А. Мөхәммәтханова, үзәк китапханә хезмәткәрләре Ф. Идаева, Г. Фәтхиева, К. Сөйләймановалар шигырьләр укыдылар.

Шулай ук, килгән кунаклар, авырлыкларны бергә җиңгән, шатлыкларны бергә уртаклашкан тормыш иптәше Миңнур ханым, апасы Римма үзләренең чыгышларында мәрхүмне сагынып искә алдылар.

– Бүген, чынлап та, матур вакыйга, - дип тәмамлый митингны район һәм шәһәр хакимияте башлыгы В. Вахитов. – Шигъриятькә булган мәхәббәт мәңге сүрелмәсен. Сәнгатькә бирелгән кешеләрне, мәдәниятебезне, телебезне онытсак – безнең киләчәгебез булмаячак. Киләчәге булган халык кына үлемсез.

Әйе, М. Гыймазетдинов бик талантлы шәхес иде. Аның исеме күңелләрдә мәңге җуелмас.

Рәхилә Мирзаянова.
“Менделеев яңалыклары” газетасы,
2000 ел, декабрь.

**Көрәшче шагыйрь.**

Мин радио тыңлыйм. Бүлмә эченә талгын гына моң җәелә:

*...Туган як кырларын сагынып,*

*Әйләнеп авылга кайт әле...*

Җыр агылы да агыла. Моңы күңелгә якын, сүзләре җанга ятышлы, сагышлы-якты көе йөрәкне назлый, иркәли.

Кем соң шулай туган якларыннан кайчандыр чыгып киткәннәрне кире авылга кайтырга чакыра? Үзенең җырга әверелгән шигъри юллары аша авылны терелтергә, яңартырга, аның язмышына йөз белән борылырга дәшә, чакыра, өнди, үтенә?..

Хәер, бу сорауны мин болай гына бирдем бугай. Чөнки бу җырны белмәгән авыл кешесе юктыр ул Татарстанда.

Әйе, җыр сүзләренең авторы – безнең, бер яктан, сөенечебез һәм горурлыгыбыз, икенче яктан, арабыздан мәңгелеккә китмәгәндә-уйламаганда бик иртә китеп баруы белән зур көенечебез – авылдашыбыз шагыйрь Марсель Гыймазетдинов. Ул шулай, “кече” авыллар исемлегенә кертелеп, бүгенге көндә эшче кулларга, белгечләргә, яшьләргә зар-интизар булып җан асраучы төбәкләр исеменнән 1992 елда Казан телевидениесеннән якташлар-

милләттәшләргә, туган авылларын күңелләреннән әлегә сызып ташларга өлгермәгән, җир хезмәтеннән курыкмаганнар адресына ихлас күңелдән мөрәҗәгать иткән иде. Авылча әйтсәк, “җан атып” сөйләгән иде. Үзе дә авыл баласы, җир кешесе, колхоз рәисе, шулар өстенә, шигъри җанлы кеше дә булгангадыр, мөгаен, туган як, туган авыл язмышына һич кенә дә битараф түгел иде ул. Бу – бүгенге тормыш, киләчәк яшәеш өчен көрәшнең бер ысулы, юлы иде, һәм ул шушы юлдан соңгы минутына кадәр туры һәм нык барды.

Марсель Гыймазетдиновның тормыш юлын һәм иҗатын мин бер кечерәк кенә матур китапчык итеп күз алдына китерәм. Шагыйрьнең шигырьләрен укыганда, мин ул китапчыкны да күңелемнән актарам.

Китапчыкның беренче битләре – гади генә биография: 1943 елда туган. Бишекле төбәге – Бондюг районының Бәзәкә авылы. Иртә әтисез кала. Урта мәктәп, институт, укытучы эшчәнлеге, соңрак – төрле җитәкче постлар.

Китапчыкның иң зур өлеше – шигъри тәлгәшләр: җир җылысы, туган як тирәкләре, башаклар, челтер чишмәләр, канат кагынучы аккошлар... Шигырьләр, шигырьләр... Шагыйрьнең бөртекләп җыйган энҗе-мәрҗән дисбесе... Һәр бөртеге шагыйрь өчен кадерле, газиз, изге... Бер генә төймәсе җитмәсә дә, дисбесе тулы булмас иде.

Марсель Гыймазетдинов күпкырлы талант иясе иде. Ул, колхоз рәисе, иртән кояш чыкканда игеннәр арасында, киләчәк икмәк өчен борчыла, яна-көя, ә кичен, арып-талып кайтып егылгач, ул үзендә илаһи бер көч таба: кулына каләм ала һәм икенче газап – ләззәтле газап – иҗатка керешә.

Марсель абый шигърият дөньясына аяк басучы һәр яшь талант өчен сөенә иде.

Каләм тибрәтүче авылдашыбыз Фәния Шакированың, райондашыбыз Илгиз Абдуллинның, Николай Климов һ.б. иҗатларын даими күзәтеп барды һәм аларга үгет-нәсыйхәтләрен бирде. Районда “Ядкарь” әдәби-музыкаль иҗат берләшмәсен җитәкләде (аяныч, җитәкчесез калгач, бу берләшмә таралды), күп-күп кызыклы кичәләр, очрашулар оештырды, һәр кич, репетицияләргә йөреп, спектакльләрдә катнашты. Һәрчак ачык күңелле, җор сүзле иде.

Ләкин аның тормышында һәм хезмәтендә дә бар да ал да гөл булмый. Ул күптөрле каршылык-киртәләргә, тормышыбыздагы ямьсез һәм күңелсез, тискәре күренешләргә каршы ашкынып һәм туктаусыз көрәште. Мәсәлән, туган телебезне саклау һәм торгызу буенча күп эшләде. Мәктәпләрдә татарча укытуны бөтен мөһимлеге һәм катгыйлыгы белән алга куйды. Район үзәгендә үткәрелә торган чараларның, Сабантуйның татарча алып барылуына иреште. Районда татар иҗтимагый үзәге оештыру, алты авылда мәчет салу өчен рөхсәт алу, Менделеев каласында төзеләчәк дүрт манаралы мәчетнең проектын булдыру, урамнар, зиратлар чистарту буенча өмәләр оештыру һәм аларда үзе дә катнашу – болар барысы да бер кешенең тырышлыгы нәтиҗәсе, көрәше. Боларның барысы да килеп чыксын өчен ул эзләнде, чапты, телефон шалтыратты, киңәште, сөйләште, кемнәр беләндер ачуланышты...

Марсель Гыймазетдиновның шундый тынгысыз булуы, уңыш-табышлары, халык арасында хөрмәтле һәм популяр булуы, иҗат күгендә

якты йолдыз булып кабынуы күпләргә ошамый, билгеле. Аңа аяк чалырга, аның дәрәҗәсен төшерергә, исемен каралтырга тырышалар, хәтта аңа матди зыян салудан да тайчынмыйлар.

Бервакыт, Марсель абый колхоз рәисе булган чакта, аның өстеннән шикаять хаты язалар. Комиссияләр килә, тикшерүләр китә. Менә шул чакны рәис кулына каләм ала һәм газетага мәкалә яза. "Анонимчыга ачык хат" дип атала ул.

"Куркак җан, сиңа ачык хат язарга булдым. Бәлки, бу хатым синең намусыңны, вөҗданыңны уятыр. Синең шикаятьләр минем, белгечләрнең омтылышына аяк чала, ахыр килеп, колхозның үсешен тоткарлый. Әгәр синең, чыннан да, колхоз үсешенә файда китерәсең килә икән, син күргән, белгән эшләр дөрес икән, нигә дип чын исемеңне атамыйсың? Яисә безнең янга килеп турыдан-туры әйтмисең? Уйлан әле, вөҗданың газапламас микән?" – дип, дәшә ул кара йөрәкле кешеләргә.

Ә икенче түбән җанлы һәм куркак теш кайраучылар бөтенләй этлек эшлиләр: шагыйрьнең дача өен ут төртеп яндыралар. Менә шундый көнче һәм кара эчле бәндәләр тынгысыз, эзләнүчән, туры сүзле, эшлекле кешегә аяк чалырга, аны өркетергә, ниһаять, бөтенләй туктатырга тырышалар. Ләкин бу артык мәшәкать кенә була. Марсель Гыймазетдинов эшлисен – эшли, әйтәсен – әйтә. Тел, сүз белән әйтеп бетермәгәнен шигырьләре аша җиткерә.

Әйе, Марсель абый шулай, күп киртәләрне җимереп, колхоз йөген тарта-тарта, иҗади хезмәткә дә вакыт таба алды, татар халкын битарафлык, манкортлык сазлыгыннан тартып чыгару өчен ашкынды, көрәште, тырышты. Аның тынгы белмәс йөрәге бу хәлләргә борчылды, сызланды, үрсәләнде... Һәм, ниһаять, йөрәк түзмәде – язның бер матур көнендә кинәт туктады да калды. Бу йөрәк әле озак тибәргә, бу зирәк акыл тагы да күбрәк матур һәм якты сәйләннәрдән шигъри муенса тезәргә, тынгысыз һәм эзләнүчән бу кеше җирдә берсеннән-берсе матур, гүзәл эшләр башкарырга тиеш иде. Ләкин язмыш барысын да үзенчә хәл итте. Бүген безнең арабызда Марсель абый юк. Тик аның җирдән, туган туфрактан шыткан шигырьләре – безнең телләрдә, аның китаплары – өстәлләрдә, җанга якын җырлары, сәхнә, радио һәм зәңгәр экраннардан көнаралаш яңгырап, күңелләребезне сафландыра, назлый, иркәли. Ә "Әйләнеп кайт әле авылга" җыры татар иленең авыл кешеләре өчен чын гимнга әверелде дип исәплим мин.

*...Кайгырма, моңайма, юксынма,*
*Әйләнеп кайт кына авылга...*

Ул язлар турында да күп язды, яратып язды: "Язлардан ала алмыйм күземне", "Язларны көтә күңел", "Язлар белән китәрмен" шигырьләре әнә шул исемлекне тулыландыралар. Нилектән бу шулай? Язларны шашып яратуданмы? Әллә соң яшел язда тугангамы дисәм, ул – кыш баласы. Ә бәлки, язлар җиргә җылылык, яктылык алып килгәнгә, ташкын булып җир өстеннән барлык пычрак һәм каралыкны агызып алып киткәнгәдер? Җирнең генә түгел, йөрәкләрдәге туңны эретерлек чистарту көченә ия булган табигатьнең бер фасылы булгангадыр?.. Тормышта Марсель абыебыз үзе дә көчле язгы ташкын кебек иде: һәрчак искелекне яңартырга, пычракны

чистартырга, үткәнне, онытылганны кайтарырга беренче булып башлап йөрүче иде.

Язлар белән туган якларга аккошлар кайта. Аккошлар – мәхәббәттә иң тугры кошлар, парларын гомерлеккә берне генә сайлыйлар. Шагыйребез дә туган җиренә мәңге тугры булып яшәгән кеше иде...

*...Туган җирем, синдә гомер буе*
*Яшәдем мин тугры ул булып... –*
дип язды ул үзенең бер шигырендә.

Аклык, пакьлек, тугрылык кебек иң югары сыйфатларга ия булган аккошларны шагыйрь үз иҗатына тиктомалдан гына кертмәгән, күрәсең. Ул үзенең шигырьләрендә, хисләрендә чиста, якты һәм ак була алды.

Безнең авыл аркылы кечерәк кенә инеш ага. Ул үз суын авылдан читтә булган бер чишмәдән ала. Халык аны "Гыйльфан чишмәсе" дип йөртә. Кем ул Гыйльфан? Ник халык чишмәгә аның исемен биргән? Ул – Марсель абыйның әтисе, колхозлашу елларында авыл советы рәисе булган, үзе тапкан чишмәне чистартып, тәртипкә китерүче. Димәк, безнең авылны тереклек көче белән тәэмин итүче чишмә-сулы итүдә тырышлык куйган кеше.

Ә Марсель Гыйльфан улы Гыймазетдинов – авылыбызның икенче чишмәсе, рухи чишмәсе,шигърият чишмәсе башында торучы булды. Беренче чишмә җанга-тәнгә көч, сихәт бирсә, икенче чишмә күңелләрне ләззәт, горурлык һәм җылы хиссият белән сугара.

Беренче чишмә-инеш бүген дә ага, яши. Икенче чишмә... юк, юк, мин аны һич кенә дә бетте, туктады, югалды дип әйтә алмыйм, телем бармый. Авылдашлары, каләмдәшләре һәм яшь буынның эш-гамәлләрендә һәм күңел хисләрендә ул һәрчак агар, яшәр, челтерәр...

Р. Мөхетдинова, педагогика ветераны,
декабрь, 2003 ел.

P.S. Татарстан Мәгариф министрлыгы игълан иткән бәйгедә. Бәзәкә мәктәбе "Мирас" түгәрәге әгъзасе Закирова Лариса, шушы исемдәге иҗади эше белән 1 нче урын алды һәм министрлыкның мактау грамотасына лаек булды.

## Нәтиҗәсен үзегез чыгарыгыз...

Тиздән Россия Дәүләт Думасына сайлаулар узачак. Элеккеге елларда депутатлыкка кандидат, сайлаучылар белән очрашып, майтарасы эшләр хакында сөйләсә, хәзер фиркаләр генә көч сынаша. Алар съездларда булачак депутатлар исемлеген раслый. Аннан инде матбугатта, аеруча телевидениядә "театр" башлана. Ак чәчле абыйлар, ыспай гына киенгән җәмәгать эшлеклеләре бер-берсен яманлый, бер-берсенә сүз әйтергә дә ирек бирми. Чын мәгънәсендә, кызык һәм кызганыч тамаша. Доренко, Соловьев үткәргән ток-шоуларны карау өчен сәламәтлек кенә түгел, махсус әзерлек тә кирәк булачак. Җәмгыяте нинди – хөкүмәте, депутатлары шундый дигәндәй, бездә

– демократия, кемне телисең, шуны сайлыйсың. Ә санаганда хилафлык булмас шикелле, чөнки кулларга дәфтәр тотып, һәр сайлаучыны исәпкә алып торучы фирка вәкилләре бик күп бит!

Элегрәк сайлаулар ничек уза иде соң? Партия кемне сайларга куша, халык шуны үти. Дөрес, үзгәртеп кору башлангач, хәлләр үзгәрде. Депутат булып кемне генә сайламадылар. Сайланганнары җәмгыятьне, партияне сүгә-сүгә илне җимерде, күпчелек Мәскәүдә баеп калды. Шушы елларда СССР Югары Советына Чаллыдан сайланган керәшен егете Николай Сазонов та, күңеле чиста булса да, әллә нинди төркемнәргә кушылып, уенчыкка әйләнде. Яшь кенә килеш гүр иясе дә булды. Авыр туфрагы җиңел булсын мәрхүмнең.

Сайлауларга янә әйләнеп кайтыйк. Мин 1990 елда 128нче сайлау округыннан РСФСР Югары Советына депутатлыкка кандидатның ышанычлысы булдым. Кандидатлар арасында шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе Марсель Гыймазетдинов та бар иде. Сайлаулар тәмамланыр алдыннан ул миңа "Социалистик Татарстан" гәҗитенә әзерләгән моң-зарлы хатын укырга бирде. Укыдым да:

– Марсель Гыйльфанович, бердән, бу хатны басмаячаклар, икенчедән, депутат булмасаң да, халык шигырьләреңне, җырларыңны ярата, үзең менә дигән җитәкче, – дип күңелен юаттым.

Ул шомырт кара күзләре белән миңа карады да:

– Син намуслы кеше, сине хөрмәт итәм, – дип, , шигырьләр китабын бүләк итте һәм минем кандидатны яклап язылган сайлаучыларга мөрәҗәгатькә кул куйды. Ә Чаллы һәм тагын җиде район халкы матур сөйләшә торган КАМГЭс шоферы Виктор Скрынник өчен тавыш бирде.

Аннан соң ике ел вакыт үтте. 1992 елның декабрендә Марсель Гыймазетдинов гүр иясе булды. Аны бөтен халык елый-елый туган авылы Бәзәкәдә җирләде. Кызганыч, талантлы шагыйрь, намуслы милләттәшебез безнең арадан бик иртә китте. Менә, 20 елдан соң, ул язган хатны сезгә тәкъим итәргә булдым. Минем өстә авыр йөк калмасын, нәтиҗәсен үзегез чыгарыгыз.

Рахман Шәфигуллин.

**Мин сайлауларны ничек оттырдым...**

Мине сайлаучылар бер үк көнне 860нчы номерлы Алабуга территориаль һәм Яр Чаллы милли-территориаль сайлау округларыннан РСФСР Югары Советына депутатлыкка кандидат итеп тәкъдим иттеләр. Беренчесенә – "Белем" җәмгыяте пленумында, ә икенчесенә – "Батыр кул" һәм "40 лет Октября" колхозчылар гомуми җыелышында. Мин хәзерге вакытта Менделеев районы Тукай исемендәге колхозның рәисе булып эшлим. Колхозыбыз соңгы елларда зур үзгәрешләр кичерә. Матур үзгәрешләр дип

әйтер идем. Үткән өч ел эчендә генә дә терлекчеләребез һәр сыердан сөт савып алуны 3991 кг га җиткерделәр, ит җитештерү 30 процентка артты. Моннан өч ел элек ел нәтиҗәләре буенча ике Мактау кәгазе алган булсак, 1989 елда колхозыбыз районда икенче урынга чыкты һәм 16 Мактау кәгазе, дипломнар алдык. Быел ит сатуның квартал планын февральдә үк үтәдек. Бүген һәр сыердан 9,8 кг сөт савабыз. Бу күрсәткеч моннан өч ел элек 5 кг иде. Менә шуңа күрә дә Менделеев районы сайлаучылары минем хезмәтемне күргәннәр дә мине Россия Федерациясе Югары Советында депутат итеп күрәселәре килгәндер инде. Һөнәрем буенча мин укытучы. Егерме ел педагогик стажым бар. Озак еллар мәктәп директоры булып эшләдем. Педагогик эшчәнлегем хәзерге эшемә зур ярдәм итә. Минемчә, колхоз-совхозларны нәкъ менә укытучылар җитәкләргә, белгечләргә таянып эш итәргә тиешләр кебек.

Милләтебезнең телен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятен саклап калу, аны үстерү, федерация халыклары белән интернациональ дуслыкны киңәйтү өстендә минем кебек укытучылар эшләмичә, кем эшләргә тиеш соң? Шундый уйлар белән мин 128нче округ буенча үземнең ризалагымны бирдем.

Сайлау алды чорында җиде районның, ике зур шәһәрнең сайлаучылары белән очрашулар башланды. Алдан ук әйтеп куям: без, депутатлыкка тугыз кандидат, Яр Чаллының 128нче округы комиссиясеннән узмадык. Иң оешмаган, кандидатлар язмышы өчен инә очы кадәр дә кайгыртмаган округ комиссиясе булды ул. Кандидатлар һәм комиссия әгъзалары арасында эчкерсез түгел, ясалма дуслык кына урнашты. Бу минем фикерем. Безнең платформалар район газеталарында бик соң гына, анда да кайберләрендә генә басылды. Рәсемнәребез барлык газеталарда да урнаштырылмады. Листовка-плакатлар сайлауларга 3-4 көн калгач кына, Казанда басылып чыкты, әмма районнарда таратылмады. Шулай итеп, сайлаучылар безнең сурәтләрне күрүдән мәхрүм булдылар, уй-фикерләребез язылган листовкаларны укый алмадылар. Безнең белән дә очраша алмадылар, чөнки округта өч йөзгә якын авыл бар, бөтенесен йөреп чыгарга физик мөмкинлегебез булмады. Бер ай буена җиде районның төрле төбәкләрендә без, үзебез булдыра алганча, очрашулар оештырып йөрдек йөрүен. Бер тиен акча бирелмәде, барлык эшләгән эшләребез безнең хисапка булды. Ә бит сайлаулар оештыру өчен округ комиссиясенә зур гына сумма бүленеп бирелә...

Районнарда 12 очрашу булды. Аларның күбесе оешмаган төстә үтте. Сайлаучылар клубларга бик аз килде. Алабуга шәһәрендә – 57, районда – 92, Менделеевта – 53, Чаллының Автозавод районында – 68, Комсомол районында 38 сайлаучы катнашты. Кайбер очрашуларда (Алабуга шәһәре) сусауны басар өчен эчәргә су да таба алмадык.

Ә менә Тукай районында безнең барыбызны да колхоз, авыл советы, коллектив җитәкчеләре белән очраштырдылар. Аларга рәхмәтебез зур. Очрашуларны, шулай ук Әгерже, Минзәлә, Мамадыш районы җитәкчеләре дә яхшы оештырды. Биредә совет власте барлыгын, КПСС район комитетының халык арасында актив эшләвен тойдык.

Очрашу вакытында һәм сайлаулар алдыннан тагын бер кат шәһәр-авылларны әйләнеп чыкканда, сайлаучылар белән сөйләшкәндә, тискәре, бүгенге үзгәртеп кору чоры таләпләренә һич тә җавап бирми торган сайлау алды ысуллары кулланылганын күрдек. Мәсәлән, Минзәлә районында колхоз-совхоз, предприятие- учреждение җитәкчеләренә һәм партия оешмасы секретарьларына депутат итеп И. Хәйруллинны сайлау турында райком тарафыннан ныклы күрсәтмә бирелгәнлеге ачыкланды. Моның шулай икәнлеге Минзәлә техниклар йортында узган очрашуда ук сизелгән иде инде. Чөнки анда чыгып сөйләүчеләр (юк, кәгазьдән укучылар) алдан ук әзерләнеп, билгеләнеп куелган иде. Шәһәр китапханәсе мөдире булып эшләүче бер ханым, ашыга-тотлыга үзенең нотыгын кәгазьдән укыды да, Хәйруллин өчен тавыш бирергә чакырып, трибунадан төште. Бу минутларда безнең сигезебезнең нинди хәлдә калуын күз алдыгызга китерегез әле. Китапханәченең сүзләрен юллар төзү участогы начальнигы да кабатлады.

Ә инде 3 март көнне без, Хуҗамәт авылына килеп, участок сайлау комиссиясе белән очрашып, депутат итеп кемне күрергә теләүләре белән кызыксынгач, арада түбәндәге әңгәмә булды:

– 128нче округтан кемне сайларга уйлыйсыз?

– Үзебезнең кешене.

– Кем соң ул үз кеше? Бәлки, җир кешесен, илне туйдыручы – Тукай колхозы председателен сайлыйсыздыр. Сез үзегез авыл кешесе булгач, үз кеше – колхозда эшләүчедер инде?

– Юк! Без Казаннан обком кешесен сайлыйбыз.

– ...

– Ул безне телевизорга төшерәчәк. Районны төшерде инде, күргәнсездер.

– Аның вазифасы бит инде ул – телевизордан республика колхоз-совхозларын күрсәтү.

– Булса соң. Безгә шундый установка булды.

– Кемнән?

– Районнан.

– Рәхмәт инде, сеңлем, барысы өчен дә. Менә сезгә җир кешесенең быел чыккан “Яшәү мәгънәсе” дигән шигырьләр җыентыгы.

Шундый ук сүзләрне Куйбышев исемендәге колхоз парткомы секретаре, авыл советы секретаре, кибеттәге сатучы мөлаем, кунакчыл ханым, балалар мөдире, мәктәп директорының тормыш иптәше мөгаллимә ханым да кабатлады. Китабымны бүләк иткәч, бераз әңгәмә корып алгач, мин аларның

күзләрендә ниндидер үзләрен гафу итмәслек тойгылар барлыкка килгәнен тойдым. Минем алда, башка кандидатлар алдында, киләчәк буынны тәрбияләүчеләр буларак, үзләрен гаепле санаганнарын йөрәгемнең күренми торган җепләре белән тоеп, күреп алдым. Ахырда укытучы ханым, миннән листовкалар алды да, дулкынланып: “Соңгарак калдыгыз шул! Хәер, бүген 13 сәгатьттә ата-аналарны җыялар”, –дип катгый бер карарга килде. Аның күзләрендә үк мәнфәгатьләре өчен теләсә нинди закон бозуларга баручы бюрократ-партократларга карата нәфрәт чаткылары күренде.

Алдан әйтеп куям, Хәйруллин Минзәлә районыннан 10 мең сайлаучының тавышын алды. Бик зур кисәк! Әмма бу гадел юл белән ирешелгән уңыш түгел! Чөнки ай ярым элек татар телевидениясе минзәләлеләр турында бик матур гына тапшырулар циклы күрсәтте. Һич шик юк, бу тапшыруларны оештыруда төп рольне Хәйруллин уйнаган. Мамадыш районы җитәкчеләренә дә турыдан-туры шундый ук күрсәтмәләр бирелде. Чөнки ай ярым чамасы элек мамадышлылар, район җитәкчеләре турында да күләмле генә тапшыру дөнья күргән иде. Телевизордан хезмәт бәйрәменнән репортаж да күрсәтелде. Һәм иптәш Хәйруллин тагын 10 мең сайлаучының тавышына ия булып куйды.

Без бит югарыда атап кителгән район авылларында булдык, бик җылы очрашулар үткәрдек. Бер әйбер башыма сыймый: ничек итеп авыл халкы, колхозчылар телевидение, Казан кешесенә күбрәк тавыш биреп, турыдан-туры авыл хуҗалыгы белән бәйле кешегә ышаныч күрсәтмиләр икән? Шул кешенең шигырьләрен укыйлар, җырларын җырлыйлар. Ә менә авыл халкының уй-хәсрәтләре белән яшәүче, алар белән газап-михнәтләр кичүче кешегә тавышларын бирмиләр...

Түбән Камада обком кешесе концертлар куеп йөрде. Үзе белән баш редакторлар, помредакторлар, журналистлар алып килде. Концертларда ачык пропаганда булды.

Бу хәлне ничек аңларга? Калган кандидатларның берсенә дә листовкалар чыгарырга, аерым гына радио-телевидениедан чыгышлар ясарга рөхсәт ителмәде. Сайлауларга өч көн кала иптәш Хәйруллин берүзе телеэкраннан 15 минут сайлау алды платформасы турында сөйләде, икенче көнне балаларның телемарафонында күрсәтелә, өченче көнне Татарстан Язучылар идарәсе рәисе әлеге кандидат турында чыгыш ясый. Ә мин, шагыйрь-кандидат турында ләм-мим бер сүз әйтүче юк.

Алабуга һәм Минзәлә газеталарында да без сигез кандидат турында бер генә мәкалә дә бастырып чыгарып булмады. Рөхсәт итмәделәр. “Үзебезнең шеф турында язмыйча, сезнең турында ничек языйк инде, абсурд”, – диделәр редактор иптәшләр.

Кыскасы, мин бу сайлауларда тагын да ныграк төшендем: дөреслек белән генә сайлауларда җиңел чыгып булмый. Элеккечә, үзләренең таплы куллары белән, райком җитәкчеләре безнең киләчәгебез белән дирижерлык итәләр. Аларга әҗәл алып килүче демократик үзгәрешләргә каршы нык көрәш алып баралар. Илдә башланган үзгәртеп коруларның алга китешенә теш-тырнаклары белән комачаулыйлар, таяк тыгалар.

Әмма бу вакытлы күренеш кенә инде. Дөнья тәгәрмәче әйләнә. Ул бик зур тәгәрмәчтер. Демократия белән "тәтиле" уйнаучы райком һәм райбашкарма җитәкчеләрен ул, эзләп табып, хәшәрәт тараканнарны сыткандай, сытып китәчәк. Моңар минем иманым камил. Шуны раслау максатыннан, минем өчен иң кадерле булган партия билетын тапшыра алам. Кесәмдә партбилетым булмаса да, шундый кешеләргә каршы көрәшемне дәвам итәчәкмен.

Әгерҗе, Менделеев, Алабуга, Мамадыш, Түбән Кама, Минзәлә, Тукай районы, Яр Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләрендә яшәүче мине яклап тавыш биргән барлык сайлаучыларга чын күңелдән рәхмәтемне белдерәм. Рәхмәт сезгә, кардәшләр, фикердәшләр. Шуны әйтәсем килә – сайлаулар гадел булмады, халык үзе теләгән кешене депутат итеп куя алмады.

Марсель Гыймазетдинов,<br>Тукай исемендәге колхоз рәисе.<br>1990 ел, март.

Р. С. Югарыда атап әйтелгән обком кешесе Хәйруллин барыбер үтә алмады. Партиянең абруе булмаганлыктанмы, халык ни өчендер, Чаллы урамнары буенча громкоговоритель аша кычкырып йөргән КАМГЭСның ПУАТ шоферы Виктор Скрынникны хуш күрде. Югары Советның да гомере озын булмады. Борис Ельцин Указы белән, ул 1993 елның 4 октябрендә туплардан атып куып таратылды.

"Шәһри Чаллы" газетасы,<br>12 октябрь, 2011 ел.

## Марсель Гыймазетдиновка 70 яшь.

Марсель Гыймазетдиновның якты истәлегенә багышлап, туган авылы Бәзәкәдә чара үткәрелде. Исән булса шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, партия оешмасы җитәкчесе, колхоз рәисе һәм башка вазыйфаларны зур җаваплылык белән башкарган шәхескә 70 яшь тулар иде.

Педагоглар, укучылар, музей хезмәткәрләре, район оешмалары вәкилләре, авылдашлары катнашындагы чараны педагог-оештыручы, музыка җитәкчесе Ясминур Гыйззәтуллина әзерләде һәм алып барды. Очрашуның беренче бүлеге балалар бакчасында узды. Театральләштерелгән тамаша Марсель Гыймазетдиновның гомер юлын тасвирлады. Балалар башкарган

шигырьләр, җыр-биюләр дә билгеләнгән темага багышланды. Чара Бәзәкә мәктәбендә дәвам итте.

Шагыйрьнең иҗат һәм тормыш юлын җентекләп өйрәнгән, аның турында материалларны бөртекләп җыйган ветеран – педагог Рәмзия Мөхетдинова М.Гыймазетдиновның зыялы, оста оештыручы, таләпчән җитәкче, шул ук вакытта бик хисчән, шигърияткә гашыйк кеше булуын ассызыклады. Милли Мәҗлес рәисе, татар халык театры артисты, төрле чараларны оста оештыручы, "Ядкарь" әдәби – музыкаль берләшмәсе җитәкчесе, Егор Уткин исемендәге премиянең беренче лауреаты – болар якташыбызның күпкырлы талант иясе булуын дәлилли. Шигырьләре, эш – гамәлләре белән халык ихтирамын яулаган әдип фани дөньядан бик иртә китсә дә, авыл күгендә сүнмәс йолдыз булып балкый.

Рәмзия Гәрәевна җитәкчелегендә мәктәп укучылары, туган якны өйрәнүче "Мирас" түгәрәге әгъзалары материал – документлар туплап, пионер бүлмәсендә М. Гыймазетдиновка багышланган почмак булдырганнар, соңрак ул мәктәп музее статусы алып, ун ел уңышлы эшләгән, экспонатлар белән баетылган. Музейда бай эчтәлекле кичәләр, очрашулар, тәрбия сәгатьләре үткәрелгән. Язучылар Туфан Миңнуллин һәм Нәбирә Гыйматдинова белән очрашулары укучылар хәтерендә тирән уелып калган.

Алабугадан килгән кунак – җырчы һәм композитор Владимир Мироваев шагыйрь белән еш очрашулары , уртак иҗат итүләре турында сөйләде. Аның тормыш иптәше Гөлчәчәк белән М. Гыймазетдинов сүзләренә көй салынган "Туган авылым Бәзәкәм", "Кире борма, туган авылым", "Җырланмыйча калды безнең җыр" һ.б.ларны башкарганда залдагыларның күбесенең күзләрендә яшь иде.

Үзешчән композитор, җырлар һәм шигырьләр язучы Роберт Нәбиуллин М. Гыймазетдиновның Тойгуҗага татар теле укытучысы булып килгән көненнән хәтерли. Якташына багышлап язылган "Әйтелмәгән сүзләр" шигырен ул чарада катнашучыларга укып ишеттерде, мәктәпкә үзенең җырлар җыентыгын истәлеккә бүләк итте.

- Табигать баласы, җир баласы иде ул. Татар – удмурт тимер юл магистралендә эшләгәндә, Әгерҗе белән Чаллы арасындагы Алнаш станциясендә Марсель утырткан агачлар әле дә үсә. Туган ягын , авылын, якташларын, барысыннан да бигрәк әнисен яратты. Кешелекле, олы җанлы шәхес иде,- дип искә алды шагыйрь дустын Р. Нәбиуллин.

Авылдашы, сыйныфташы, күршесе Габделхәй Җиһаншин Марсель белән балачакларының авыр чорга туры килүе, бер табактан ашаган вакытлары булуы, күршесенең мәктәптә укыганда ук шигырьләр язуы, 6-7 нче сыйныфларда инде калын китаплар, романнар укуы турында сөйләде. Яшь буынга мөрәҗәгать итеп, компьютер, Интернет белән артык мавыкмаска, күбрәк китап укырга өндәде.

Очрашу "Аккош канат кагына" җырын бергәләп башкару белән тәмамланды.

Мәдинә Григорьева,
"Ватаным Татарстан",
21 декабрь, 2013 ел.

**Марсель Гыймазетдинов иҗатында милли, рухи - әхлакый кыйммәтләр һәм милли характерлар чагылышы**

Менделеев шәһәренең 4 нче гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Кашапова Гөлфирә Хәмәт кызы укучылары белән татар теле буенча үткәрелгән күп төрле иҗат бәйгеләрендә еш катнаша. Менә шул иҗади эшләрнең берсеннән бер-ике өзек: “...Кемдер үз гомерен тыныч кына, ә кемдер метеоритка тиң булып, кыска гомерен дә башкалар өчен янып үткәрә. Марсель Гыймазетдинов та шундыйлардан. Кешеләргә булган хөрмәтен, туган җиргә булган мәхәббәтен шигырьләрендә тирән итеп чагылдыра ул. Үзе дә авыл баласы, җир кешесе, колхоз рәисе, шулар өстенә, шигъри җанлы кеше дә булганга, туган як, туган авыл, кешеләр язмышына һич кенә дә битараф булмый.”

“...Әгәр ул исән булып, аның белән очрашырга туры килсә, мин аңа мондый сүзләр җиткерер идем: “Марсель абый! Сезнең тормыш юлыгыз, шигырьләрегез сокланырга, уйланырга мәҗбүр итәләр. Тәрбияле, фикерләүгә сәләтле, үз хокукларын, телен, милләтен яклый белгән чын Кеше булырга өндиләр. Рәхмәт Сезгә!” Мин кемнәрдән генә Марсель Гыймазетдинов турында сорасам да, кайдан гына аның турында укысам да, аның чын ир, хезмәт кешесе, кешелекле, намуслы булуын ишетәм, укыйм, күрәм. Бүгенге көндә мондый кешеләргә сокланмыйча, алар белән горурланмыйча мөмкин түгел! Аның күркәм эшләре, сокландыргыч шигырьләре безнең күңелләрдә сакланыр, безнең өчен һәрчак үрнәк булыр! “

**Марсель абый турында истәлекләр.**

Быел Марсель абыйның юбилее. Ул безнең арадан бик иртә китеп барды. Аның күпме эшләр эшлисе, күпме шигырьләр язасы калгандыр. 75 яшькә кадәр генә торган булса да, ниләр генә эшләп бетермәс иде ул!?

Мин аны мәктәптә укыган вакытыннан беләм. Ул чагында минем әни татар теле укыта иде. Шуңа күрәдер инде, Марсель абый безгә килгәләп йөрде. Исемдә, аның кулында юка битле альбом була иде. Ул шунда язган шигырьләрен әнигә укый. Аннары бергәләп шигырь язу серләре, нинди темага язу турында сөйләшәләр. Кайбер чагында төзәтергә дип әнигә калдырып та китә. Мин яшертен генә шул альбомны алып укый идем. Әни уңышлы шигырьләрен район газетасына җибәрергә киңәш итә иде. Ул Марсель абыйның беренче адымнары булган, күрәсең. Ул еллардан соң безнең очрашулар сирәк булды.

70 нче еллар ахыры, 80нче еллар башында мин Алабугада мәктәп инспекторы булып эшләдем. Шул чагында Марсель абый Тихоново мәктәбендә директор иде. Бер үк вакытта Тихоноводa төзелә торган тимер юл

станциясендә дә эшләде. Бер урында гына тора да, эшли дә алмый. Аның энергиясе ташып тора иде. Үзе белән бергә эшли торган Наил исемле прораб белән, елмаеп, РОНОга килеп керәләр. Башлана шау-гөр... Ачылмаган ишек, ул кермәгән бүлмә, сөйләшмәгән кешесе калмый .Кемгәдер кызык вакыйга, кемгәдер анекдот сөйли, шул арада отчетын да бирә, яңалыклар белән дә таныштыра, заданиеләр дә ала. Ул да булмый, “авылдаш” дип, миңа да өлеш чыгара. Минем шундый авылдашым булу белән бик горурлана идем. Аны шул ачык күңелле, җор булганга күрә яратып “еврейский татарин”, я булмаса “цыганский татарин” дип үзенә үк әйтәләр иде. Ул аңа бер дә үпкәләми, җавап итеп: “Меня, наверное, цыганский табор потерял” яки “Отец, наверное, еврей был,”- дип көлә генә. Җорлыгы, шат күңелле, гади булуы белән, нindидер магниты бар диярсең, бөтен кешене үзенә тартып тора иде. Ул килсә, караңгы көннәр яктырып, авыр вакыйгалар җиңеләеп кала. Буран булып килеп керә, давыл булып чыгып китә...Аңа карап, бөтен кайгы-хәсрәтләреӊ югала, куркуларың бетә иде.

Мин РОНОда эшләгәндә, хәзерге Менделеевск районы Алабуга районына керә иде. Инспектор буларак, мин шул як өчен җаваплы идем.Тикшерү белән шул яктагы бөтен авыл мәктәпләрен йөреп чыгарга туры килде. Көннәрдән бер көнне, мине план буенча, Тихоново мәктәбен тикшерергә җибәрделәр. Миңа ничектер читен, уңайсыз булып тоелды. Беренчедән, мин Марсель абыйдан кече, шулай булгач, тәҗрибәм дә азрак, икенчедән, үзебезнең авыл кешесе. Авылдаш буларак, якын итеп, РОНОдагы кебек үзен тотса, шаярта башласа, мин ни эшләрмен, дип уйлыйм. Ни эшләп тә булмый, кушалар – барасың, эшең шул.

Мәктәпкә килдем, Марсель абый каршы алды, коллективны җыеп, таныштырды. Кирәкле бөтен документларны җыеп, алып килергә кушты. Бернинди көлү-шаяру юк, бөтен нәрсә бик эшлекле рәвештә бара. “Әгәр мин кирәк булсам, чакыртырсыз”,- дип, китеп барды. Завучка да барлык кирәк нәрсәләр белән тәэмин итәргә кушты. Вакыт-вакыт килеп, хәл белешеп китә, сорауларга җавап бирә, коллективка кирәкле күрсәтмәләр бирә.

Тикшерү беткәч, педсовет булды. Бик зур игътибар белән тыңлады. Коллектив та аны бик хөрмәт итә иде. Һәр сүзен тыңлыйлар. Таныш кеше, авылдаш дип, нindидер ташлама ясау турында бер сүз дә булмады. Мин язган отчетны тыныч кына укып чыкты, язылган кимчелекләр белән берсүзсез килеште, төзәтергә сүз бирде. Миңа аның эшлекле, бар нәрсәгә игътибарлы булуы, мәктәп коллективы белән үзара элемтәсе бик ошады. Тикшерүләр узып, эшләр беткәч, Марсель абый яңадан элеккеге шат, җор, гади кешегә әйләнде.

Марсель абый, әнисен бик яраткангадыр инде, хатын-кызны бик хөрмәт итә иде. Алар турында күпме шигырь язды ул. Бөтенесенә яратуын белдерде.

Аның ул мөнәсәбәтен кешеләр аңлап бетермәделәр бугай. Хәтеремдә,“Әнисә” дигән шигырен язгач, без аның белән көлешеп, сөйләшеп алдык.Бигрәк тә шаян күңелле иде ул. “Шигырь багышлаган бөтен хатын-кыз да минеке була алмый бит инде. Ә шуны аңламыйлар.  Хатын-кыз минем өчен алиһә булып кала,”- диде. Шагыйрь буларак, матурлыкка сокланып яшәде ул.

Исемдә, Марсель абыйга багышланган кичә уздырдык. Без бер автобус булып Алабугадан җыелып кайттык. Анда Мироваевлар бөтен гаиләсе белән килгән иде. Клуб халык белән шыгырым тулы. Катнашучылар да бик күп булды. Марсель абыйның күп кенә шигыренә Владимир Мироваев матур көйләр язган иде, аларны бик күп кеше җырлады. Искә алып, чыгыш ясаучылар да байтак булды. Шунда халыкның аны хөрмәт итүе бары тик яхшы сүзләр әйтүеннән сизелеп торды.

Минем хәтеремдә Марсель абый менә шундый булып калды. Мин белгәннәр арасында аның турында начар уйлаучыны белмим. Марсель абый белән таныш кешеләрнең йөзендә, аның турында сүз башлауга, матур елмаю пәйдә була. Авылын, әнисен яратып, авылдашларын хөрмәт итеп, гүзәллекне күреп тормыш итте. Кайда гына булса да, ул янып эшләде, янып яшәде. Шуңа күрә дә, иртә янып, китеп баргандыр инде ул. Безгә матур шигырьләре һәм җырлары, якты истәлеге калды. Аның әсәрләре, шундый матур язылган булу белән беррәттән, тирән уйландыра да. Рәхмәт сезгә, Марсель абый, бу дөньяга килүегезгә, безнең йөрәкләрдә матур эз калдыруыгызга. Урыныгыз җәннәттә булсын.

Махмутова Әнисә.
Ноябрь, 2018

**Энем турында сүзем.**

Марсель Гыйльфан улы Гыймазетдинов 1943 нче елның 11 декабрендә (элеккеге Бондюг) хәзерге Менделеев районы Бәзәкә авылында 13нче бала булып (ике әнигә), хезмәткәр семьясында туа.

Әтиебез – Гыймазетдинов Гыйльфан, 1912 нче елдан ВКПб члены, Камай, Күрәк волосте рәисе булган, Илдән акларны кууда катнашкан революционер. 1930-1948 елларда Бәзәкә авыл советы рәисе, авылда колхоз төзү эшләренә җитәкчелек итә.

Әниебез Гәзизәбану – йорт хуҗабикәсе.

Марсель Гыймазетдинов 4-5 яшьләрдә үк укырга, язарга өйрәнде. Мин 1нче сыйныф укучысы идем. Нәрсә укыйм, нәрсә ятлыйм – Марсель шундук отып ала, бик зиһенле малай иде. Энемә 4 яшь тулуга, әтиебез вафат булды. Ике баланы әтисез үстереп, кеше итү әниебез Гәзизәбану өстенә төште

Марсель башта балалар бакчасына йөрде, аннары 1951 нче елны Бәзәкә урта мәктәбенең 1 нче сыйныфына укырга керде. Бик тырыш, тәртипле, гел бишле билгеләренә генә укыды ул. Тәүге укытучысы Гөлсем апа Гайнуллина иде.

8-9-10 сыйныфларда укыганда, Марсельне урта мәктәпнең комсомол оешмасы секретаре итеп сайлыйлар. Сабакташлары, дуслары аны бик хөрмәт итәләр, чөнки ул ышанычлы, аралашучан, һәрвакыт ярдәмгә килергә торучы дус була.

Марсельнең шигырьләре 5 сыйныфта укыганда ук мәктәп стенгазетасында күренә башлый. 7-8 сыйныфларда Алабуга районы газетасы битләрендә бастырылып чыга. Шигырьләрен, җәяүләп барып, үзебезнең район газетасы редакциясенә тапшырган чаклары да булды.

Марсельненң 8 нче сыйныфта язган бер шигыре әле дә үземдә саклана:

Кыр казлары зәңгәр һаваларның
Дулкыннарын ярып киләләр.
- Кыйгак, кыйгак, саумы, дуслар, - диеп,
Гүя алар сәлам бирәләр.

Тракторларның көчле тавышлары
Килеп кушыла язгы җырларга.
Яшьлек үзе кочак җәеп килә,
Ничек чыкмассың соң кырларга.

Тирләр ага, кайчак билләр тала,
Аксын әйдә, талсын, талсыннар.
Җыр һәм хезмәт, җиңүләргә әйдәп,
Без йөрегән юллар калсыннар.

1959 ел.

Марсель, 1962 нче елны, Бәзәкә урта мәктәбен 5ле билгеләренә генә тәмамлап, Алабуга педагогия институтына укырга керде. Анда да ул бик актив, оештыру сәләте ташып торган факультет лидеры була, барлык җәмәгать эшләрендә катнаша.

Хезмәт юлын Тойгуҗа авылында укытучы булып башлап җибәрә. Аннары Камай авылында укытучы булып эшли. Шунда ук авыл комсомол оешмасы белән җитәкчелек итә.

Озакламый аны Ык-Тамагы авыл мәктәбенә директор итеп күчерәләр. Шул ук вакытта колхозның партия оешмасы белән җитәкчелек итә. РОНО инспекторы һәм тиздән, Камай авылы “Батыр Кул” колхозына партия оешмасы секретаре итеп сайлыйлар. Анда эшләгәндә авыл юлларына асфальт җәйдерә, урамнарын яктырта, амбар-фермаларны чистартып, ап-акка

буята. Аңа кадәр эшләгән өлкән яшьтәге агайлар булдырмаган эшләрне башкара.

1986 нчы елны Марсельне Тукай исемендәге колхоз рәисе итеп сайлыйлар. Яшь вакытта әтиебез Гыйльфан Гыймазетдинов эшләгән колхоз бу. Марсель Гыймазетдинов кабул иткәндә, ничә миллион бурычка баткан, эшче көчләр җитми торган колхоз була. Яңа рәис иң башта, хуҗалары ташлап киткән буш калган өйләрне барлый. Һәм Казан телевидениесеннән: - “Минем белән колхозны күтәрергә теләүчеләр булмасмы?” – дип, эшче көчләр чакырып, халыкка мөрәҗагать итә һәм сүзләрен “Әйләнеп авылга кайт әле” дигән шигырь-җыр юллары белән куәтли:

Рәиснең мөрәҗәгатен һәм җырны ишетеп, авылга бик күп гаиләләр әйләнеп кайта. Читтән килүче гаиләләр дә күп була. Аларны торак урыннары белән тәэмин итү сабакташы һәм курсташы, колхозның партком секретаре Әхмәтгәрәев Сәетҗан белән икесенең өстенә төшә.

Марсель Гыймазетдинов Г. Тукай исемендәге колхозда 1990 нчы елга кадәр эшли. Шушы 4 ел эчендә колхозның әллә ничә миллионлаган бурычын бетереп, колхозны районда беренчеләр рәтенә чыгара. Шул елны Менделеев районы сабантуенда алдынгы колхозчылар белән, күчмә байрак күтәреп, мәйдан әйләнәләр. Бу нинди зур шатлык иде, үзе һәм колхозчылары өчен! Мәйданга җыелган халык арасыннан берәү: - Әй, шагыйрь, син кайда идең моңа кадәр? – дип кычкыра.

1990 нчы елда, сыйныфташы, партком секретаре Саетҗан Әхмәтгәрәевка колхозны тапшырып, райисполкомга рәис ярдәмчесе итеп сайлыйлар үзен. Ләкин аның йөрәге, бәйгедәге аттай, басу-кырларга ашкына. Марсель иң артта калган совхозны үз теләге белән сорап ала. Ул совхозны да 2-3 ел эчендә алдынгылар рәтенә чыгара.

Авылдашы Гыйльфанов Мехәмәтнурга совхозны тапшырып, совхоздан Монай авылын аерып ала һәм, яңа колхоз оештырып, аңа “Татарстан” дигән исем бирә. Авылга газ керттерә, урамнарын яктырта, бик күп йортлар төзетә.

**Марсель Гыймазетдинов совхоз җитәкчесе генә түгел, Менделеев шәһәрендә уза торган барлык чараларда актив катнашучы да иде:**

Шәһәр-район советы депутаты;

Сайлауларда учет комиссиясе рәисе;

“Ядкарь” әдәби иҗат берләшмәсенең җитәкчесе;

Спектакльлләрдә баш рольлләрне башкаручы да;

СССР журналистлар берлеге әгъзасы;

Егор Уткин исемендәге премиянең 1нче лауреаты (1992 ел);

Бәзәкә авылының почетлы гражданины;

Татарстан энциклопедик сүзлегенә шагыйрь буларак кертелгән (2005 ел);

1992 елда туган якны өйрәнүчеләр конференциясендә район укучылары М.Гыймазетдиновны “Ел кешесе” дип атыйлар;
Югары уку йортларында студент якташларыбыз шагыйрь М. Гыймазетдинов белән бәйле темаларга багышланган конференцияләр үткәрәләр, курс эшләре һәм рефератлар язалар;

**Шагыйрьнең иҗат җимешләре җыентык булып дөнья күрә:**
1987 елда “Туган як җыры” җыентыгына М. Гыймазетдиновның шигырьләре “Аккош канат кагына” исеме белән кергән, 15000 экземпляр;
1990 елда “Яшәү мәгънәсе” исемле җыентыгы, 3000 экземпляр;
1992 елда “Язлардан алалмыйм күземне”, 3000 экземпляр;
1994 елда “Син мине белмисең” исемле җыентыгы, 2000 экземпляр;
2012 елда “Лира Прикамья” җыентыгында шигырьләре 300 экземпляр басылган;
“Үзгәртеп коручылар” исемле җыентыкта шагыйрьнең хезмәте турында күләмле мәкалә бирелгән;
Нәҗип Фатыйховның “Бондюжцы Татарстана” (1995 ел) китабында“Татарстан” колхозы һәм аның беренче рәисе буларак искәртмә бирелгән;
2010 елда“Бондюг Татарстана – Родина семи Героев Советского Союза” китабында “Династия Гимазетдиновых из Бизяков” – дип аталган язма зур урын алган;
2009 елда “Мәйдан” журналының 1 нче санында шагыйрьнең зур күләмдә шигырьләре басылган;
1995 елда“Аргамак” журналының 12 санында “Әдәби мирас” рубрикасында матур-матур шигырьләре басылып чыккан.

**Марсель Гыймазетдиновның шигырьләренә бик күп композиторлар көйләр яздылар:**
Аккош канат кагына - Сафьян Ибраһимов;
Көт әле дисең - Илгиз Закиров;
Гөлгенә –Вил Усманов;
Каеннарга сарган мәхәббәтем –Венер Мөхәммәдиев;
Соңлаган язлардай –Роберт Нәбиуллин;
Әнисә –Илгиз Закиров;
Язлардан алалмыйм күземне – Луиза Батыр-Болгари;
Туган җирнең китмәс кошлары без – Фирзәр Мортазин, Илгиз Закиров;
Сагышларым туган якта – Венер Мөхәммәдиев;
Кайтчы яныма – Фирзәр Мортазин;
Син генә – Әхтәм Миңлебаев;
Китмә син – Марсель Иванов;

Яшәргә дә әле, яшәргә – Чулпан Зиннәтуллина;
Балачак рәсеме – Сания Узлова;
Синең өчен – Алсу Салихова;
Килмисең син көлеп – Зөфәр Хәйретдинов;
Язмышымда калдың – Владимир Мироваев;
Рәмзия – Владимир Мироваев;
Туган авылым Бәзәкәм – Владимир Мироваев;
Тыңла әле – Вәсим Әхмәтшин;
Үпкәләмә миңа - Алсу Салихова;
Туган туфрак, туган нигез – Җәүдәт Гыйльманов;
Их, иркәм, белмисең – Алсу Салихова;
Әнкәйгә – Җәүдәт Гыйльманов;
Тирәкләрем – Вил Усманов;
Сиңа әйтер сүзләрем күп – Әхтәм Миңлебаев;
Тальян гармун – Җәүдәт Гыйльманов;
Юксынам дисең син – Илгиз Закиров;
Хуш киләсең, Яңа ел! – Сания Узлова;
Яшьлек – Җәүдәт Гыйльманов;
Әнкәемнең ак шәле – Илгиз Закиров, Җәүдәт Гыйльманов;
Халидә – Фирзәр Мортазин;
Саумы, әнкәй! – Роберт Нәбиуллин;
Аңламадың йөрәк тибешен – Ринат Донбас;
Бүләк иттем – Лилия Таһирова һәм башкалар.

**Шагыйрь Марсель Гыймазетдиновның күп кенә шигъри юллары чын афоризмнарга әверелделәр:**

– Мин яшәр идем кыска гомер,
Мәңгелеккә калсам кешедә;

– Туган җирем, синдә гомер буе
Яшәдем мин тугры ул булып;

– Шатлык булып җиргә ташыйк без...

– Туган якның фасыллары белән
Мин яшәрмен, мәңге яшәрмен;

– Кеше килә, кеше китә,
Ә яшәү дәвам итә;

– Сиңа кайттым: без бит – игез,

Туган туфрак, туган нигез;

– Шигырем һәйкәл, җырым маяк булса иде,
Алга әйдәп алып барырлык;

– Аклык-пакълык белән үтсен иде
Дөньялыкта кыска гомерем...

Марсель Гыймазетдинов үзенең **“Җырлар язам”** дигән шигырендә болай дип яза:

Җырлар язам халкым йөрәгендә шытсын,
Чәчәк атсын өчен.
Шигырь язам халкым күңелендә мәңге,
Мәңге калсын өчен.
Җырым яңгырар, үлмәсәләр алар.
Егет, кызлар аны җырлар.
Киң кырлар да, матур тугайлар да,
Чишмәләр дә бирелеп тыңлар.
Сайрар кошлар аны отып алсын.
Мин үлсәм дә, истәлегем булып калсын.

1 май,1979 ел.

Шушы шигыре аша, әйтерсең лә, ул безнең белән саубуллашкан. 1993 елның 19 апрелендә кадерле, бердәнбер энемнең йөрәге тибүдән туктады. Барыбызны ятим итеп, җаны мәңгелеккә күчте.

Шул көннәрдә авылдашыбыз, шагыйрә Фәния Шакирова Марсельгә багышлап шигырь язды.

**Очар кошым**

Очар кошым очты-китте, тоталмадым,
Очар кошка “китмә”- диеп әйтә алмадым.
Очар кошым ерак китте, кайта алмас,
Бүтән кошчык очар кошка тиң булалмас.

Очар кошны уңнан көтмим, сулдан көтмим.
Бәхет миңа кире кайтмас, өмет итмим.
Очар кошым, нигә инде очып киттең,
Нигә соң син безне ятим иттең?...

Марсель Гыймазетдиновның туып үскән йортында мемориаль такта куелды. Мәрмәр кабер ташына үзенең шигыреннән:

“Мин яшәр идем кыска гомер,

Мәңгелеккә калсам кешедә” – дигән сүзләре уелган.

Һәр елны авылдашлар һәм райондашлар Марсель Гыйльфан улының туган көнен балалар бакчаларында, мәктәп, китапханә, мәдәният йортларында зур бәйрәм ясап, билгеләп үтәләр. Авылдашлар, якташлар яраткан шагыйрьләрен онытмыйлар.

Ә мин, бердәнбер апасы, әти-әнием һәм яраткан энем Марсельнең рухларына ихласлык белән дога кылам, Ходай Тәгаләдән җаннары тыныч, рухлары шарт булсын дип телим. Амин.

Римма Гыйльфан кызы Гыймазетдинова,

2018 ел, декабрь

(Бу истәлек язма Мирһади Разов тарафыннан “Шәһри Чаллы” газетасында басылып чыкты.)

## Гыймазетдиновлар династиясе турында.

Әтием Гыймазетдинов Гыйльфан Гыймазетдин улы 1889нчы елның 11 мартында (элеккеге Бондюг)хәзерге Менделеев районы Песәй авылында туган. Башта Песәй авылы мәдрәсәсендә укый, соңыннан мәктәптә 7 класс белем ала. Шәрәфиев Сәет, Шәрифуллин Зәйнулла абыйлар һәм әтием Гыймазетдинов Гыйльфан Песәй авылында колхоз төзүдә актив җитәкчеләр һәм кохоз рәисләре булалар. Шәрәфиев Сәет абый Татарстанда Министрлар советы рәисе була. Әтием Алабуга кантонында бүлек рәисе вазифасын башкара. Азин дивизиясе партизаны.

Илдән, Кама, Волга буйларыннан куып, Уфа, Алабуга, Бондюг, Әгерҗе якларыннан ак банданы тар-мар итүдә катнаша. ВКПб сафларына шул вакытта кабул ителгән. Камай, Күрәк волостендә, акларның оясын тар-мар иткәч, шул авыл волосте рәисе булып эшли. Шул якларда Совет власте урнаштыруда җитәкчелек итә, 2 мәртәбә яралана.

1930 нчы елны әтиемне Бәзәкә авылына, төзелеп таралган колхозны яңадан төзүдә җитәкчелек итү өчен авыл Советы рәисе итеп 3 елга командировкага җибәрәләр. Авылда ике колхоз – Сталин һәм Ворошилов исемендәге колхозлар төзелә. Әтием 1930 нчы елдан 1948 елга кадәр Бәзәкә авыл Советы рәисе булып эшли. (1948 нче елның 11 мартында вафат)

Бәзәкә авылы халкы гомер буе суга тилмереп яши. Авылда берничә кешедә генә кое була. Ул коеларда да сулар бетеп кенә тора, чүмечләп кенә су җыя торган була халык.Егет чакта Песәй авлыннан Алабугага Тукмаклы чокырлары, таулары, үзәннәре аша үтә торган була әтинең юлы. Җир астыннан бәреп торган чишмәләрне күзәтеп йөргәндер, күрәсең ул. Бәзәкәгә рәис булып килгәч, ат арбасына озын торба салып, үзе белән бер иптәш ияртеп барып, чишмә эзлиләр. Бәхеткә каршы, көчле суы бәреп торган

чишмәгә торба утырталар. Саф чишмә суы бик югарыга атып бәреп чыга. Чимшмә янында соңрак зур чокыр хасил була. Төбендәге комнар саф-чиста булып ялтырап ята. Без бәләкәй чакта, экскурсиягә баргач, сөттән бушаган шешәләргә су тутырып, торба төбенә төшереп җибәрә идек. Бераз вакыт үтүгә, торбадан сулы шешә атылып өскә чыга иде. Менә шундый көчле сулы чишмә иде ул. Су агып, берничә километрга сузылып, Бәзәкәгә таба юл ала. 2-3 урында буа буалар. Халык суга рәхәтләнә. Су коеналар, каз-үрдәк үстерәләр. Җиз самоварны комлап юып, бала-чага чыр-чу килеп, инеш суында коенып, кышын бәке тишеп. суга рәхәтләнеп гомер итә Бәзәкә халкы. Бу чишмәне “Гыйльфан чишмәсе” дип атыйлар.

Шул чишмәләрне барлап, тагын авылга инеш агызучы ир-егетләр табылмасмы соң?

Юк инде, юк хәзер ул инешләр, корып беткәннәр.

Әтием ике мәртәбә өйләнә, 15 баласы була:

Миргарифан – Сарсаз авылында колхоз рәисе булып эшләгән. Үз теләге белән 1941 нче елны фронтка китә. Политрук була. Сугыш кырында ятып кала. Бер улы Дамир туып кала.

Миргаяз – Юдино совхозында ветеринар врач булып эшли. Бер кыз һәм ул үстерәләр. 1960 елда вафат.

Мирфаяз –Бөек Ватан сугышы офицеры. Сугышта каты яраланып, госпитальләрдә ята. Сугыш кырыннан исән кайтып өйләнә. Әгерҗе районы Деветерня авылында умартачы һәм колхозда бригадир булып эшли. 5 кыз үстерәләр. 1984 елда вафат.

Мирхәйдәр – Ленинградта хәрби ветеринар врачына укый. Суслонгерда офицер званиесында хезмәт итә. Кухнядан, яшереп ризыклар алып чыгып, ачка тилмергән кешеләрне ашата торган була. Соңрак Бондюгка кайтып, район башкарма комитетында секретарь, Сарсаз авылында колхоз рәисе, Песәйдә (туган авылында) озак еллар авыл Советы рәисе булып эшли. Хатыны Фәния белән 5 бала үстерәләр. 1974 елда вафат.

Мирзаһит – Теньки авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлап, бакчачы һөнәрен ала. Песәй авылында “Мичурин” сортлы алмагачлар утыртып, алма бакчасы үстерә. Анда шәмәхә эчле, бал тәмнәре килә торган алмалар үстерә. Шул алмагач бакчасында әтием дусты Мортаза абзый күмелгән. Соңгы елларын Ижау шәһәрендә яши. 1994 елда вафат.

Марсельеза – Алабуга культура-агарту училищесын тәмамлап, Песәй авылында китапханә мөдире булып эшли. 1952 елда вафат.

Марс – 12 яшендә салкын тигезеп, үпкәсе ялкынсынудан вафат.

Марсель – Алабуга педагогия институтын тәмамлый, Ык Тамагы авылында мәктәп директоры, Псәй авылында әтиебез төзегән Г. Тукай исемендәге колхоз рәисе, Менделеев районы башкарма комитеты рәисе

урынбасары, совхоз директоры, Татарстан исемендәге колхоз рәисе, шагыйрь, язучы, журналист, җәмәгать эшлеклесе.

1993 елда вафат. Ике ул үстерәләр:

Рөстәм – сан. врач һәм финансист. 2 малай, 1 кыз үстерәләр.

Марат – психолог. 2 малай үстерәләр. Беренче улына әтисенең исемен, Марсель дип куша. Шулай итеп, Казан шәһәрендә, әйтерсең лә, икенче Марсель Гыймазетдинов үсеп килә. Дөрес, әле ул 5 класста гына укый. Кем белә, бәлки бабасы язып бетерә алмаган шигырьләрне ул дәвам итәр, ул язар. Тормыш дәвам итә!

Өч бертуган Гыймазетдинов Гыйльфан кызлары Чаллы шәһәрен, Камаз заводын төзүдә актив катнашалар. Ул елларда көнне төнгә ялгап, атнага бер көн ял итеп, (әле ул да эләкми) я дежур буласың, я киңәшмәләр булып кына тора - эштән соң гына кайтасың.

Валентина – Ижевка авылында балалар бакчасы мөдире, партоешма секретаре була. Чаллы шәһәренә килеп, ЗЯБтәге заводта кадрлар бүлеге җитәкчесе булып эшли. Ак калада яңа трест (промышленных предприятий) оеша. Зур гына завод ЗМК, ЖБИ-210, РБЗ-1, РБЗ-2, ЗСК, агач эшкәртү, мрамор эшкәртү комбинатларын җитәкче кадрлар белән тәэмин итү аның өстендә була. Озак еллар эшләп, лаеклы ялга чыга. Ире Георгий Михеевич белән бер ул үстерәләр. 2006 елда вафат.

Галина –ЗЯБтәге заводта партоешма секретаре, кадрлар бүлегендә өлкән инспектор булып, озак еллар эшләп, лаеклы ялга чыга. Хәзер 93 яшьтә. Ире Михаил белән 6 бала үстерәләр. Барысы да югары белемле, шәһәрнең төрле урыннарында хезмәт итәләр: филология фәннәре докторы, баш ренгенолог, исполкомда бүлек җитәкчесе һ.б.

Римма – Казан сәүдә техникумы (бухгалтер), Бәзәкә авылы сельпосында бухгалтер, Минзәлә педучилищесы, Юраш авылында укытучы, Әлмәттә шәһәр балалар бүлеге җитәкчесе, Чаллының дүртьеллык СовХокук университетының кечке бүлегендә юрист белгечлеген ала. Чаллы шәһәрендә завод ЖБИ-210 кадрлар әзерләү бүлегендә инженер, ПО “Камгэсэнергострой” генераль дирекциясендә кадрлар буенча өлкән инженер булып 1974 елдан 1997 елга кадәр эшләп, лаеклы ялга чыга. “Хезмәт ветераны” медале белән бүләкләнә. Чаллы шәһәрендә яши. Кызы Лилия Чаллы шәһәре телевидениесендә видеомонтаж инженеры булып эшли. Лилиянең кызы Диләрә журналист, улы Булат КАИ студенты, бүгенге көндә диплом эшен яза.

Әти-әниемнең башка балалары сабый чакларында вафат булалар.

Римма Гыймазетдинова,<br>Май 2019 ел.

# Фотоядкарьләр.

## *Туган йортым, кадерле кешеләрем.*



**Туган йорт**



**Гыйльфан Гыймазетдинов**



**Газизәбану Гыймазетдинова**



Газизәбану өлкән балалары белән




Марсель һәм Римманың кечкенә вакытлары



Миргаяз Гыйльфанов гаиләсе белән





Римма әнисе Газизәбану белән

Мирзаһит Гыйльфанов





Валентина Гыйльфановна

Галина Гыйльфановна



Мирхәйдәр Гыйльфанов гаиләсе



Икетуган Галиәхмәт Сибгатуллин балалары белән




Рөстәм гаиләсе белән Гыйльфан бабасы йортында



Марат һәм Лилия – Рөстәм һәм Эльвира Гыймазетдиновлар



Рөстәм хатыны һәм уллары белән



Рөстәмнең өлкән улы Иркен





Марат һәм Лилия

Марат гаиләсе



Шагыйрьнең оныгы

Марсель Марат улы

Гыймазетдинов





Диләрә һәм Марат

Римма ханым оныгы Булат белән



М. Гыймазетдиновның 75 еллык юбилеена җыелган якын туганнар

## *Мәктәп һәм институт еллары.*




Марсель һәм балачак дусты Габделхәй Җиһаншин



Сабакташлар.
Сулдан уңга: Марсель Гыймазетдинов, Мулламөхәммәт Бәшәров,
Рифкать Тазиев, Габделхәй Шәрәфиев, Мансур Нәбиуллин, Муллаян Шәяхмәтов.



Рәшит абый Бәшаров җитәкләгән сыйныф




Студент еллары



Институт сәхнәсендә



Студентларның төзү отряды



Римма һәм Марсель Гыймазетдиновлар

## ***Хезмәт юл башы.***



Институттан соң Тойгужа мәктәбендә эшли башлаган вакыт



Ык Тамагы укытучылары



Камай мәктәбе коллективы

# Гаиләсе.



Марсель һәм Миңнур Гыймазетдиновлар



Уллары Рөстәм һәм Марат




Ял йортында



Марсель Гыймазетдинов улы Рөстәм белән

## *Эшсөяр рәис.*



Колхоз рәисе кабинетта



Сабантуйда



Сыер савучылар янында



Механизаторлар янында




Камай ашханәсе



Тукай колхозы хезмәтчәннәре

# Ижаты – җан авазы














Шагыйрь үз шигырьләрен укый



М. Гыймазетдинов һәм шагыйрь Г. Рәхим



ДИПЛОМ

№1

Настоящий диплом выдан

лауреату

литературно-краеведческой

премии

имени Егора УТКИНА

Гимазетдинову М[illegible]

в жанре исследование творчества

за 1992 год

М. Гыймазетдинов – Егор Уткин исемендәге премиянең 1нче лауреаты



Ике дус: М. Гыймазетдинов һәм шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин



Караламалар




М. Гыймазетдинов шигырьләренә көйләр

# Армас-талмас оештыручы



Ветераннар арасында



Яңа мәктәп ачу тантанасы



Аксакаллар белән очрашу



Сабантуйда



Алдынгыларны бүләкләү





Сәхнәдә тудырган образлар



«Жырлыйк әле, жырлыйк әле,
Жырлап ачыла күңел...»

„Ядкарь“

„Җырлыйк әле...“

Менделеев шәһәре
декабрь, 1987 ел.



Әдәби-музыкаль «Ядкарь»
берләшмәсенең чакыру кәгазе

Каләмдәш дусты Егор Уткин



Время выдачи билета

9 окт. 89

СОЮЗ ЖУРНАЛИСТОВ СССР

ЧЛЕНСКИЙ БИЛЕТ № 103789

Фамилия Гимазетдинов

Имя и отчество Марсель Гильфанович

Время вступления в Союз 19 мая 1989 г.

Председатель Правления Союза журналистов СССР

Шагыйрь М. Гыймазетдинов СССР журналистлар берлеге әгъзәсе

## *М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында 50 еллык юбилей тантанасы.*



Сүз остасы Рәшит Сабиров белән



Шагыйрь үзенең шигырьләрен укый



“Аккош канат кагына” җыры белән җиңү яулаган җырчы Зөһрә Шәрифуллина җыр авторы белән

 

Шагыйрьне юбилее белән каләмдәш дуслары котлый



Сәхнәдә М. Гыймазетдиновның җырларын башкаручы яраткан артистларыбыз

## *Шагыйрь музее*



ТАНЫКЛЫК

№ 306

МӘКТӘП МУЗЕЕ

ИСЕМЕН БИРҮ ТУРЫНДА

Менделеевск районы Бизәкә

(МУЗЕЙ ИСЕМЕ)

мәктәбенең әдәби музеена

(мәктәп, район, шәһәр)

Җәмгыятькә файдалы зур эзләнү-тикшерү эшләре алып барган, кызыклы экспозицияләр (күргәзмә әсбапләр) булдырган һәм укучыларны тәрбияләүдәге уңышлары өчен тапшырыла.

Республиканың мәктәп музейлары эзләү тикшерү

31 марта 1999 г.

СВИДЕТЕЛЬСТВО

№ 306

О ПРИСВОЕНИИ ЗВАНИЯ

ШКОЛЬНЫЙ МУЗЕЙ

литературному музею

(НАИМЕНОВАНИЕ МУЗЕЯ)

Бизякинской ш. Менделеевского р-на

(ШКОЛА, РАЙОН, ГОРОД)

За большую поисково-исследовательскую общественно-полезную работу, создание интересной экспозиции и успехи в воспитании учащихся

председатель комиссии республиканского смотра работы школьных музеев

31 марта 1999 г.






Музей ишекләре укучыларга һәрвакыт ачык



Шагыйрь музее ачылу тантанасы



Шагыйрьгә багышланган һәр кичәдә даими
катнашучы Гөлчәчәк һәм Владимир Мироваевлар гаиләсе



Шагыйрь Нәҗип Мәдьяров шигырьләрен укый




Фәния апа Шакирова чыгыш ясый



Татарстан Югары Советы депутаты, драматург Т. Миңнуллин һәм язучы Нәбирә Гыйматдинова белән очрашу.



Т. Миңнуллин һәм аның “улы” Кәрлә.




Авылдашлар һәм килгән кунаклар музей белән танышалар

## *М. Гимазетдиновны авылда һәм районда искә алу чаралары.*

### *Мәдәният йортында үткәрелгән “Якташлар-сәнгатьтәшләр” бәйрәме*




5нче сыйныф кызлары бию башкаралар




Гөлчәчәк Миннахметова “Әйләнеп кайт әле авылга” җырын башкара.
Баянда – Дамир Гыймазов




Фәния апа Шакированың “Бәзәкәдә ике чишмә” җыры башкарыла




Мәктәп укучылары “Туган авылым, Бәзәкәм” җырын башкаралар



“Мирас” түгәрәге әгъзаләре
шагыйрь йорты янында




Менделеевскийда шагыйрь йортында
яңа мемориаль такта




Мемориаль такта ачылган көндә шагыйрь йорты янында митинг



Бәзәкә зыяратында шагыйрь каберенә чәчәкләр кую




2017 елда, Бәзәкә авылының 500 еллыгын үткәргәндә, шагыйрь М. Гыймазетдиновка “Бәзәкәнең шәрәфле (почетлы) гражданины” дигән медаль тапшырылды.

## “Ләйсән” балалар бакчасында М. Гыймазетдиновның 70-еллыгына багышланган иртә.









Ана ролендә – Тәнзилә Сибгатуллина

Музыка җитәкчесе – Ясминур Гыйззатуллина

## ***Бәзәкә урта мәктәбендә шагыйрь М. Гыймазетдиновның 70-еллыгына багышланган чара.***




Мәктәп диварында шагыйрьгә багышланган стенд



Бәйрәмне тәрбия эшләре завучы Рәвилә Калимуллина ачып җибәрә



Мироваевлар гаиләсе чыгышы




Шагыйрьнең дусты Р.Нәбиуллин истәлекләр белән уртаклаша



Тазиева Ләйсән шигырьләр укый



85 яшьлек хезмәт ветераны Шәргыя апа Ибатуллина шагыйрьнең җырын башкара



“Ядкарь”че, шагыйрә Фәния апа Шакирова остазын җылы хисләр белән искә ала



Укытучы Ефимова Лилия “Язмышымда калдың” җырын башкара




Песәй укытучысы Наил Тимербаев шагыйрь турында илһамланып сөйли



Дусты Габделхәй Җиһаншин балачак һәм яшьлек елларын искә төшерә



Килгән кунаклар шагыйрьнең җырларын яратып җырлыйлар

**Авылыбыз китапханәсендә һәм мәдәният йортында яраткан шагыйребезгә күптөрле чаралар үткәрелә.**




Китапханәче Фәния Бәшәрова М. Гыймазетдиновка багышланган күптөрле чаралар үткәрә





Ветеран педагог Р. Мөхетдинова шагыйрь турында хатирәләр яңарта





Җырчы кызыбыз Юлия Иванова шагыйрь җырларын яратып башкара

Китапханәдә үткәрелгән чираттагы чарада катнашучылар



Мәдәният йортында шагыйрьнең шигырьләрен оста укучылар конкурсы

## Марсель Гыймазетдиновның 75 еллык юбилей тантанасы.








Марсель Гыймазетдиновның юбилей кичәсендә мәдәният йорты халык белән тулы иде



Алып баручылар Рәмзия Мөхетдинова һәм Гүзәлия Гомәрова юбилей тантанасын ачып җибәрделәр



“Бизәк” бию ансамбле кызлары “Аккошлар” биюен башкара



Бәзәкәлеләр шагыйрьнең “Кайтчы, иркәм, яныма” җырын башкаралар



Тойгуҗадан сәхнә ветераны Р. Нәбиуллин дусты турында чыгыш ясый



Песәйдән укытучы Н. Тимербаев шагыйрьгә багышланган үзенең шигырьләрен укый



Татар Тәкәше авылыннан “Гөлләрем” ансамбле “Әйләнеп авылга кайт әле” җырын башкара






Үзешчән сәнгатьтә актив катнашучылар
Рәвилә Калимуллина һәи Илшат Шакировлар жырлый






Яр Чаллы шәһәреннән килгән каләмдәш дуслар: Филология фәннәре докторы Әнвәр Шәрипов, филология фәннәре кандидаты Факил Сафин, “Шәһри Чаллы” газетасының журналисты Илшат Солтанов һәм баш мөхәррире Мирһади Разов, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы Әлфия Ситдыйкова.



Мироваевлар гаиләсе чыгышын тамашачы көчле алкышлар белән каршылады.
Җырлый Гөлчәчәк Мироваева



Татарстанның атказанган артисткасы Диләрә Мироваева Марсель Гыймазетдиновның “Язмышымда калдың” җырын башкара



“Бизәк” ансамбле кызлары “Чишмә янында” биюен башкаралар



Фәния Мухаметхатипова башкаруында “Көт әле, дисең” җыры тамашачы күңеленә хуш килде



Песәйдән Фирдәвес Рәхмәтуллина “Гомеремне назлы җыр иттең” шигырен башкара





Фәрит Гәрәев һәм Рашат Хуҗиәхмәтов
шагыйрьнең шигырьләрен
тәэсирле итеп укыдылар



Римма ханым, кызы Лилия һәм юбилейга килгән кунаклар




Шагыйрь Марсель Гыймазетдиновның 75 еллык юбилеен үткәрүдә катнашучыларны бүләкләү





Гөлшат Нәҗметдинова шагыйрьнең “Җырлар язам” шигырен укый, ә үзешчәннәр коллективы “Яшәргә дә әле, яшәргә” җыры белән юбилей тантанасын тәмамлый.

**Авылдашыбыз Марсель Гыймазетдиновның 75 еллык юбилеена багышланган “Гомер җырда калсын...” китабы тәмамаланып килә. Безнең сөйләгән-язган сүзләребез, укыган шигырьләребез, җырлаган җырларыбыз, Ходай Тәгалә риза булып, Марсель Гыйльфан улының рухына дога булып ирешсен, урыны җәннәт түрләреннән булсын. Амин!**



**Эчтәлек**

Кереш сүз
Сез канат бирдегез
Хезмәте – җан рәхәте
Булдырасыз, егетләр!
Татар тәкәше басуларында
Бер төш күрдем
Авылым киләчәккә карый
Олпат әдипнең юбилеенда
Пәйгамбәр
Соң булса да, уң булсын
“Сагыну”
Шомырт чәчәкләре ак кына
Әйтер сүзем калды
Сыерчыклар китәләр, без калабыз...
Мизгелләр... Хатирәләр...
“Җирне яшәртергә сүз бирдек”
Марсель Гыймазетдинов “Башкача булдыра алмыйбыз”
Тормыштан ямь – тәм табып
Үзгәртеп коручы
Туган җир моңнары
Безнең делегат
Халык бәяне дөрес куя
Уважаемый, Марсель Гильфанович!
Җирдән, туган туфрактан шыткан шигырьләр
Шагыйрь ару-талуны белми
Туган якның китмәс кошы
Шагыйрь Марсель Гыйлфановның вафатына мәрсия
Соңгы юлга
Фәйзелхак Хөснетдинов
Илгиз Абдуллин
Рәйсә Авзалова
Фәния Шакирова
Роберт Набиуллин
Фазыл Шәех
“Сиңа диеп моңлы бер җыр яздым,
Сәйләннәрдәй тезеп хисемнән...”
Гайшә Сәгъдиева
Николай Климов

Радость Гыйльфанов
Тарих әйтеп бетерсен
Марсель Гыймазетдинов истәлегенә
Җир язмышы күңелне телгәләде,
Туган як , дип типте йөрәге...
Кеше китә, җыры кала
Эстафетаны кабул итеп
Ул һәрдаим–күңелләребездә
Марсель Гыймазетдинов музее.
Исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен бел.
Марсель турында хатирәләр
В твоих песнях – твоя муза
Мы помним о них
Җырлы, моңлы очар кошыбыз
Исеме хәтерләрдә саклана
Көрәшче шагыйрь
Нәтиҗәсен үзегез чыгарыгыз
Мин сайлауларны ничек оттырдым
Марсель Гыймазетдиновка 70 яшь
Марсель Гыймазетдинов иҗатында милли, рухи-әхлакый кыйммәтләр һәм милли характерлар чагылышы
Марсель абый турында истәлекләр
Энем турында сүзем
Гыймазетдиновлар династиясе
Фотоядкарьләр